1926–1991 ЕЛЛАРДА АЗАТ ХАТЫН 2021 ИЮНЬ № 6

# СӨЕМБИКӘ

ISSN 0869-1398

ӘНИЕМ – КАРТЛАР ЙОРТЫНДА
язмышымы,
ялгышымы

ЮЛЫМДА –
синең эзләрең...
бер җыр тарихы

ДИНӘ ЗАКИРОВА
балыкчы кызыннан –
балыклы сый

Татьяна
ШИҺАБЕТДИНОВА:
«Һәр сәламәт туган
бала – шатлык».

Мин әни булдым, әни!

# Мин әни булдым, әни!

Мин әни булдым, әни!

Шушы сүзне әйткән мизгелдә барысы да үзгәрә! Аралар тагын да якыная, җылына, күңелләр бер-берсен сүзсез дә аңлый... Бер үк кичерешләр аша узганнарның якынлыгы башка аның. Сүзләр, хәрәкәтләр, теләкләр бөтенләй үзгә төсмер ала. «Менә әни ни өчен ул вакытта шулай дигән, шулай эшләгән (яки эшләмәгән) икән», – дип уйлыйсың... Барысы да мәңгелекнең үзе кебек гап-гади, чөнки син – Әни! Ә Әниләр инде бер телдә сөйләшә...

Өр-яңа проект башлыйбыз. «Мин әни булдым, әни!» дип атала ул. Бер фоторәсемдә өч буын – әниегез, сез һәм кызыгыз (улыгыз): буыннар чылбыры шулай тезелә!

Җылылык, яктылык, нур бөркеп торган мондый фотосурәтләр сездә дә бардыр – кушылыгыз!



Зөләйха КАМАЛОВА

## ӘКИЯТЛӘР СӨЙЛӘРМЕН

Кызым йоклый, төшләр күрә,
Төшенә ниләр керә?
Киң аланда чирәмнәрдән
Яланаяк йөгерә.
Ул аланда бик сөйкемле
Тәти соры бүреләр.
Болыт кебек бәрәннәргә
Алар һич тә тимиләр.
Ә бәрәннәр, чирәм утлап,
Үсәләр таулар чаклы,
Арысланнар жираф белән
Уйный икән курчаклы.
Диңгездә төсле балыклар
Матур җырлар сузалар.
Ак җилкәнле шук көймәләр
Берсен берсе узалар.
Йокла, кызым, күзләрең йом,
Әлли-бәлли көйләрмен.
Уянгачтын сиңа яңа
Әкиятләр сөйләрмен.

■ Бергәләп ял итү – гаиләбезнең иң матур гадәте дип саныйм. Мәсәлән, бакча эшләрен тәгәлләгәннән соң, самовар кайнатып, сөйләшә-сөйләшә, карлыган яфрагы, бөтнек белән пешерелгән чәй эчәбез. Андый чакларда якыннарыңның чыннан да бик кадерле булуын тоясың. Кызым Асылъяр да, әле сөйләшә белмәсә дә, безнең белән мәш килергә ярата. Безгә булышчы да, дус та үсеп килә.

Зөләйха КАМАЛОВА. Казан.

Фото: Анна АРАХАМИЯ.

# Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!



© «Сөембикә» 2021




Фото: Анна Арахамия

Ежемесячное литературно-художественное и культурно-просветительское электроннное периодическое издание на татарском, русском языках для женщин и семьи.

Территория распространения: Российская Федерация, зарубежные страны

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2015 елның 18 маенда «Сююмбике» дип теркәлгән. Теркәү таныклыгы Эл № ФС 77-61814

Язмалар авторның тулы адресы күрсәтелеп, паспорт мәгълүматлары, пенсия иминияте таныклыгы, ИНН таныклыгының ксерокс күчермәләре белән бергә җибәрелгәндә генә кабул ителә.

Кульъязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.

**Баш мөхәррир**
Л. Н. Маликова

**Редколлегия:**
Зилә Вәлиева, Нурия Вәлиева, Искәндәр Гыйләҗев, Нәбирә Гыйматдинова, Айрат Зарипов, Эльмира Зарипова, Кадрия Идрисова, Сәрия Сабурская, Нурия Һашимова, Гөлназ Шәйхи, Рафаэль Шәвәлиев, Равилә Шәйдуллина, Лотфулла Шәфигуллин.

**Редакциянең гомуми телефоны** 222-09-77

**Җитәкче урынбасары** 222-09-78
Рәмзия Кашапова
**Баш мөхәррир урынбасары** 222-09-78
Гөлнур Хәсәншина
**Җаваплы сәркатип**
Лариса Маликова
**Әдәби мөхәррир**
Эльмира Закирова
**Сайт мөхәррирләре:**
Сөмбел Гаффарова
Камилә Димөхәммәтова

Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

Реклама текстлары аны бирүчеләр җаваплылыгында.

Редакциянең язмача рөхсәтеннән башка материалларны «Сөембикә»дән күчереп басу тыела.

**Тышлыкта:**
Татьяна Шиһабетдинова
Фото: Анна Арахамия

**Мөхәррирләр**
Чулпан Галиәхмәтова
Сөмбел Гаффарова
Алсу Шакирова
Фәгыйлә Шакирова
**Верстка**
Резеда Галиуллина
**Корректор**
Фирдәвес Исмәгыйлева
**Фотокорреспондент**
Анна Арахамия
**Гамәли хезмәткәр**
Ильмира Сөләйманова
Олег Сердюк

Формат: 225х290 мм
Күләме 64 бит

Басарга кул куелды: 31.05.2021 ел.
Чыгу көне: 7.06.2021 ел.
Заказ Е-1737
Тираж 9952

Учредитель: Акционерное общество «Татмедиа»



ТР «Татмедиа» Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.

Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.
**www.syuyumbike.ru**
E-mail: suumbike@tatmedia.com
ssuum@yandex.ru
тел./факс: (843) 222-09-77

Язылу индексы
ПАП рәсми каталогы буенча:
Татарстанда П2204 (ярты еллык),
П8299 (берьеллык)
Татарстаннан читтә: П0279

Банк реквизитлары:
Филиал АО «ТАТМЕДИА»
«Редакция журнала «Сююмбикә»
Расч/счет 40702810600020010309
кор/сч 30101810000000000805
в ПАО «АК БАРС» БАНК г. Казань
ИНН 1655144950
БИК 049205805
КПП 165802002

16+

# 1 ИЮНЬ – ХАЛЫКАРА БАЛАЛАРНЫ ЯКЛАУ КӨНЕ




Фото: Алиса Даутова

# Баш мөхәррир сүзе




Без ирем белән бик яшьли өйләнештек: икебез дә кичәге студентлар, әле эшкә дә урнашып өлгермәгән... Бар мөлкәтебез – мәхәббәт! Кызыбыз туды. Бала караватында яткан кечкенә йомгакка карап: «Без аны ничек үстерербез? Нинди тәрбия бирә алырбыз?» – дип, күз яшьләрем белән елаганым әле дә исемдә. Азаматның: «Без аны яратырбыз!» – дип, мине тынычландырырга тырышуы да онытылмый...

Кызларыбыз инде үсте: олысы да, кечкенәсе дә. «Яратып үстерү» формуласы эшли – сезгә дә аны тәкъдим итәм. Әмма соңгы вакытта гел бер нәрсә хакында уйланам: яратуның барыбер чамасы булырга тиештер.

Без хәзер кеше тормышы турында соцчелтәрләрдән барысын да белеп торабыз. Бер ерак танышларымның гаиләсен дә фотолар аша гел шулай күзәтеп бардым. Бәхетләре ташып тора! Һәм ул бәхетне әни кеше гел балалары аша күрсәтте: менә алар бергә табигатьтә, менә балалары ике катлы кызыл поезд янында чемодан тотып басып тора – ялга китешләре; улы белән кызының диңгез ярындагы фотосурәтләрен аларның мәктәп бәйрәмнәре алыштыра; кафе-рестораннардагы кичке ашлар да бихисап... Бер нәрсә аермачык күренә: бу танышым балаларын бар нәрсәдән артык күреп ярата. Алай гына да түгел – ул аларны бу яратуга күмә!
Ә Яңа ел алдыннан алар хакында гел көтмәгән хәбәр ишеттем. Уллары: «Туйдым сезнең игътибардан!» – дип, кышның суык бер көнендә җәйге курткадан гына өйдән чыгып киткән... Ярты ел инде соцчелтәрләрдәге фотолары үзгәрешсез... Димәк, улы һаман да кайтмаган.

Һәм менә быел шау чәчәккә күмелгән май башында барыбызны да тетрәндергән Казандагы фаҗига... Ике мисал арасында нинди бәйләнеш бар? Әйе, тагын ярату. Бу яшь егетне әлеге адымга этәргән сәбәпләрне ачыкларга тырышканда «аңа игътибар һәм ярату җитмәгән» дигән фаразлар да булды. Кемдер моны җинаятьчене акларга тырышу дип тә кабул итте. Минемчә, алай түгел. Башка әти-әниләргә кисәтү иде ул: балаларыгыз белән бергә еш буласызмы, аларны ишетәсезме?

Әйе, бала үстерү җиңел түгел... «Яратып үстерү» формуласы да шактый катлаулы. Ата-ана сакларга тиеш чик күзгә күренми, әмма аны узып китү дә, аңа барып җитмәү дә – икесе дә бер дәрәҗәдә куркыныч.

Яратып,
Лариса МАЛИКОВА

# Безнең тышлыкта



«Һәр авырлы хатынның үз язмышы. Алар өчен бала табу – гомерендәге иң зур вакыйга. Бер очрак та бер-берсенә охшамаган.»


16
«Башкача яши белмим...»
Чулпан Галиәхмәтова


# Заман һәм без




6
Вәхшигә табынучылар
Чулпан Галиәхмәтова





10
Диңгез буласым килә
Алсу Шакирова





14
«Матурлык эзлим»
Гөлнур Хәсәншина






20
Үҗәт Алишәнең илһамчысы
Чулпан Галиәхмәтова

## Татар дөньясы



22 Салиховлар утарында
Эльмира Закирова

Гомер заяга узмаган 26
Гөлнур Сафиуллина



30 «Талчыбык без милләт агачында»
Лилия Гәрәева

## Мәдәни тормыш

Фатиха 36
Кәрим Кара




40 Роза Халитова: «Музыка белән яшәү җиңелрәк!»
Алсу Шакирова

## Яшәеш



46 «Бүтән әнием юк...»
Гөлнур Сафиуллина



50 Юлымда – синең эзләрең...
Алсу Шакирова

## Хуҗабикә

Яңаклар матурлыгы 57
Чулпан Юнысова

58 Бакча йортын яңартабыз
Алсу Шакирова



60 Гөмбәле скумбрия



# ВӘХШИГӘ ТАБЫНУЧЫЛАР



Чулпан
ГАЛИӘХМӘТОВА

Быелгы майның матурлыгын сурәтләп бетереп булмас иде кебек. Беренче көннәрдән үк кояш, бөтен дөнья чәчәктә. Тирә-як хуш искә, сандугач тавышына күмелде. Күңелне бетмәс-төкәнмәс шатлык хисенә төргән майның бер көнендә кинәт бу матурлык югалып калды, тоныкланды. 11 май иртәсе күпләрнең тормышын астын-өскә китерде. Хәер, аерым кешеләрнекен генә түгел, республиканыкын да. Татарстан башкаласындагы 175 нче гимназиядә булган вәхшилектән соң без инде башкачарак булырбыз кебек. Майның матурлыгы да кабат кайчан куандырыр, билгесез. Фаҗигадә якыннарын югалтканнар өчен май гомер буена кайгы ае булып калачак… Җитмәсә, бу вәхшилек җәмгыятьтәге тагын бер фаҗигане дә кабат ачып күрсәтте.

### *Казан колумбайнеры?!*

«Кемнәргә аттым, барысын да юк итәргә теләдем, яралар өчен генә түгел», – ди мәктәпкә коралы һөҗүм ясаган 19 яшьлек Илназ Галәвиев соңыннан сорау алганда. Ул 20 җанны кыярга планлаштырганын әйтә. Ә иң куркынычы: «Бу эшем өчен үкенмим, Россия кануннары буенча гаебемне тулысынча таныйм, ә үзем – юк. Үземнең Аллаһы Тәгалә икәнемне күрсәттем», — ди яшь җинаятьче. Әле яшәргә дә өлгермәгән егеттә мондый кансызлык каян килгәнен фаразларга гына кала. Кемдер моңа интернетны, кемдер интернет уеннарын, кемнәрдер корал сатып алырга рөхсәт бирүчеләрне гаепләде. Әмма без барыбыз да гаепле. Белем бирү оешмаларында мондый кансызлык бер генә булса, аерым бер кешеләрне гаепләп булыр иде. Ләкин, кызганыч, бу системалы күренешкә әйләнеп бара. Колумбайнерлар агымы чәчәк ата. Моннан дистә еллар элек ул әле башка кыйтгада гына иде. Менталитет, кыйммәтләр бөтән булган җәмгыятебезгә ул кермәс төсле тоелды. Колумбайнер төшенчәсе 1999 елда барлыкка килә. 20 апрельдә АКШның Колорадо штатындагы Колумбайн мәктәбенең ике укучысы Эрик Харрис белән Дилан Клиболд, мәктәпкә алдан әзерләнеп килеп, 13 кешенең гомерен өзәләр, 23 кешене яралыйлар, соңыннан үзләренә дә кул салалар. Алар интернет технологияләр белән җенләнә, сайтларында җәмгыятьне куралмаулары, кешеләрне юк итәргә теләүләре турында язалар. Моның белән кызыксынучыларны, ул җинаятьчеләргә табынучыларны колумбайнерлар дип атыйлар. Инде бу вәхшилек Россия мәктәпләренә дә үтеп керде. 2014 елда Мәскәүдә унынчы сыйныф укучысы, мәктәпкә утлы корал алып килеп, укытучысына ата, классташларын тоткынлыкка ала.

Иң фаҗигалесе 2018 елның 17 октябрендә Керчь политехник көллиятендә була. 18 яшьлек студент Владислав Росляков утлы корал белән көллияткә килеп, 21 кешенең гомерен өзә, үзенекен дә аямый. «Керченский стрелок» дигән исем бирелгән бу җинаятьчене Колумбайн мәктәбенә һөҗүм итүчеләргә охшарга тырышкан дип бәяләделәр. Тагын бер колумбайнер Татарстанда да барлыкка килдеме?! Ул да бит 20 кешенең гомерен кыярга планлаштыра. Колумбайндагы атышка кадәр дә мәктәптә мондый очраклар була, әмма соңгысы туры эфирда диярлек бара. Бу – барлык матбугат чаралары сөйләгән беренче скулшутинг (инглиз теленнән кергән термин. School shooting — «мәктәп укучыларын күпләп юк итү». Мәктәпләргә коралы һөҗүм дигәнне аңлата. – *Ч. Г.*). Матбугат игътибары колумбайнерлар агымын көчәйтә генә дип саный психологлар. Әлеге хәлләр турында тирәнтен өйрәнеп һәм бик сак язарга киңәш итәләр.

Россиядә колумбайнерларны ныклап торып өйрәнмиләр икән әле. Шулай да Россия психологлары Кирилл Хломов һәм Денис Давыдовның америка тәҗрибәләренә таянып үткәргән тикшеренүләре буенча, мәктәпләргә коралы һөҗүм ясаучыларның 60–78 проценты депрессиядән интеккән, 12 процентының якын дуслары булмаган, 34 проценты – йомык кешеләр. Җинаятьчеләрнең күпчелеге – социаль яктан яхшы гаиләләрдән, социаль хезмәтләрдә исәптә тормаган, барысы да диярлек яхшы укыган.



Казан дәүләт медицина университеты профессоры, медицина фәннәре докторы, психиатр Ләйлә ШӘЙДУКОВА: «Пубертат чорындагы кайбер үсмерләр үз-үзен тотышы, кыланышы, эш-гамәлләре социаль нормаларга туры килмәгән шәхесләргә соклана, аларны үзенең кумирына әйләндерә...»

Казан дәүләт медицина университеты профессоры, медицина фәннәре докторы, балалар психиатры Ләйлә Шәйдукова Казан колумбайнерының психологик портретын һәм аның бу адымга бару сәбәпләрен фаразлады:

– Җинаятькә баруы ук рухи яктан сәламәт булмавын күрсәтә. Тоткарланганнан соң сорау алган вакытта төшерелгән видеодан аның психомоторикасы ярсулы булуын күрәбез. Ул бәргәләнә, теләсә нәрсә кычкыра, йөзе акылдан язган тиле кешенеке кебек... Үзен Аллага тиңләвен, кешеләрне «биомусор» дип атавын психиатриядә парафрения, ягъни кискен саташу дип атыйлар. Бу нәрсәдән килеп чыгарга мөмкин соң? Беренче версия һәм, мөгаен, иң туры килгәне – шизофренияле шуб. Бу авыру бер көндә килеп чыкмый. Кеше гадәти тормыш алып бара, әмма психик яктан тәэсир иткән хәлләр өянәген кузгатып җибәрә. Холкы буенча җинаятьчене тыныч, йомык кеше, диләр. Җитмәсә, ул – программист. Димәк, даими рәвештә виртуаль дөньяда дүрт стена арасында утырган. Вәхши идея дә аңа атна эчендә килмәгән бит. Башта ул ният туган, аннан әкренләп ныгыган. Моңа, күрәсең, билгеле бер хәлләр, аерым бер вакыйгалар этәргәндер. Икенче версия – наркотик матдәләр кабул итү. Әмма ул урынсыз. Наркотик матдәләр кыска вакытта гына тәэсир итә. Әфьюн кешене һәрвакыт ярсытып тормый. Гаиләсеннән кала, тирә-яктагыларга куркыныч булуы моңа кадәр беленмәгән бит. Саташуы хәзер барлыкка килгән. Өченче версия – социопат. Ягъни холкында үзе һәм тирә-яктагылар белән гармониядә яшәргә киртә тудырган сыйфатлар булу. Мондыйлар төрле секталар йогынтысына тиз бирелә. Миңа калса, әлеге версия бу җинаятьчегә туры килеп бетми, чөнки видеодан күренгәнчә, саташуы гаять көчле иде. Шуңа күрә психиатр буларак, аның шизофрения белән интегү версиясе дөреслеккә туры килә дип саныйм.

Фото: Анна Арахамия

## Иң куркынычы – үсмер кызлар җинаятьчегә мәхәббәт аңлата.

Палачның авырумы-түгелме икәнен әлегә Мәскәү психиатрлары тикшерә. Алар дөрес һәм рәсми диагноз куяр дип ышанабыз.

### *Тормыш дәвам итә... Әмма ничек?*

Бу фаҗигадә 9 кеше һәлак булды, 32 кеше шартлау һәм атудан төрле тән җәрәхәтләре алып, хастаханәдә ята. 7 ата-ана зур өметләр баглап үстергән багалмаларын караңгы гүргә иңдерде. Аллаһы Тәгалә аларга алга таба яшәр өчен көч һәм сабырлык бирсен. Күтәрә алмас кайгы килгән кешеләрнең елауларын, әрнеп әйткән сүзләрен, чирәмдә тезелеп яткан яралы балаларны, хәтта сыйныф бүлмәсендә кан эчендәге укучыларны минуты-сәгате белән күрдегез. Хайп артыннан куган матбугат, төрле телеграм-каналлар мондый фото, видеоларны таратудан чирканып тормады. Монысы инде җәмгыятьнең башка авыруы. Башка тема...

Күз алдында классташларының гомерләре өзелгәнен күргән исән балаларга ничек яшәргә? Тормышка, җәмгыятькә, өлкәннәргә ышанычны ничек кире кайтарырга? Йөрәкләренә утырган бу төен тора-бара зураймасмы? Бәхет төшенчәсе онытылмасмы? Исән калган укучыларның ата-аналарын бүген әнә шул сораулар борчый. «Гаилә» мәчетенең имам-хатыйбы Рөстәм Хәйруллинның да ике улы – канлы мәхшәр шаһиты. Өченче сыйныфта укыган Әминдә өч ядрә ярасы. Ул хастаханәдә дәвалана. Әхмәт исә утның нәкъ эчендә була. Сыйныфташларының җинаятьче кулыннан һәлак булуын үз күзләре белән күрә. «Әти буларак, шәхсән мин үзем бу фаҗигадән дәрес алдым. Бөтен теләгем – балаларым кара йөрәкле булып үсмәсен иде. Үзем дә көн-төн мәчеттә, игътибар да җитеп бетмидер. Зур кайгы артыгы кирәкмәгәнне күрсәтте. Мәхшәр эченнән улларымны эзләп йөргәндә бизмәндә бала ягы басты, күзгә берни күренмәде... Бары бер теләк булды: «Раббым, сакла!» Балаларга телефон, компьютер бүләк итәбез, кием алабыз, ә рухи тәрбия турында уйлап бетермибез. Аллаһы Тәгаләне дә күпләр кайгы килгәндә генә искә ала», – ди хәзрәт. Әлеге фаҗиганең килеп чыгуын да рухи һәм әхлакый тәрбия җитмәгәнлектән дип саный.

– Революциягә кадәр мәктәпләр мәчет-чиркәүләр янында иде. Кешене дин тәрбияләде. «Дин – халык өчен әфьюн», – дип, совет чорында аны читкә этәрделәр. Динне югары дәрәҗәдәге мәдәниятркә алыштырдылар. Ул вакытта да тәртип иде. Цензура үткән кино-мультфильмнар тәртипкә, олыларны хөрмәт итәргә, илне сөяргә өйрәтте. Пионер-комсомол идеологиясе көчле иде. Ә хәзер балаларны интернет тәрбияли. Мәдәният тә югалды, әти-әнинең дә вакыты юк – алар көн-төн эштә. Аннан, хәзер бит өлкән буын белән бер түбә астында яшәргә дә бик яратмыйлар. Ә интернет ул чүплек кебек, анда бар нәрсә дә бар. Яшьләр өчен әхлак, дингә генә урын аз. Илназ Галәвиев гөнаһ дигән сүзне, әхлакның нәрсә икәнен белсә, бу адымга бармас иде. Йөрәгендә Аллаһы Тәгалә яшәгән, аннан курыккан яшьләр бу адымга берничек тә бара алмый.

Бу фаҗигадән соң берничә көн үткәч, хәзрәт белән бер чарада күрештек. Ул анда улы Әхмәт белән килгән иде. Улының кулын бер минутка да ычкындырмады. «Улым җәмгыятьтән читләшмәсен өчен бар көчемне куям, – дип аңлатты ата. – Аңа җиңел түгел. Болай да йомшак күңелле бала ул. Психологлар: «Эмоцияләрен чыгарып бетерсен өчен һаман сөйләсен», – диделәр. Кайберәүләр Әхмәткә интервью бирдерткән өчен гаепли. Әмма мин аны махсус эшлим. Сөйләсен генә. Медкомиссия булды, ярты сыйныфташлары килмәгән. «Алар халык арасына чыгарга курка», – ди. Әхмәт тә телевизордан «Ашыгыч ярдәм» машинасы гүләвен ишетсә дә, сискәнеп китә. Беркөнне капка төбендә идек, безнең тыкрыкка таныш булмаган кеше килеп керде. Карыйм, Әхмәт артка чигенә башлады. «Улым, ни булды?» – дип сорыйм. «Анда чит кеше», – ди. Шуңа, Әхмәтне җитәкләп, төрле сәбәпләр табып, халык арасына алып чыгам. Йөрәгендә халыктан, җәмгыятьтән курку калмасын, кешеләргә карата ышанычы бетмәсен иде, дим. Аның йөрәге дә карага әйләнергә мөмкин бит. Шуңа күрә дә балалар янында усаллык күрсәтмик, аларның күңелендә кала ул. Шушы кайгыдан зур сабак алып, балаларны саклыйк, тәрбиялик. Алар кеше булсын. Безнең һәр сүзебезне балалар да ишетә, шуны да онытмыйк. Хәзер бу фаҗигадә гимназия директорын, укытучыны гаепләүчеләр дә бар. Әмма ул гаепләүдән безгә җиңеллек килми. Кешене рәнҗетәбез генә. Укытучы бөтен йөрәге белән безнең балаларны сакларга теләгән бит – ядрә астына кергән. Шул хакта онытмасак иде».

### *«Илназ, син краш...»*

Менә монысы инде иң куркынычы! Киләчәк өчен иң аянычы! Һәм тиз арада хәл ителмәсә, еллар үткәч шартлаячак дары мичкәсе... Кеше җанын кыючы Илназ Галәвиевнең социаль челтәрләрдә берничә фанклубы оешты. Тугыз кешене җирләүнең икенче көнендә ул секс-символга әйләнде. Аның судта башын кырын салып, камерага төбәлеп басып торган фотосы астына нинди генә шәрехләмәләр язмадылар! «Син краш!» (Яшьләр слэнгы. Инглиз телендә мәхәббәт хисләре өермәсе дигәнне аңлата. – *Ч. Г.*) «Илназ, син чибәр», «Син гаепле түгел», дип язалар. Хәтта «Үлгән балалар үлгән инде, сине жәллим», дип язарга да уңайсызланмаганнар. Мәхәббәт тә аңлаталар, төрмәдән көтәчәкмен дә, диләр. Үсмер кызлар... кеше үтерүчегә гашыйк! Керчь көллиятендә атыш оештырган Владислав Росляковның да үз вакытында фан-клублары барлыкка килгән иде. Алай гына түгел, ул кигән «Ненависть» дигән язулы футболкага бермә-бер сорау арта. Тора-бара Илназның «Бог» дип язылган битлегенә ихтыяҗ тумас дип, ышандырып кем әйтә ала?!.

Яшүсмер вакыт – болай да үзеңә һәм бөтен дөньяга карата ачу килгән чор. Моны хәзерге яшь буын гына түгел, без дә, әти-әниләребез дә, әбибабаларыбыз да үткәндер. Гормоннар уены чорларга карамый ул. Әмма хәзерге үсмерләрдә ул тагын да киеренкерәк, катлаулырак. Балалар психиатры Ләйлә Шәйдукова әйтүенчә, соңгы вакытта парадоксаль хәлләр күзәтелә. Пубертат чорындагы үсмерләр үз-үзен тотышы, кыланышы, эшгамәлләре социаль нормаларга туры килмәгән шәхесләргә мөкиббән. Галәвиев, Росляковлар кебекләр кумирга әйләнә. Аларның матурлыгына, максатына чигенмичә барган «батырлыкларына» сокланалар. Үсмерләр хәтта аңлап та бетерми: алар бит психологик патологиягә, психика какшауга таң кала. Психиатр Ләйлә Шәйдукова моның сәбәбен болай дип аңлата.

– Хәзерге яшьләрнең күпчелегендә тормыш кыйммәтләре, күзаллаулар бозылган, минемчә. Алар өчен матурлык белән бозыклык, әхлак белән әхлаксызлык арасында чикләр юылган. Шуңа да тормышта булырга тиеш түгел хәлләр: суицид, гомицид еш очрый. Хәтта блогер-кеше үтерүчеләр бар. Болар барысы да лайклар өчен. Лайк галиҗәнаплары безнең балалар белән идарә итә. Әлеге тенденцияне бетерү бик авыр булачак. Үсмерләрдә җылылык, миһербанлылык дигән сыйфатлар юкка чыга. Нәкъ менә шулар корал сатып алып, аны кешеләргә төби!..

Балаларыбыз киләчәге бары тик безнең – ата-аналар кулында. Мәктәпләрдә, кызганыч, тәрбия функциясе юкка чыгып бара. Тәрбия эшен тестлар, рейтинглар, БДИлар алыштырды. Моңа укытучы гаепле түгел, билгеле. Аның күпме кәгазь тутырасы, хисап тотасы бар. Хәзерге укыту системасы аларны шушы көнгә төшерде. Класстан тыш чаралар юк дәрәҗәсендә, безнең заманда «акыл өйрәтү сәгате» дип аталган класс сәгатьләрендә дә бүген билге тикшерәләр. Яшь буынны үстерү өчен эшлибез дип, изге гамәлләр турында күп сөйләсәләр дә, түләүсез спорт секцияләре дә, түгәрәкләр дә күренми. Алар бардыр да, әмма күп һәм нәтиҗәле түгел. Спорт, бию, музыка белән шөгыльләнү акчага корылган бүген. Кешеләр арасындагы социаль аерма да үсмерләр күңелендә каршылыклар тудыра. Бары үз үрнәгебездәге тәрбия белән генә балаларны саклап алып кала алабыз. «Алар материаль яктан тәэмин ителгән, әмма эмоциональ яктан ялгыз, – ди психиатр, – Барысы да интернет кочагында. Безгә һәр айны селфхарм тәртипле берничә үсмерне алып киләләр. Селф – үз-үзең, ә харм – саташу дигән сүз. Алар кан тамырларын кисә, кул беләзекләренә, аякларына, иңсәләренә яра ясый. Имеш, шул рәвешле авыртуны баса. Барысы да диярлек моны интернеттан өйрәнгәнен әйтә. Үсмер үз-үзен имгәтә икән, аңа башкаларга зыян салырга нәрсә комачауларга мөмкин? Эчкерсез, җылы, тере сөйләшүләрне, үзләренә ышанып карауларны алар бик аз күрә. Шуңа күрә дә үсмер белән күбрәк аралашырга, миһербанлылыкка өйрәтергә кирәк. Кызганыч, игелек хәзер бездә – дефицит».

Ә балалар үсә. Элек тәртипсез үсмерләрне «урам балалары» дип атыйлар иде. Балалар өйдә, урамга чыгып йөрми, дип сөенәбез хәзер. Ата-аналар көн-төн эшкә чапканда, аларга урам тәрбиясен интернет бирә. Йә аларны ул тәрбиядән йолып алабыз, йә җинаятьчеләргә мөкиббән егет-кызлар үстерәбез. Җан кыючыга сокланганнар иртәгә үзләре үк бу адымга бармас дип, кем әйтә ала?! Монда һәр мәктәпкә Росгвардия сагы куеп та, утлы корал сатып алу яшен арттырып та, үлем җәзасы кертеп тә, «Яровая пакеты» кебек кануннар кабул итеп тә котылып булмаячак.



**Гөлназ ӘХМӘТҖАНОВА, психолог**

Казанда булган фаҗигадән соң ата-аналар психологларга күбрәк мөрәҗәгать итә башлады. Мондый вәхши хәлләрне кеше аеруча эмоциональ кабул итә, аның тизрәк әйләнә-тирәдәге дөньяны «чистартасы» килә башлый. «Минем улым үзен-үзе яклый белми. Аны мәктәптә кыерсытырлар да, ул йомылыр, җәмгыятькә карата үпкәсе туып, җинаятьчегә әйләнмәс микән», – дип борчыла ата-аналар. Иң элек үзләренең психологик халәте өчен җаваплылык тоялар. Беләбез: бәхетле әниләр генә бәхетле балалар тәрбияли ала. Үзләренә карата ышаныч тоярга, шатлык хисләре кичерә белергә гаилә өйрәтә бит баланы.

Әти-әниләр баланың аңа гына хас булган үзенчәлекләренә игътибар итсеннәр иде. Озак иялэшә, авыр аралаша торган балалар бар. Моны күз уңыннан ычкындырмаска кирәк. Безгә әлеге проблема белән ата-аналар һәрдаим мөрәҗәгать итә. Ул балалар белән махсус тренинглар үткәрәбез. Алар үзләрен күрсәтергә, коммуникациягә өйрәнә. Үз эченә бикләнгән балаларны ачып була. Әмма бер нәрсә бар – кайбер ата-аналар баланың авыру булуы белән килешергә теләми. Психиатр куйган диагнозны җитди кабул итми. «Ул сау-сәламәт» яисә «Үскәч барысы да җайланыр», – дип уйлыйлар. Әмма шуны онытмаска кирәк, балага ярдәм итмәү дә – җинаять.

Баланың билгеле бер мохиттә үз-үзен ничек тотуын күзәтергә киңәш итәр идем. Кайбер балага мәктәптә авыр, әмма моны әти-әнисе дә, укытучысы да күрми дә, сизми дә. Гомумән, бу хәлгә битараф калалар. Әмма бу очракта бердәм ярдәм кирәк. Барысын да мәктәпкә өеп калдыру дөрес булмас. Мисал китерә алам: кызым укыган сыйныфта тәртип буенча сораулар туа башлагач, җыелышып гаеплеләрне эзләмәдек, ә ярдәм итү юлларын барладык. Бергәләп әлеге проблеманы хәл итү юлларын таптык. Укытучылар белән хезмәттәшлек итәргә кирәк. «Өйдә ул яхшы, мәктәптә генә начар, димәк, сез гаепле», – дип, көндәшлек тудырырга ярамый. Тәртибе буенча проблемалар булган балаларга вакытында ярдәм итмәсәң, аларда агрессия көчәячәк. Үзен кимсетелгән итеп тоячак. Менә шуннан «Алла» дип язылган битлек киючеләр килеп чыгарга мөмкин, чөнки алар башкалардан үзен өстен итеп күрсәтергә теләячәк.

«Нәнә, ташлыйм гимнастиканы, шөгыльләнәсем килми бүтән!» Бүгенге хәерле иртәм кызымның шушы сүзләре белән башланды. Дәшмәдем. Бозылган кәефемне лапыр-лопыр пешеп утырган дөге боткасына батырырга тырышкандай, ярсый-ярсый болгаттым. «Нәрсә булды тагын?» – дим. Беренче тапкыр гына ишетмим бит инде бу сүзләрне. Бүген бик җаваплы ярышлары – Россия беренчелегенә үтү-үтмәве хәл ителәчәк. Ике атна буе баш күтәрми әзерләнүләре, көненә сигез-тугыз сәгать залда шөгыльләнүләре бушка китәме хәзер бу баланың? Нәрсә турында уйлый ул?





Алсу ШАКИРОВА

Кичә йоклар алдыннан: «Минем белән ятып тор әле», – дип сорады Азалия. «Кызым, 13 яшең тулды бит, синең белән ятыйммы, 3 яшьлек сеңлеңне йоклатыйммы?!» – дип, бүлмәдән чыгып киттем. Белгән булсам, ятмый идемме соң – кичтән үк күңелен ачмакчы булган бу бала югыйсә. Эх, шушы кыя булуларым... «Диңгез булырга! Диңгез!» – дип, күпме төзәтергә тырышам үземне. Татьяна Моринаның шигыре шулай өйрәтте. «Үзгәрәм!» – дип сүз биргән идем аны укыганнан соң.

«Ни булды, кызым?» – дип, Азалия каршына ботка-сын куям. Бөтен борчуларын дулкыным белән юып төшереп, калкып чыкмаслык итеп төпкә батырырга исәп. Башын да күтәрми, күзгә дә карамый кызым. Уен эшмени, нәфис гимнастикага тугыз ел гомерен багышлады. Ташларлык сәбәбе бер түгел, йөз булды инде аның. Шуңа күрә сүзсез дә аңлыйм баламны. «Ярар, кызым, ташласаң да бер сүзем юк. Бүген генә сабыр ит инде. Тренерны мондый четерекле хәлдә калдырып булмый бит, аның да хезмәтен онытырга ярамый. Ничек тә бүгенге көнне үткәрик», – дип, уртак фикергә киләбез. Калганын күз күрер, дим эчтән генә...

# ДИҢГЕЗ БУЛАСЫМ КИЛӘ



Фото: Анна Арахамия

«Мәйданчыкка Аза-а-алия Шаки-и-ирова чакырыла! Казан шәһәре!» Микрофоннан чыккан корылык катыш көр тавыш уйларымны сызып үтте. Тизрәк келәмгә чыгасы кызымны барлыйм. Балам борчылудан дымланган кулларын тренерның киеменә сөртеп киптерде дә, тирән сулыш алып, уң аягыннан келәмгә таба атлады. Тренеры да борчыла: теләк-фатихасы – күзләрендә. Аллаһка тапшырдык!

Келәмнең нәкъ уртасына чыга Азалия. Боҗрасын ике кулы белән тотып, башлангыч ноктасына баса. Бер минут та утыз секунд. Төгәл шушы вакыт эчендә бөтен осталыгын күрсәтеп, мөмкин кадәр күбрәк балл җыярга кирәк. Бер минут та утыз секунд! Бер гомер! Кан басымымның асты өскә килә бугай: йөрәгем туктар хәлгә җитә, уч төпләрем дымлана, аяк-кулларым өши. Йөрәкнең табан астына ни рәвешле төшеп китүен миннән генә сорагыз: бөтен нечкәлекләре белән аңлата алам. Тик соңрак...

Төрле төсле ташлар белән җемелдәп торган купальнигын, баш очына өеп җыйган чәчләрен кабат күздән үткәрәм. Аякларындагы кара янып күгәргән таплары болай күзгә ташланмый икән үзе... «Кызым, көрәшчеләрнең биле сөлге белән кырылып бетә, синең аякларың күгәреп чыга. Сездәге предметлар көрәшчеләрнекенә караганда да яманрак ахрысы», – дип көлә әтисе. Булава төшеп, ике атна күгәреп йөргән күз түгел инде, аякка чыдарга була.

Азалия, келәмдә образ тудырып, испан музыкасына үзенең программасын башкара. «Сөбханаллаһ! Афәрин, кызым! Тот! Ахырга кадәр тот!» – дип, аның һәрбер уңышлы хәрәкәтен хуплыйм. Хөкемдарларны да күзәтергә өлгерәм. Әнә баш хөкемдар аягүрә торып басты, игътибар белән минем кызымны бәяли. Димәк, җәлеп иткән, ошаткан!

Үзенчәлекле спорт төре шул нәфис гимнастика. Монда тышкы кыяфәт, буй-сын, йөзнең матурлыгы, тиз хәрәкәтләнү мөһим. Берсеннән-берсе матур йөзләгән кыз арасыннан игътибарны үзеңә җәлеп итә белергә, көндәшләрдән аерылып торырга кирәк. Безне исә профессиональ спорт юлына тырышлык һәм... акыл алып килде. Гимнастика өчен гәүдә авырлыгы артыграк булган кызымны тренерыбыз Ләйсән

# Бу сүзләрне нинди генә очракларда, нинди генә мәгънә, төсмер кушып кабатламадым икән?!

Рөстәмовна исәпкә дә алмый иде бит башта. Җәйге лагерьдагы тренировкаларның берсендә исә Азалиянең тырышлыгына, тиз отып калу сәләтенә таң калган ул. 6 яшьлек нәни кыз сменадагы бөтен кызлар өчен үрнәк була ул чакта, хәтта олы яшьтәге кызларга да барлык яңа хәрәкәтләрне Азалия күрсәтә. «Нәфис гимнастика белән шөгыльләнүне дәвам итәргә теләсәгез, ябыгырга кирәк булачак», – дип озатты безне Ләйсән Рөстәмовна. 6 яшьлек түм-түгәрәк кызчыктан шушындый буй-сынлы кыз үсәр дип уйлап та карамагандыр ул вакытта тренер. Шул көннән бирле көн саен бергәләп «ябыгабыз»: кызым үзе, мин, тренеры. Әнә келәм артында Азалиянең һәрбер хәрәкәтен кабатлап, уңга-сулга ярым адымнар ясап, алга-артка талпынып басып тора ул. Басып тора дип әйтү дә дөрес булмас. Ләйсән Рөстәмовна да Азалия белән бергә чыгыш ясый сыман.

Уңдык без тренердан. Гомумән, бер-беребездән уңдык. Профессиональ спортта уңышка ирешү өчен тренер–бала–әти-әнинең бердәмлеге бик мөһим икәнен бездән дә яхшы белүче юктыр. Атна саен авылга кайтулар, җәй көне туйганчы ял итүләр, каникул дигән әйбер күптән онытылды инде безнең гаиләдә. Отпускны да Азалиягә көйләп ала башладык. Туган көннәргә йөрү, кунакка барулар да бик сирәк эләгә. Бездә икесенең берсе: йә ярыш, йә тренировка... Азалиягә 7 яше тулган елны онытасым юк. «Кермим залга, өйгә кайтам!» – дип, спорт комплексы ишеге төбендә елап торган баламны ничә тапкыр калдырып китәргә туры килде. Эшкә бер минутка соңга калсаң, аңлатмалар яздырып йөдәтүче җитәкчеләрнең балалары алай көйсезләнмидер шул... Тренеры, чыгып, җитәкләп алып кереп китә иде. Шушы авыр күчеш чоры Азалиянең сәламәтлегенә йогынты ясады, минем дә башымда беренче ак чәчләр шул чакта пәйда булды... Нигә шул вакытта ук туктамадык икән? «Сәләтле бала», «өметле бала», дип, тренерның үсендереп торуы көч бирде, шул өметкә ияреп алга атладыкмы соң?!. Бүгеннән барыбер нокта куям, ди бит менә... Ташлыйм, ди.

Ниһаять, чыгышның кульминацион ноктасы. Азалия бөҗраны аяк очы белән эләктереп, өскә чөеп җибәрде. Бөҗра әйләнеп төшкәнче, өч тапкыр мәтәлчек атып, ике тапкыр әйләнеп өлгерергә тиеш ул. «То-о-о-от!» – дип кычкырам эчтән генә тешне кысып. Нәкъ секундына туры китереп, кызым чыгышын тәмамлый! Басып, хөкемдарларга баш ия дә, келәмнән чыгып китә. Тренерның йөзенә карап кына да чыгышын бәяләргә өйрәнде инде ул. Ләйсән Рөстәмовна җиңелчә генә, Азалия аңларлык итеп кенә башын кагып куйды. Келәм читендә ул аны бер кулы белән кочаклап алды да, залдан алып чыгып китте. Анда алар безнең күзгә күренмәгән, үзләре генә аңлаган хаталар турында сөйләшәчәкләр хәзер. Җиңел сулап куйдым – тренер канәгать калды. Үскән саен кыйммәтләр үзгәрә. Элек медаль өчен тырышып йөргән балага остазының бер мактау сүзе кадерлерәк булган яшькә җиттек.

Ярыш тәмам. Ябык иңнәренә олы рюкзагын, чыгыш киемнәрен, бөҗрасын күтәреп яныма чыгып килүче кызымны каршылыйм. Россия беренчелегенә үтүе – зур җиңү! Шушы яшьтә үзеңне җиңеп алга атлау – җиңүнең тагын да зуррагы. Идел буе федераль округы командасы әгъзасы буларак, үз яше өчен иң дәрәҗәле ярышка юллама җиңел бирелмәде, әлбәттә. «Ярый, тугыз ел йөргән (яратып йөргән дип әйтә алмыйм, төрле чагы булды) нәфис гимнастикага нокта куяр өчен бик матур җиңү», – дип, кызымның иртән әйткән сүзләрен күңелемнән үткәреп, үземне тынычландырам.

Ярыштан соң өйгә кайтканда Азалия, гадәттәгечә, сөйләшми. Бөтен эмоцияләрен, хисләрен келәмдә калдырып чыга ул. Кергәндә бөҗрасын өйгә алып кермичә, машинада гына калдыра – монысына да күптән ияләшкән.

– Кызым, боларны ал инде бүген, өйгә алып кереп урнаштырыйк, – дим. Башка кирәк булмас дигән мәгънә салып әйтәм.

– Калсын, нәнә. Иртәгә кирәк булачак барыбер.

Бер-беребезне аңлар өчен шуннан артык сүз кирәкме... Димәк, миңа диңгез булырга өйрәнәсе әле, ярларны киңәйтәсе! Кирәк чакта җылы дулкын булып күтәреләсе, назлыйсы, тибрәтәсе... Төптән кубып күтәрелгән комнарны, чүпләрне иләп, болганчык суларны тынычландырасы... Өстә нинди генә җилләр уйнаса да, каршы торасы, көрәшәсе икән әле! «Иренмәскә! Тырыш булырга! Бирешмәскә! Дәвам итәргә! Алга барырга! Еламаска! Бар да яхшы булачак! Йөз тапкырдан килеп чыкмаса, мең кабат эшләргә! Нык булырга!» Мин бу сүзләрне нинди генә очракларда, нинди генә мәгънә, төсмер кушып кабатламадым икән?! Дистә елга якын шулай кыя булмасам, бүгенге җиңүләр булыр идеме икән соң?!

Ә кич белән ул миңа тагын бер серне ачты: ярышның баш хөкемдары – Россиянең атказанган тренеры ярышлар тәмамлангач, кызыма: «Мин синең җанатарыңа әйләндем, уңышлар сиңа, Азалия!» – дигән икән. Димәк, юлыбыздан тайпылмыйбыз – күнегүләрне дәвам итәбез әле без! Хыялларыңны тормышка ашыру өчен мин кыя да булырмын, диңгез булырга да өйрәнермен, кызым! Киләсе җиңүләрең хакына. Җиңүләребез хакына!




# ӘЙДӘГЕЗ ХАТЛАР ЯЗЫЙК, ЯҢА ДУСЛАР ТАБЫЙК, БӨТЕН ДӨНЬЯ ТАТАРЛАРЫ БЕЛӘН БЕРЛӘШИК!

*Хатлар йорты – открыткалар җибәрү сервисы*




16+

ООО «Медиа – партнёр» Адрес: 420066, г. Казань, ул. Декабристов, д. 2, пом. 14, ГРН 1111690004469. Реклама

# «МАТУРЛЫК ЭЗЛИМ»

– Мин нигә рәсем укытучысы гына булмадым икән, әлегәчә шуңа аптырыйм...

Лира ханым Яруллина Апас районы Чүрибураш урта мәктәбендә кырык елдан артык рус теле һәм әдәбияты укыта. Әмма буяулар дөньясы һәрвакыт аның күңелендә була. Шуның өчен дә мәктәптә рәсем укытучысы декрет ялына киткәндә бик теләп аның дәресләрен үзенә алып кала. Укучылары шигырьгә тирән анализны... төсләр ярдәмендә ясап, олимпиадалар вакытында жюри әгъзаларын шаккаттыра. Мәсәлән, кемдер өчен кызыл төс – тантана, зәңгәр төс – иркенлек... Хәер, юк, бу темага кереп китсәк, буяуларга тәмам чумарбыз.

Лаеклы ялга чыккач та, мәктәп белән ул бик озак саубуллаша алмый аптырый. Алтынчы дистәне ваклый башлагач та, өч тапкыр язын укучылары белән хушлашып, өч тапкыр көзен кабат классына кире кайта әле. Әмма ул көн барыбер килә. Чабып барган атны туктату кебек була бу. Авыр дию генә аз. Кыңгырау тавышын ишетсә дә, мәктәп янәшәсеннән узса да, күзенә яшь тула. Күңелендәге бу бушлыкны тутырырлык җитди бер шөгыль кирәген аңлый... Санаторийга ялга баргач, Таня исемле рәссам кыз белән таныша. Акварель белән рәсем ясау буенча берничә мастер-классны Лира ханымга ул бирә. Ошый! Тик күңелдә әллә кайчангы хыял бар бит әле – майлы буяулар белән эшләү техникасын өйрәнү. Барысы да нияттән башлана диләрме әле? Шул көннәрдә инстаграмда андый мастер-класслар үткәрүче рәссам Миләүшә Нуруллинага тап була ул.

– Аңа берничә эшемне җибәргән идем. Миләүшә аларны карауга: «Сез ясый ала торган кеше, килегез!» – диде. Мине ул чакта шушы мастер-класслар коткарды. 2019 ел иде ул. Казанга ай саен өчәр көнгә килергә тырыштым. Иртәдән кичкә кадәр аяк өстендә басып торган килеш рәсем ясыйм. Арыйм, билгеле. Әмма аруымны соңыннан гына аңлыйм...

Штрих, ярдәмчел сызыклар, горизонт линиясе, перспектива... Телгә-көнгә яңа сүзләр өстәлә (рәссамнар лексиконы!). Өйгә авыл йорты өчен ят җиһаз – мольберт кайта. Майлы буяу исе тарала.

Гомер буе Алексей Саврасов, Иван Шишкин, Исаак Левитан, Эдуард Мане, Рафаэль Санти, Бакый Урманче, Харис Якупов кебек рәссамнарга, аларның эшләренә тартылу юкка гына булмаган бит инде ул. Кайсы гына шәһәргә юлы төшсә дә, иң элек күргәзмәләр эзләп киткән. Санкт-Петербургның «Русский музей», Мәскәүнең Третьяков галереясы залларында ничәмәничә сәгатьләр уздырган?! Брюллов залында, Саврасовта... Ул рәссамнарның эшләре каршында кабат-кабат озаклап басып тору теләге беркайчан кимеми. Левитанның «Ранняя весна» картинасындагы урынга охшаган җирне үзләренең Чүрибураш авылында да тапкан! Кечкенәдән күңелгә кереп калган әсәр. Әнисе бу картинаның репродукциясен алып кайтып, диварларына элеп куйган булган. Сәяхәт итәргә яраткан әнисе кая гына барса да кызы өчен төрле рәссамнарның эшләре басылган открыткалар җыеп кайткан – сәнгатькә мәхәббәт шулай тәрбияләнгән.

Аның рәсемнәрендә – Чүрибураш авылы табигате: агачлары, күлләре, таулары. Айлы төннәре! «Иң яраткан рәссамнарының берсе – Куинджи», – дигән кеше өчен айны, аның сихри матурлыгын рәсемгә төшерергә омтылу теләге туу гаҗәпмени?!

– Авыл халкыннан мин, бәлки, бераз аерылып торамдыр, – дип елмая ул. – Кая гына барсам да, кулымда һәрвакыт фотоаппарат – фотосурәткә төшерергә яраттым. Хәзер менә урамга чыкканда да кәгазь-карандашны үземнән калдырмыйм. Пләнерга сирәк йөрим, әмма сокланган күренешләрне, төсләрне онытмас өчен, фотога төшереп алырга тырышам. Таң атуын, кояш баешларын карарга – бер мизгелнең икенчесенә күчүен күзәтергә яратам. Шул матурлыкны аннары киндергә күчерергә... Матурлык дигәннән, мин һәрвакыт сурәткә төшерү өчен авылдан элеккеге авылны эзлим. Аны табу шактый авыр бүген. Эшләремне инстаграмга да куйгалыйм. Авылдашлар карап, күзәтеп бара. Беркөнне күршем: «Ирем сине интернеттан күргән. «Лира безнең урам очындагы агачны төшергән, карале, матур икән бит ул», – дип әйтте», – ди. «Лира апа, аккошлар килгән, күрдегезме әле?» – дип туктатты урамда бер механизатор егет. «Лира, салават күпере чыккан, кара әле!» – дип шалтыраталар. Сөенәм андый чакларда, үземне һаман да укытучы кебек хис итәм – матурлыкка минем күз белән карыйлар бит. Улым белән кызым, оныкларым кебек үк!

«Алмазны бриллиантка әйләндерү өчен вакыт һәм тырышлык кирәк. Моның өчен нидер эшләү кирәк!» Лира апаларының укучыларына гел кабатлаган киңәшләренең берсе булган бу. Һәр көн саен хыялыңа бер адым атларга! Менә ни өчен Лира ханым бүген күңелендә үзе кебек яшерен хыялтеләк йөртүчеләргә, аны чынга ашыру өчен киләчәк җиткәнне – лаеклы ялга чыккан көннәрне көтмәгез, ди. «Үзегез өчен вакыт табыгыз. Теләге, омтылышы һәм сәләте булган кешегә, зур шәһәрдән ерак авылда яшәсә дә, теләсә нинди яңа эшкә тотынырга мөмкинлекләр бар бүген. Интернеттан видеодәресләр эзләгез – мастер-класста алып өлгермәгән күнекмәләрне мин үзем шулай тулыландырдым».

Хыяллар исә аның күңелендә җитәрлек. Менә берсе.

Әтисе белән әнисе аерылышкач, алар әниле-кызлы Урта Балтай авылында, мәктәп йортында яшиләр. Авылдан читтәрәк торган, өч тәрәзәле генә иске агач йорт була ул. Тәрәзә каршысында эскәмиясе дә бар. Лира анда чыгып китап укырга ярата. Хыялланырга... Андый чакларда үзен Тургенев әсәрләрендәге кызларның берсе итеп хис итә. Ул чактагы укытучыларның күбесе кебек әнисе белән алар да терлек-туар асрамыйлар, кош-корт тотмыйлар: Лира сөткә авылга йөри. Әнисе кайчак йортлары каршындагы эскәмиягә утырып гармунда уйный, җырлый. Тагын әле ул рәсем дә ясый. Балачакның иң татлы хатирәсе, иң матур күренеше... Ул йорт инде күптән юк. Лира ханым аны бүген кабат җанландырырга тели, бу юлы – киндердә.

Гөлнур ХӘСӘНШИНА

– Рәсем ясау буенча алган мастер-классларлардагы халәтем гел истә. Ап-ак кәгазь алдына килеп басам да, бар дөньямны оныта идем. Хәер, ул хәзер дә шулай. Иртән илһам килгән минутлар була. «Берничә штрих кына өстим», – дип, кылкаләмгә тотынам да, өч сәгать узганын сизми дә калам... Ә ул чакта... Соңгы автобусның Апаска ничәдә кузгаласы да хәтердән чыга. Аннары тагын Казанда куна калырга туры килә... Яшермим, баштагы ике картинамны күчереп кенә ясадым. Австралия рәссамы Грэм Геркенны. Аннан, тәвәккәлләп, үз күңелемдәге хыялларга күчтем. Иң беренче дәрестә үк күк йөзен һәм су өстен ясарга яратканымны аңладым. Озаклап, онытылып, тәмләп ясыйм... Укытучы яныма килә дә, аптырап: «Сез әле һаман да күктән китә алмадыгызмыни?» – дип сорый иде.

Фото: Анна Арахамия

# «БАШКАЧА ЯШИ БЕЛМИМ...»



Нарасыйның дөньяга тәүге кат аваз салуы – ана өчен дә, бу минутларда янәшәдә булган табиблар өчен дә зур бәхет! Соңгылары өчен икеләтә дә куаныч, чөнки табиблар баланы гына түгел, ананың сабыена баккан, алҗыган, әмма бәхетле күзләрен дә күрә. Ике гомер өчен җавап тотарга кирәген белеп киләләр акушер-гинекологлар сафына. Олы һәм көчле йөрәклеләр генә әлеге үтә җаваплы эшкә алынадыр. Болай да дары мичкәсе өстендә утыргандай эшләгән акушерлар өчен соңгы ел үтә катлаулы булды. Чөнки тормыш ике өлешкә бүленде: коронавирус инфекциясенә кадәр һәм ковидлы чорга. Җаваплылык берничә тапкырга артты. Сәламәтлек саклау министрлыгының штаттан тыш баш акушер-гинекологы, Казан шәһәренең 7 нче клиник хастаханәсе баш табибының акушер һәм гинекология буенча урынбасары Татьяна **ШИҺАБЕТДИНОВА** белән шушы хакта сөйләшәбез.

## *Ковидсыз тормыш*

**Татьяна Николаевна, һәр яңа туган сабыйны кулыгызга алгач, нинди хисләр кичерәсез?**

– «Дөньяга төкле аягың белән кил, сабый!» Аңа әйткән беренче сүзем шушы. Ул сау-сәламәт булып, тууга бөтен дөньяга аваз сала икән, моннан да зур шатлык юк. Шатлык белән бергә миндә горурлык хисе дә туа. Синең ярдәмең белән җиргә яңа кеше килә! Ул әлегә ярдәмгә мохтаҗ. Аның гомере өчен синең җаваплылыгың да әти-әнисенекеннән ким түгел. Шуңа күрә дә хаталанырга хакың юк!

**Сез табиблар династиясеннән түгел – әти-әниегез башка һөнәр ияләре. Киләчәктә ак халатлы фәрештә булырга кем этәргеч бирде?**

– Мин кечкенә чакта әтием Казан шәһәренең Киров районын җитәкләде. Казан балалар неврологиясе мәктәбенә нигез салган профессор Александр Ратнер янына эше буенча еш кереп йөри иде ул. 5 яшьләр булгандыр, берсендә мине дә үзе белән алды. Алар сөйләшкәндә әтидән шыпырт кына: «Миңа хастаханәне карарга ярый микән?» – дип сорадым. Моны профессор ишетеп алып, махсус кечкенә ак халат табып, шәхсән үзе хастаханәне күрсәтте. Анда бөтен Советлар Союзыннан балалар дәвалана иде. Ул хастаханәдә кичергән тәэсирләремне һич онытасым юк... Нәкъ менә шушы вакыйга киләчәктә нинди һөнәр сайлавымны билгеләде дә. Беренче сыйныфка барганда тәгаен белә идем: мәктәпне тәмамлыйм да, табиб булырга укыячакмын! Мәктәптә санитар дружина җитәкләдем. Тугызынчы сыйныфта укыганда әтине партия кушуы буенча Каракалпак Республикасына эшкә җибәрделәр. Укуымны үзбәк мәктәбендә дәвам итәргә туры килде. Көзен бездә балаларны «бәрәңгегә» җибәрсәләр, анда мамык җыярга йөртәләр иде. 53–55 градус челләдә 60–70 килограмм мамык җыярга кирәк. Ә мамык бит ул бик җиңел! Бервакыт классташ кызым эсседән һушын җуеп егылды. Югалып калмадым, беренче медицина ярдәме күрсәттем. Ашыгыч ярдәм табиблары: «Син сыйныфташыңны коткарып калгансың», – диделәр. Уңыш җыеп бетергәч, мәктәптә линейкада Каракалпакның Сәламәтлек саклау министры тантаналы төстә миңа рәхмәт белдерде. Бу очрак балачак хыялымны тагын да ныгытты. Мәктәпне алтын медаль белән тәмамлап, Мәскәү медицина институтына укырга керергә имтиханнар бирдем, әмма бер балл җитмәде. Кайттым да Нукус медицина училищесына укырга кердем. Ул арада әтине кабат Казанга күчерделәр. Казан медицина училищесын кызыл диплом белән тәмамлап, Казан дәүләт медицина институтына дәвалау эше бүлегенә укырга кердем. Нигә нәкъ менә акушер-гинекологияне сайладыммы? Кабат янәшәмдәге кешеләр тәэсиредер. Каракалпакта күршеләребез – ирле-хатынлы табиб Ширлановлар гаиләсе бар иде. Әниләре дә, кызлары Чулпан да акушер-гинеколог. Алар белән бала тудыру йортына төнге кизүгә дә, операцияләргә дә йөрдем. Нәкъ менә шушы гаилә миңа акушерлык дөньясына юллама тоттырды. Алар белән баланың дөньяга туу шатлыкларын тойдым, алар белән бергә бу һөнәрнең аеруча җаваплы булуын аңладым. Минем дә хатын-кызларга ярдәм итәсем килде. Дүртенче курста Казан дәүләт медицина университетының В. С. Груздев исемендәге «Медицина университеты» клиникасының бала тудыру йортына субординатурага килдем һәм шунда 23 ел эшләп, зур республикабызның акушер-гинекология хезмәте җитәкчесе дәрәҗәсенә күтәрелдем. Анда минем укытучыларым, остазларым, кандидатлык диссертациямнең фәнни җитәкчесе. Алар барысы да үз вакытларын, көчләрен җәлләмичә, мине укыттылар, ярдәм иттеләр, һәрвакыт теләктәшлек күрсәттеләр. Һөнәремне чын күңелемнән сайладым. Биргән Гиппократ антыма тап төшермим, көчемнән килгәнчә кешеләргә ярдәм итәргә, яхшылык эшләргә тырышам.

**Димәк, һөнәрегез ул сезнең өчен эш кенә түгел?**

– Юк, ул Ходайдан бирелгән сәләт тә. Һәрвакыт кешеләргә ярдәм итәсем килә. Бу инде тормышның мәгънәсе. Башкача яши дә алмыйм, яши белмим дә. Нәкъ менә шуңа күрә һаман алга барам. Һөнәремне ярату көч һәм саекмас энергия бирә.

## *Коронавируслы тормыш*

**Акушер-гинеколог эшен тыныч хезмәт дип атап булмый. Һәр яңа сәгать кенә түгел, минут-секунд эчендә көтелмәгән хәлләр килеп туарга мөмкин. Узган ел илдә коронавирус зәхмәте башлангач, табиблар беренчеләрдән булып әлеге чир белән күзгә-күз очрашты – көрәштә алгы фронтта булды. Инфекция авырлы хатыннарны да аямады. COVID-19 чорында Татарстанда авырлы хатыннарга медицина ярдәме күрсәтү ничек оештырылды һәм пандемия чигенсә дә, ул алгоритм әле эшлиме?**

– Узган ел февраль ахырында башкаланың 7 нче шәһәр клиник хастаханәсендә авырлы хатыннар өчен инфекцион бүлек оештырылды. Без шул көннән башлап салкын тиюнең һәр очрагын яңа коронавирус инфекциясе түгелме дип тикшерә башладык. Башта әлеге авыру авырлы хатыннарны читләтеп узар кебек иде, әмма алай булмады. Коронавирус эләктергән авырлы хатыннарның хәле ике сәгать эчендә кискен үзгәрергә мөмкин. Татарстанның Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан махсус приказ әзерләнде. Барлык үзәкләрдә булачак аналар өчен инфекцион бүлекләр оештырылды. Приказда әлеге авыру белән көрәш өчен бөтен чек-листлар җентекләп язылган иде. Көмәннәре 22 атнага кадәр булганнар – 7 нче хаста-





Авырлы хатыннарга салкын тиюнең һәр очрагы коронавирус инфекциясенә тикшерелә.

ханәгә, аннан зуррак сроклылар Республика клиник хастаханәсенең Перинаталь үзәгенә җибәрелде. Авыру йоктырган барлык булачак аналар бары тик шушы үзәктә генә бала тапты. Тәгаенләп әйтә алам: бу көннәрдә бер авырлы хатын да игътибардан читтә калмады. Алар өчен «виртуаль обход» оештырылды. Бу эшне сәламәтлек саклау министры Марат Садыйков үзе җитәкләде. Ул нидән гыйбарәт соң? Мессенджерда махсус төркем булдырылды. Анда министрлыкның штаттан тыш барлык баш белгечләре, министр урынбасарлары, профессорлар составы, баш табиблар кертелде. Барысы йөздән артык белгеч җыелдык. Хәле катлаулырак булган һәр йөкле хатын буенча мәгълүмат тиз арада «виртуаль обход»ка куелып, фикер алышулар булды. Билгеле бер карарга килгәннән соң, авыруга махсус югары сыйфатлы ярдәм күрсәтер өчен, тиз арада хастаханәгә күчерелде. Бу эш режимы тәүлек әйләнәсендә барды: мөрәҗәгать була икән, төнме, көнме шунда ук киңәшләшә башлый идек. Консилиумнар онлайн гына түгел, офлайн да барды. Мәскәү белгечләре белән дә элемтәгә керүләр шактый булды. Кайбер пациентка унбишәр консилиум уздырдык. Шундый катлаулы режимда без инде бер ел эшлибез. Кирәк икән, консилиумнарны «кызыл зона»да да җыябыз. Барлык очраклар Коронавируска каршы республика штабы җитәкчесе, вице-премьер Ләйлә Фазлыева, сәламәтлек саклау министры Марат Садыйков контролендә булды. Кеше гомере өчен көрәшкәндә регалияләр дә, дәрәҗәләр дә онытыла. Без барыбыз да табиблар. Тәүлегенә өч-дүрт сәгать кенә йоклаган, хәтта төне буе күз йоммаган вакытлар да күп булды. Әлеге алгоритм хәзер дә, коронавирус бераз тынычлангач та, эшли.
Һәр кискен респиратор вирус инфекциясе тикшерелә. Приказны беркем дә гамәлдән чыгармады – тынычланырга әле иртәрәк...

**Коронавирус эләктергән авырлы хатыннар үз гомерләреннән битәр, туасы балалары өчен борчылгандыр, чөнки баштагы вакытта инфекциянең үзен ничек тотачагын беркем белми иде. Дәвалаудан тыш, аларны тынычландыру бурычы да торгандыр сезнең алда.**

– Шуның өчен дә «кызыл зона»да психологлар эшләде. Булачак әниләр белән рәсем ясадык (арт-терапия тынычландыру өчен бик яхшы алым), сөйләштек. Чирне җиңүебезгә ышанып эшләдек. Пациентлар белән һәрвакыт элемтәдә тордык. «Мин кызыл зонада» дигән уй да кешегә психологик яктан бик нык басым ясый. Булачак аналарны аңларга була. Йөрәк астында сабые, ә шуңа өстәп һава да җитми башласа... Алар белән барлык профильдәге табиблар эшләде, янәшәләрендә булды. Әлбәттә, авырлы хатынның үпкәсенә ясалма вентиляция кушкач, борчылу бермә-бер арта. Һәрбер очрак турында Мәскәүгә Кулаков исемендәге гинекология һәм акушерлык үзәгенә хәбәр итеп тордык. Алар безнең белән тәүлек әйләнәсендә элемтәдә булды. Авыруны халык теле белән әйткәнчә, «торбадан төшергәч», ягъни үзе сулый башлый, шатлыкка чикләр юк иде. Авыру кичергән анадан туган һәр баладан тиз арада анализлар алдык. Шунысы куанычлы, республикада яңа туган бер генә сабыйда да коронавирус инфекциясе ачыкланмады. Әлбәттә, «кызыл зона»да фаҗигале минутлар да булды. Кулыңнан килгәннең барысын да эшләп тә, булачак ананың гомерен коткарып кала алмавыңны аңлау бик авыр. Әле ничек кенә авыр! Чарасызлыгыңны тоеп торсаң да, соңгы минутка кадәр нидер эшләргә, кабат-кабат ярдәм күрсәтергә тырышасың. Һәр очрак Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгының Координацион советында каралды, Мәскәү тикшерде.

**Коронавирус инфекциясенә ышанмаган авырлы хатыннар да булдымы?**

– Кызганыч, андый очраклар да булды. Шундый авырлы хатынны югалттык та. Ул инфекциягә ышанмаган, үз белдегe белән дәваланган. «Мин бары тик грипп белән генә авырыйм», – дип йөргән. КТ (компьютер томографиясе) үтүдән дә, хастаханәгә ятудан да баш тарткан. Хәле бик авыргайгач кына, соңлап мөрәҗәгать итте ул безгә. Барлык тиешле ярдәмне күрсәттек, әмма... Шуннан соң Казан дәүләт медицина университеты профессоры Рушания Габидуллина белән, үзбелдекләнеп дәваланмаска, вакытында дәвалау учреждениеләренә барырга чакырып, хатын-кызларга матбугат аша мөрәҗәгать белән чыктык. Гади генә томау төшсә дә, сагаерга кирәклеген әйттек.

**Табибның эш көне сәгатьтән сәгатькә генә төгәлләнми. Төнге кизүләр, планлаштырылмаган очраклар бик күп. Ә пандемия вакытында аларга, гомумән, хастаханәдә яшәргә туры килде. Миңа калса, табиблар өчен гаилә кыйммәтләре аеруча мөһим. Тылың көчле булмаса, тынычлап эшләп булмый. Бигрәк тә сезнеке кебек үтә дә җаваплы эштә...**

– Гаиләдә мәхәббәт һәм дуслык хакимлек итәргә тиеш. Әлеге хисләрне миндә әти-әнием тәрбияләде. Мәхәббәт белән дуслыктан кала, бар нәрсәне сатып алырга мөмкин, дип әйтә эти. Гаиләмнән уңдым. Пандемия елында бу тагын бер кат расланды. Әйткәнемчә, тәүлегенә 24 сәгать, атнасына җиде көн эшләгән вакытлар күп булды, әмма өйдәгеләрнең терәген тоеп эшләдем. Пандемия башланган вакытта инфекциянең ниндилеген белмәдек.
Ә белмәгән әйбер куркытты. Өйдән чыгып киткәндә кире әйләнеп кайтачагыбызга, авырмаячагыбызга беркем гарантия бирмәде. Моны, билгеле, якыннарым да аңлады һәм эчтән генә борчылды. Әмма беләләр: мин хатын-кызларга ярдәм итәргә тиеш. Бу – минем бурычым. Гаиләмнең теләктәшлеген тойганга сыгылмаганмындыр.

Мин генә түгел, барлык табиблар да гаиләләренең ышанычын тоеп эшләде. Балаларым өчен дә җаным тыныч иде. Ике кызым бар. Олысы инде зур, ә төпчек кызыбызга 8 яшь кенә әле. Кечкенә булса да, ул да минем авырулар янәшәсендә булырга тиешлегемне аңлый. Аның белән видеошалтырату аша аралашып тордык. Сагынса да, күз яшен күрсәтмәде, сабыр итте. Янында һәрвакыт әтисе, әби-бабайлар булды. Әле бит өйгә кайткач та тыныч кына яшәп булмый, без һәрвакыт элемтәдә – кулдан телефон төшми. Гаиләмдә монысын да аңлыйлар.

**Коронавирус күпләрне үзгәртте, диләр. Сезне үзгәрттеме ул?**

– Әлбәттә, мин дә тормышка башкача карый башладым. Гаиләм тагын да бердәмрәк хәзер. Без болай да бик тату яши идек. Ял итәргә дә иремнең әти-әнисе, минем әти-әниләр һәрвакыт бергә бардык. Ата-аналарыбызга булган хөрмәтне, кайгыртуны балаларыбыз күреп үсә. Өлкәнәйгәч, алар да безгә карата миһербанлы булырлар. Якыннарымның кадере тагын да артты. Буш вакытларымны бары тик гаиләмә багышлыйм. Нинди генә тыгыз режимда эшләсәм дә, кичен кызымны тренировкаларга йөртерлек итеп вакытымны көйләргә тырышам. Аның белән үзем дә тимераякка бастым. Балаң белән бергә бозда шуу мизгелләре әйтеп бетергесез рәхәт ул. Тормышның, гомернең кадерен тагын да ныграк белергә өйрәндем кебек. Мин болай да: «Һәр көн – бәйрәм», – дип яшәүчеләрдән. Әлеге фикерем хәзер тагын да ныгыды. Эшемдә иң авыр ел булды бу. Шәхси тормышымда да иң кайгылы елым – әниемне югалттым. Иртәнге җидедә эшкә килеп, «кызыл зона»га керергә әзерләнгәндә аның үлеме турында хәбәр иттеләр. Сыгылып төшәргә хакым юк иде. Бар борчуым йөрәгемдә булды.

**Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгының штаттан тыш баш гинекологы буларак, Сез республикадагы барлык авырлы хатын-кызлар өчен җавап тотасыз. Авыр йөкме бу?**

– Әлбәттә, бу бик зур җаваплылык. Әмма Татарстанның акушер-гинекология хезмәте командасы көчле. Барлык белгечләр, профессорлар составы белән бердәм эшлибез, бер-беребезгә ярдәм итәбез, теләсә кайчан җыелып фикерләшәбез. Бер кеше генә бу йөкне алып бара алмый, билгеле. Бүгенге уңышларыбыз өчен командадагы һәркемгә рәхмәтлемен.

**Татьяна Николаевна, акушер-гинеколог эшчәнлегегезгә быел чирек гасыр була. 25 ел эшләү дәверендә истә калган иң куанычлы һәм иң борчулы очракны исегезгә төшерегез әле.**

– Һәр авырлы хатынның үз язмышы. Алар өчен бала табу гомерендәге иң зур вакыйга. Бер очрак та бер-берсенә охшамаган. Әлбәттә, сәламәт туган һәр бала шатлык. Шуңа күрә аларны аерып карап та булмыйдыр. Иң авыры – өметсез пациентлар. Чарасызлыктан елыйсың андый чакта...

**Табиблар да елыймы?..**

– Әйе, без дә бит кешеләр... 2019 елның 24 ноябре иде ул. Әниләр көне... Кичен авыр хәлдәге авырлы хатынны алып килүләре турында хәбәр иттеләр. Мөселман канунары буенча яшәгән гаиләнең дүрт баласы бар. Иң кечкенәсенә тугыз ай. Пациент организмындагы тормыш эшчәнлеге өчен җаваплы өч системага да зыян килгән. Реанимациядә бик озак ятты ул. Исән калуына мөмкинлекләр бик аз иде. Ул гаиләдәге бердәмлеккә, мәхәббәткә, җылы мөнәсәбәткә барыбыз да сокландык. Өметнең азлыгын аңлаганга, әнисенә аның янында булырга рөхсәт иттек. Ул кызына изге китаптан дога укыды да, дога укыды... Әтисе, ире һәрвакыт яныма кереп йөрделәр. Әле дә хәтерлим, профессор Рушания Габидуллина белән: «Кулдан килгәннең барысын да эшләдек. Исән калуына өмет бик аз, бары тик ике процент кына», – дидек. Табиб өчен мондый сүзләрне әйтү бик авыр... Иренең кулында Коръән, елый-елый: «Мин сезгә ышанам. Аңа ярдәм итәрсез дип өметләнәм», – ди... Бу минутта күз яшьләрен тыеп торып буламы?! Әлеге ханымның гомере өчен көрәш республика дәрәҗәсендә барды. Вице-премьер Ләйлә Фазлыева, министр Марат Садыйков ярдәмендә Мәскәүдән махсус полимиксиналы колонкалар (кан чистарта торган медицина җиһазы) кайтартылды. Медицинадагы заманча технологияләр, хастаханәнең югары квалификацияле белгечләре ярдәмендә ана гомерен саклап кала алдык. Бу очрак, һичшиксез, гомергә исемдә калыр. Ике ай ятты ул хатын хастаханәдә. Хәзер дә аралашып торабыз. Кызым өчен борчылган кебек борчылдым аның өчен. Яшь табибларга: «Пациентка дәвалау курсы билгеләгәнче, аның урынына кызыгызны, апагызны, сеңлегезне, якын кешегезне куеп карагыз, шул вакытта гына аңа карата мөнәсәбәтегез башкача булыр. Туганыгыз кебек кабул итәрсез», – дим.

**Республиканың Коронавируска каршы көрәш штабы башлыгы, вице-премьер Ләйлә Ринатовна белән бергә күп тапкырлар матбугат очрашулары, туры элемтәләр үткәрдегез. Нәтиҗәләре бармы?**

– Күпчелек халык әлеге авыруның бик мәкерле булуын аңлады. Бик күп хатын-кызлар алдан җентекләп әзерләнеп авырга уза хәзер. Махсус тикшеренүләр узалар, прививка ясаталар, битлекләр киялэр. Үзләре генә түгел, якыннары да. Бала табарга планлаштырган хатын-кызларга ярты ел алдан коронавируска каршы прививка ясатырга киңәш итәбез. Әйе, шикләнеп караучылар юк түгел. Әмма исегездә булса, 7–10 ел элек авырлы хатыннар гриппка каршы прививка ясатудан да курка иде, хәзер ул прививкалар календарена кертелде, чөнки күрәбез: вакцина ясатканнар авыруны җиңел кичерә. Авырга узу, йөклелек – хатын-кыз тормышындагы иң әһәмиятле чор. Моны аңлап, зур җаваплылык белән карасыннар иде!

**Татьяна Николаевна, татар халкында бәбиләүче хатын-кызларга элегрәк кендек әбиләре ярдәм иткән. Бу исемне хәзер акушер-гинекологлар йөртә. Сез менә үзегез ничә баланың кендек әбисе икән?**

– Биш ел элек санаганда 5 мең бала иде. Хәзер инде исәп-хисапны югалттым... Шунысы сөенечле: туарга ярдәм иткән балалар үсеп, үзләре миңа бала табарга килә. Димәк, кешелек алга бара!

Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА

# ҮҖӘТ АЛИШӘНЕҢ ИЛҺАМЧЫСЫ

**Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры актрисасы Алинә Мөдәрисова кечкенә дә төш кенә булса да, сәхнәдә ут яндыра. «Ак калфагым төшердем кулдан», «Сүнгән йолдызлар», «Өйләнәм. tat», «Хуш, авылым», «Килә ява, килә ява», «Исәнмесез!?.», «Гөргөри кияүләре» кебек спектакльләрдә бер-берсенә охшамаган образлар иҗат итә. Әле урынында тик тора белмәгән бала ул, әле хисләр ярсуына бирелгән хатын, әле гомер иткән әби. Сәхнәдә бөтерчек кебек Алинә тормышта бик тыныч, балаларча самими, хәтта оялчан. Әнә шул сыйфатлары кечкенә рольләрен дә онытылмаслык итәргә ярдәм итәдер, мөгаен.**

**Алинә, без барыбыз да балачактан, диләр. Балачактагы иң бәхетле көннәреңне искә төшер әле.**

– Мин зур, тату гаиләдә үстем. Без өч кыз һәм бер малай. Барыбыз да иҗат кешеләре. Икенче сеңлем Раушания Ижауда ансамбльдә бии. Өченче сеңлем Җәмилә Константин Хабенский театр студиясендә шөгыльләнә. Аңа зур өметләр баглыйбыз. Энем Бәхтиярга әле 8 генә яшь. Әтием Рушат Мөдәрисов Башкортстанның халык артисты, «Нур» театры актёры. Мин сәхнә артында үстем. Беренче ролем 3–4 яшьтә Фәрит Бикчәнтәев куйган спектакльдә. Карале, беренче режиссерым да ул булган икән бит! (*Елмая.*) 10 яшемдә «Нур» театрында миңа төп роль бирделәр. Салават Юлаевка багышланган «Гөлбәзир» спектаклендә Гөлбәзир роле иде ул. Салават Юлаевның өченче хатынын уйнадым. Режиссер Илдар абый Вәлиев бик усал иде. Рольне елыйелый өйрәндем. Күз яшьләрем белән әтием янына килгәч: «Минем янга елап килмә. Үзең сайлаган юл», – диде. Шул вакытта җәлләвен күрсәтмәгәне өчен рәхмәтле аңа. Бу роль белән Башкортстан артистлары арасында үткәрелгән бәйгедә «Яңа исем» номинациясендә җиңеп чыктым.



«Күңелле әлифба» видеопроектының бер сериясен, QR-код аша кереп, видеодан карый аласыз.







**Алинә, сиңа дусларың Алишә, диләр? Ни өчен?**

– 13 яшьтән мин тхэквондога йөри башладым. Максат куям икән, ирешми калмыйм. Иртә-кич шөгыльләнеп, ике ел эчендә Россия беренчелегенә барып, кара билбау алып кайттым. Үҗәт мин! Тренерым: «Телефонда Алинәләр күп, сине Алишә дип язып әле», – дип сорады. Мин риза булдым һәм шуннан Алишәгә әйләндем. Күп кеше хәзер шулай дип атый.

**Укып бетергәч, Әлмәт театрында эшләдең. Казанга кире кайтуның сәбәпчесе ирең Алмазмы (*Камал театры актеры Алмаз Гәрәев – Г. Ч.*), әллә театрмы?**

– Казан театр училищесында Фәрит абый Бикчәнтәев курсын тәмамлагач, Әлмәткә чакырдылар да, шунда киттем. Камалга Фәрит абый мине алмады. Әлмәт Татар дәүләт драма театрында уйнаган елларым – яшьлегемнең иң күңелле чоры. Төрле рольләр, гастрольләр, хәтта үзем спектакль чыгардым. Ике елдан соң Фәрит абый: «Давай, кайт», – диде. Көтелмәгән тәкъдим булды ул. Ниятләдем. Казанда театрдан кала, Алмаз да бар иде бит әле. Аны күптән беләм. Училищеда укыганда гел Камал театрында булдык. Минем янга килә иде дә: «Сине кочакласам буламы?» – дип сорый иде. Шулай биш ел кочаклап йөрде ул. (*Рәхәтләнеп көлә.*) Әлмәткә китеп, бер елдан соң күрешкәч: «Бу егеткә кияүгә чыгар идем», – дип уйладым. Әмма Казанга кайтуым, күпләр уйлаганча, Алмаз аркасында түгел. Мине Фәрит абый актриса буларак чакырды, һәм үкенми дип өметләнәм.

**Видеоролик төшергәндә күзәттем: Алмазга бик хөрмәт белән, сокланып карыйсың. Синең өчен ул үзе бер дөнья кебек. Гаиләдә гармония. Ә сәхнәдә? Ирең белән бергә эшләве авыр түгелме?**

– Киресенчә, бик рәхәт. Алмаз: «Син иң чибәр һәм сәләтле актриса», – дип рухландыра. (*Уйланып.*) Ул миңа дөнья мәшәкатьләрен оныттырып, сәхнәдә иҗат итәргә мөмкинлек биреп яши. Күз алдыгызга китерегез, бер айлык Зөбәйдәне алып калып, мине репетицияләргә җибәрде ул. Баланы имезергә генә алып килеп йөрде. Бу рольнең кирәклеген аңлый иде... Алмазга бик рәхмәтлемен.

**Аңлавымча, бала тәрбияләүдә Алмаз зур роль уйный. Зөбәйдә бит әле әтисе белән «Татмедиа Junior» проекты кысаларында «Салават күпере» журналы әзерләгән «Күңелле әлифба» таптышыруын алып бара. Ул – иң уңышлы проектларның берсе...**

– Әтисе белән булгач, булдыра инде Зөбәйдә. Алмаз аны җайлый да, эшләтә дә белә. Ул – әти кызы! Аның тел байлыгы да Алмаздан. Бик ошый Зөбәйдәгә алып баручы булу. Ә мин горурланам. Зөбәйдәне «Күңелле әлифба» аша таныйлар. Хәтта фанатлары барлыкка килде, диләр тапшыруны әзерләүчеләр. Балалар бик яратып карый. Ул бит белемгә мәхәббәт уята торган проект. Кечкенәләргә хәрефләрне кызык итеп истә калдырырга ярдәм итә.

**Зөбәйдә елмаеп кына тора. Димәк, бик бәхетле бала. Бала тәрбияләүдә нәрсә мөһим дип уйлыйсың, Алинә?**

– Бәхетле әти-әни генә бәхетле бала тәрбияли ала. Гаиләдә мәхәббәт булырга тиеш. Бала күңеле бик сизгер ул! Без гел бергә. Кочаклашу, сыйпау-назлауларны яратабыз. Үзем дә шундый гаиләдә тәрбияләндем. Шуңа да балалыгым да чыгып бетмәгәндер, күрәсең.

**Сәхнәдә бала образларын да искиткеч оста, истә калырлык итеп ача алуыңа ярдәм итәдер ул, әйеме?**

– Әйе шул, мин бала кебек – тиз ышанам, дөньяга ачыкмын. Шуңа балалар образын бик җиңел тудырам. Сәхнәдә уйнаганда күңелемдәге бала тантана итә. Бала рольләрен буем кечкенә булганга да бирәләрдер.

**Сәхнәдә чәчрәп торган Алинә пәрдә артында нинди?**

– Сәхнәдә эмоцияләрем чыгып бетә бугай. Тормышта мин бик тыныч. Күз өстендә каш булып йөрергә яратмыйм.

Текст: Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА.
Фото: Анна АРАХАМИЯ. Видео: Фәнис САДЫЙКОВ.
Видеоны карар өчен смартфонның камерасын QR-кодка якынайтыгыз.



РЕКЛАМА ХОКУКЫНДА




УРТАК ПРОЕКТ




# САЛИХОВЛАР УТАРЫНДА



Эльмира
ЗАКИРОВА

**Бу гаилә турында кыскача гына «Теләче» район газетасындагы коллегалардан ишеттек. «Салиховлар – бөтен Теләчегә атаклы нәсел. Белмәгән кеше юк аларны. Чып-чын татар гаиләсе!» – диделәр. Сөйләүләренә караганда, гаилә башлыгы Наис Хәйдәр улы, бөтенесен нульдән башлап, заманында районда үзе «Агропромснаб» оештырган кеше икән. Хатыны Зәйтүнә гомер буе хастаханәдә өлкән шәфкать туташы булып эшләгән. Уңган-булган өч малай үстергәннәр. Хәзер оныклар белән мәш киләләр. Ә менә дәү әтиләре Хәйдәр ага – республикада даны таралган Ленин исемендәге тәҗрибә-җитештерү хуҗалыгының алыштыргысыз баш инженеры булган. Бабайга 85 яшь тулган инде, ә ул һаман руль артында джипта җилдерә, ди! Гармунда сыздырып уйный, китаплар укый, Мишә елгасында моторлы көймәдә балыклар тотып йөри, ди!**
**Шулай ымсындырдылар. Һәм без Теләчегә юл тоттык. Буыннар чылбыры ныклыгын, хезмәт яратып үскәннәрнең уңышлар яулавын, гаилә традицияләренең ничек саклануын бер гаилә мисалында күрсәтәсебез килде.**









Фото: Анна Арахамия

## *Атасы кем – углы шул*

Башта, әлбәттә, Наис Салиховка шалтыраттым.

«Сез – дүрт буын Салиховлар – бер оя булып яшәп ятасыз икән, Наис Хәйдәрович, – дим. – Әби-бабай, уллар һәм киленнәр, оныклар һәм сез үзегез...

– Безнең кызларыбыз да бар әле! – ди ул, шаккаттырып. – Тәрбиягә алган кызларыбыз... – дип, ачыклык кертә.

...Теләчегә керү белән уң кулда – автомагазин. Ни генә юк анда! Фильтрлар, электрика, «дворник»лар, коврикләр, шөрепләр, майлар... Салиховлар кибете ул. Бүгенге көндә ирле-хатынлы шунда эшләп яталар.

Наис гаилә белән таныштыруны әти-әнисеннән башларга булды. Һәм без болыннар, басу юллары аша элеккеге Ленин исемендәге тәҗрибә-җитештерү хуҗалыгы булган Үзәккә җилдердек. Наис (ул Наис Хәйдәрович дип эндәшүне кабул итеп бетермәде, безнең халык алай сөйләшми бит, ди – *Э. З.)* Үзәк, Сауш, Шармыш, Алга, Петровский авылларын берләштергән данлыклы совхоз, аның атаклы кешеләре турында сөйләп бара. «Бөтен Татарстанга билгеле хуҗалык иде заманында. Социалистик Хезмәт Геройлары Гөлбикә Кәримова, Габделхак Галиевлар безнеке бит!» – ди. Әтиләре Хәйдәр абый шушы хуҗалыкта баш инженер булып эшләгән. Чыгышы белән Иске Җөридән икән. Гаиләләре белән 1948 елда Үзәккә күчеп килгәннәр. Хәйдәр 16 яшеннән тракторга утырган. Техникага әвәс егет гел машиналарга тартылган. Армиядән кайткач, Мамадышта шоферлар әзерләү курсында укыган. Машина да йөрткән, механик та, гараж мөдире дә булып эшләгән. Энесе Миңнехаҗи белән Горькийда (хәзер Түбән Новгород – *Э. З.*) автомеханиклар техникумында укып кайткач, Хәйдәр Салиховны баш инженер итеп куйганнар. «Без өч малай үстек, өчебезгә дә машина җене кагылган иде. Әтидән күчкәндер инде, – ди Наис. – Ул безгә бәләкәй чакта ук «Урал» мотоциклы алып бирде дә, мин, Илдар, Илгиз – өчәүләп малларга печән ташып, урман-кырларга чыгып, дөнья гизеп йөри идек. Рәхәт чаклар... – дип сагынып куя ул. – Илдар юк инде арабызда...» – дип, юл һәлакәтендә һәлак булган энесен сагышланып искә ала.

Наис Салихов Чистай авыл хуҗалыгы техникумыннан соң, Ленин исемендәге тәҗрибә-җитештерү хуҗалыгында инженер булып эшләп ала. Читтән торып Казан авыл хуҗалыгы институтының механика факультетын тәмамлый. Җитәкчелек серләрен туган ягында эшләгәндә һәм армия сафларында хезмәт иткәндә үзләштергәндер. Кытай чиген саклаган егет армиядән старшина дәрәҗәсендә кайта. Оештыру сәләте, әлбәттә инде, әтисеннән дә киләдер. Яңадан торгызылган Теләче районында базар икътисадына күчү елларында «Агропромснаб» дигән оешма оештырып җибәрә. Механика өлкәсендә судагы балык кебек йөзә чөнки. Административ бина, складлар, ягулык саклау станциясе төзеп җибәрәләр, кибет ачалар, эшчеләргә фатирлар төзиләр. «Агропромснаб» хуҗалыкларны яңа техника, запас частьлар белән тәэмин итә. Ат арбасыннан башлап нәни шөрепчекләргә кадәр бар аларда, диләр. Бартерга да эшлиләр, товар кредитына да...

## *Төп йортта*

...Ул арада Хәйдәр абыйлар капка төбенә килеп туктадык. Өй каршында – яшел болын. Тәрәзәләрдән гөлләр елмая. Хуҗа кешегә 85 яшь дип кем әйтер! Мишәгә балыкка төшү турында сүз кузгата, хоккей уены җанатары буларак, Гагарин кубогына узган матчларга бәя бирә, дөнья хәлләренә күчә... «Эшләгән елларымны әле дә онытып бетермиләр, рәхмәт яугыры. Юбилеема бик күп котлаулар килде. Хакимият башлыгы үзе килеп Рәхмәт хаты тапшырды. Авыл хуҗалыгы министрлыгыннан да Мактау грамотасы җибәргәннәр иде», – дип, сөенече белән дә уртаклашып ала.

Дания апа куе чия төсендәге камзулдан, аңа төстәш калфактан. Елмаеп сөйләшә. Нindидер затлылык бөркелә үзеннән... 40 ел кибеттә эшләгән ул. Фотосы районның Мактау тактасыннан төшмәгән.

– Бабай белән мал-туар асрап, шушында яшәп ятабыз менә. Әле чебиләр алдык. Сарыклар, тавыклар, умарта бар. Кыяр, помидор үстерәбез. Илгизнең Илназы атна саен кайтып йөри. «Дәү әти, нишлибез?» дип кенә тора. Строительныйда да, аграрныйда да укый ул... Илгиз кызы идәннәр юып китә. Өй юганда килен киленнәре төшә хәзер, – дип, ул җайлап кына тормышлары белән таныштыруга күчә.

– Эштән курыкмаска кирәк. Шулай булса тормыш бара, – дип, Хәйдәр ага да хатынын җөпләп куя.

– Минем әти-әни бик эшчән кеше иде. Оет авылыныкылар без. Шәлләр, җылы киемнәр бәйләп үстек. Балалар өстендә дә гел үзем бәйләп кидергән киемнәр иде. Ә болар ягы безне дә уздыра булып чыкты. Без йокыдан торганчы, кайнатам печән чабып кайта иде инде, – дип, көлә-көлә искә төшерә карчыгы. – 20 яшьтә Хәйдәргә кияүгә чыктым. Әти әйтә: «Алай-болай кырын карасалар, кире үзебезгә алып кайтам, кызым», – ди. Әни кырт кисте: «Беркая кайтмый! Бардымы – тора шунда! – ди. – Сыер сау! Су ташы! Артыңа кояш төшкәнче йоклап ятма!» – дип киртләп әйтте.

Дания апа балалар үстергән елларын сагынып искә төшерә:

**Дания апа: «Малайларың русча начар белә, өйдә русча сөйләшегез», – ди бервакыт укытучылары. «Өйрәнерләр әле, алар кечкенә. Иң элек үз телләрен яхшы белсеннәр!» – дидем. Ә бер көнне рус теле укытучысы Елизавета Ивановна көлә-көлә сөйли: «8 Мартка әниләргә котлау сүзе язарга кушкан идем. Синең Илгизең «Мама» дип түгел, «Дорогая Әни!» дип язган», – ди. «Улым дөрес язган, мин Әни бит!» – дидем...»**



■ Балалар, оныклар үзләренең җиде буынын, нәсел тамырын, кайсы халыктан булуларын белеп үсәргә тиеш.

– Өч малай үстердек. Өчесе дә техникага тартылып үсте. Алар кечкенәдән, 4-5 яшьтән аталары белән мотоцикл янында кайнашты. Үзләре күренми дә иде. Эшкә бик хирыс булдылар, үзләре белеп эшләде.

Наис сүзгә кушыла:

– Ашарга чиратлап пешердек инде. Так санлы көннәрдә – мин, җөп санлыларында – Илдар. Миңа чират ике тапкыр эләгә иде: 31 ендә һәм 1 ендә. Әти белән әни эштән соң гына кайталар. Савыт-сабаны да үзебез юабыз, маллар да карыйбыз...

Сүз үзеннән-үзе оныкларга күчә. Дания апаның һәркайсын мактап кына телгә аласы килә инде!

– Илдарның кызы Эльмираның Ясминә исемле кызы үсә, тиздән тагын бәби алып кайталар, малае Илнарның улы бар. Киленем, Илдарның хатыны – Дамира. Атна саен Казаннан кайтып йөриләр. Кече улым Илгиз Алабугада Идарә башлыгы булып эшли, аңа кадәр Алабуга районы Башкарма комитеты рәисе урынбасары иде. Хатыны Алсу белән өч бала үстерәләр: Илназ, Альбина, Азалия. Илгизнең кызы 11 яшьлек Азалия фигуралы шуу буенча ярышларда катнаша. Алинә Заһитова кебек буламы инде... *(Көлеп куя.)* Конькиларымны йоклаганда да кочаклап ятар идем, ди. «Аллаһы Тәгалә белә, саклый. Бозга кергәндә бисмилланы әйтеп кер, кызым», – дим. «Әйтәм, әйтәм, дәү әни!» – ди. Илгиз үзе дә спортка һәвәс булды, гармуннарда да уйный иде... Киленнәрем Зәйтүнә – Буадан, Дамира – Шытсудан, Алсу – Теләчедән. Зәйтүнә белән Наис та өч җиткән егет үстереп, башлы-күзле иттеләр. Фларис, Фәнис, Фирдүс. Житмәсә, ике кызны да алып үстерде бит әле алар. Гөлназ белән Ләйсәнне. Аларны да бик яраттым... Башта курыккан идем: ике кыз бала, нишләрсез, дип. Зәйтүнә бик тырыш, тәртипле, уңган-булган: ул аларны эшкә өйрәтте.

## Җизни абый, Чәчәк апа

Безнең кызларыбыз да бар әле, дигән сүзләр һич тынгы бирмәгән иде. Менә Наис шул хакта сөйли инде.

– 2005 елның 31 декабрендә Зәйтүнәнең энесе Сәгыйть Яңа ел алдыннан авариягә очрап һәлак булды. Буада милиция капитаны иде... Өйдә сөйләштек-киңәштек тә, кызларны үзебезгә алырга булдык. 1990, 1992 елгы балалар. Гөлназ җиденчедә, Ләйсән тугызда укый... Әниләренә ышаныч юк, тәртибе шундыйрак... Аңардан өметне өздек. Детдомга биреп булмый бит! РОНОга кереп хәлне аңлаттым да, кызларны Буадан Теләчегә алып кайттым. Бездә яши башладылар. Шулай итеп, биш балалыга әйләндек. Миңа – «Җизни абый», Зәйтүнәгә «Чәчәк апа», дип дәшәләр иде. Алар ягында шулай Туган апа, Алма апа, Чәчәк апа дип сөйләшүләр бар. Бездә – дәү әти, дәү әни, Зәйтүнәләр ягында әби, бабай, диләр. Үз балаларыма караган кебек карадым, берсен дә аермадым. Зәйтүнә генә кайчак әйтеп куя, малайларга да, кызларга да корырак булдың, ди. Ләйсән Россия Хокук академиясендә укыды, Гөлназ педагогика уку йортын сайлады. Үсеп җитеп, очты инде кызларыбыз, икесе дә кияүдә хәзер. Оныклар белән кунакка кайтып йөриләр. Оныклар дигәннән... исемнәрен хәзер буталмыйча саный да алмыйм, тугызау бит! Фаяз, Зәлия, Тимур, Регина, Роберт, Ранель, Гадел, Зилә, Солтан...

...Безнең халыкта гомер-гомергә шундый язылмаган кануннар булган бит. Карт әби-бабайларны – Картлар йортына, ятим калган балаларны Балалар йортларына тапшырмаганнар, туган-тумача һәрчак үз янына сыендырган. Наис белән Зәйтүнә дә шул юлны сайлаган.

## Без «папа», «мама» түгел!

Хәтер йомгагын сүткәндә кызык хәлләр дә искә төшә икән. Дания апа бер вакыйганы сөйләде. Наис, армиягә киткәч, өйгә русча хат язып салган. «Папа», «мама» дигән сүзләрне укыган Дания апа утлы күмер тоткандай хис иткән үзен.

– Берзаман әнидән хат килеп төште. «Сәлам совхоздан! Улым, без син киткәндә татар идек, хәзер дә руска әйләнмәдек. Без папа, мама түгел – әти, әни, дип, ул сүзләрнең астына кызыл каралар белән сызып язган! Оят булды инде! Армиядәге малайлардан күреп язганмындыр инде, – ди Наис уңайсызланып. – Шәп сабак булды ул!

– Шул сүзләрем өч балама да җитте! Ник берсе русча язсын! – ди Дания апа. – Малайларың русча начар белә, өйдә русча сөйләшегез, ди бервакыт укытучылары. Беренче, икенчедә генә укыган чаклары иде. Өйрәнерләр әле, алар кечкенә, дидем дә бетте-китте. Ата-аналарның балалары белән русча сөйләшеп утыруына эчем поша. Танышларга да әйтәм инде, нигә ул кызыгыз белән русча сөйләшәсез, дим. Татарча эндәшсәм, җавап бирми, ди берсе. Син дә эндәшмә аңа, дим. Бер оныгыбыз кайчак рус сүзләре ычкындыргалый. Дәү этиләренә ошамаган, татарча сөйләшегез, ди икән. «Дәү әти, мин барысын да беләм. Әлхәм-колһуалла догасын да беләм», – дигәч, күңелгә рәхәт булып китте инде. Зилә әнә, кечкенә булса да, Фатиха, Кәүсәр сүрәләрен дә шартлатып укый. Әнисенә ияреп мәчеткә дә йөри икән бала.

## *Бер түбә астында – өч гаилә*

Теләчегә, Наис белән Зәйтүнә биләмәләренә кайтып керсәк... Анда әле уртанчы уллары Фәнис белән киленнәре Зөлфия, аларның балалары Зилә белән Солтан да, төпчек малай Фирдүс һәм яшь килен Алинә дә яши икән. Әйе, иркен, зур йорт. Бүлмәләр күп, җиһазлар – заманча. Ләкин хикмәт зурлыкта, байлыктамыни! Күңел киңлеге, бер-береңә хөрмәт кирәк! Гөл чәчәгеннән билгеле, диләр.
Бу очракта мин Зәйтүнәне гөлгә тиңләр идем. Сабыр, кайгыртучан, киң күңелле, уңган, тырыш... Барысын җайлап, хәлләренә кереп, күңелләрен күреп йөрү үзе бер таланттыр. Уллары да, киленнәре дә «әни» дип өзелеп тора! Өйдәге тәртип тә, рәхәт халәт тә, тынычлык та күп вакыт хатын-кыз зирәклегеннән, кирәк вакытта юл куя белүеннән тора шул. Әле дә кызлар кебек сыгылмалы гәүдәле, йөзендә һаман тиенкы елмаю, тыйнаклык балкыган Зәйтүнә үзе моңарчы белмәгән-күрмәгән бу якларга килгәнгә дә озакламый 40 ел була икән инде! Яшел Үзәндә медучилище тәмамлаган Буа кызын Саба районына эшкә җибәрәләр. Иртүк Казма авылыннан чыгып китеп, көн буе килә ул. «Районның баш врачы мишәр иде, Буадан булгач, мине де мишәр кызы дип уйлап якын күрдеме, «Вәлиуллина, сине атаклы Ленин исемендәге совхозга эшкә җибәрәбез», – дип, фатихасын бирде», – дип искә төшерә Зәйтүнә. Наис белән шунда танышалар, кавышалар. Гаиләләре белән Теләчегә күчкәч, гинекология бүлегендә эшли, терапия бүлегендә өлкән шәфкать туташы, соңрак хастаханәнең баш шәфкать туташы була. Тырыш, чая кыз оештыру сәләтенә дә ия икән! Җырлый да, бии дә, КВНнарда да катнаша. Ягымлы, йомшак телле Зәйтүнә ак халатлы фәрештәгә әйләнә.

«Ул һәрчак без, киленнәре, ягында, – ди Зөлфия. – Шундый оста дипломат ул безнең! Тынычландыра да белә, киңәш тә бирә... Фәнис белән танышкач ук бу йортка килеп йөри башлаган идем. Гел ачык йөз белән каршы алдылар. Хәзер инде бөтенләй үзләренеке мин! Безнең хәтта табында да үз урыныбыз бар! Әтинеке – түрдә, әнинеке аның янында. Минеке холодильник янында. *(Көлә.)* Ялгыш берәрсе утырса, «монысы әти урыны!» – дип сиздереп куялар. Фәнис белән йөргәндә әниләренә күчтәнәчкә өчпочмаклар пешереп җибәрә идем. Ә ул кош тоткандай килеп сөенче ала: «Безнекеләр синең өчпочмакларны бик яраттылар!» – ди.

Фәнис күптән түгел үзенең юридик консультациясен ачкан. Россия Хокук академиясен тәмамлап, Сабада судта эшләгән еллары үзе бер тормыш, тәҗрибә мәктәбе булган. Зөлфия – Күкчә авылы кызы. Теләче мәктәбендә физкультура укыта. Сигезенчеләрнең класс җитәкчесе. Чаңгы ярышларында – ул гел беренче. Республика күләмендә үткәрелгән ярышларда да алдынгы урыннарны яулый. Хыялы: ире Фәнисне, кызы Зилә белән улы Солтанны чаңгыга бастырасы, чаңгычылар гаиләсе булдырасы, укучыларыннан чемпионнар тәрбиялисе килә. Үзен, яратып, җилдән җитез Зөлфия дип йөртәләр икән.

Салиховларның төпчеге Фирдүс технология университетын тәмамлаган. Автосервиста эшли. Дәү әтисенә, әтисенә охшап, аңа да «машина җене кагылган». Дуслары белән Теләчедә спортның автоузышлар төрен кертеп җибәрергә, Салават кубогына чыгарга да хыялланалар. 12 спорт машиналары бар икән инде хәзер. «Үзем дә сизмәстән әнигә охшаган кызны эзләгәнмен икән. Алинә дә эшчән, йомшак, җайлы минем. Ул да әнием шикелле озын чәчле. Тик аның чәчләре кояш кебек алтын төстә! – ди Фирдүс. – Без бер түбә астында өч гаилә яшибез. Бик күңелле! Туганнар сүзгә килә башласа, гаилә бетә, дип әйтә иде дәү әти белән дәү әни. Шул сүз бәләкәйдән күңелгә сеңеп калган. Без бер сүздә булып, берберебезне тыңлап, юл куеп яшибез».

Яшь килен Алинә – «Лесной» бистәсе кызы. Казанда банк мәктәбендә укыган, аннары Югары икътисад мәктәбенә укырга кергән. Хәзер менә Теләчедә эшмәкәрләргә ярдәм итү фондында эшли. Фирдүс белән дуслары туенда танышканнар. Аннары социаль челтәрләрдә аралаша башлаганнар. «Фирдүс мине әти-әнисенә күрсәтергә алып кайтты башта. Шаян телләләр, гадиләр, ихласлар – бик ошаттым! Аллага шөкер, бәхетем бар икән, дип сөендем, – ди Алинә. – Үз әнием исә сеңлем Зәринә белән миңа гаилә тормышы буенча гел киңәшләр бирә иде. Тыныч булырга, ирне узып баш булырга тырышмаска өйрәтте.

Ике килен-килендәш – җилдәй җитез Зөлфия белән алтын чәчле Алинә менә шулай Салиховлар дөньясын ямьлиләр. Ата-бабалар көн күргәнчә, бер түбә астында өч гаилә дус һәм тату яшәп яталар.

## *Ермаклар, Кораешлар нәселе*

Төп йортта – Хәйдәр абый белән Дания апа өендә – түрдә эленеп торган нәсел шәҗәрәсенә сокланып карап торган идек. Шуны ук Наис-Зәйтүнәләр өендә дә күрдек. Гаиләсе белән Мәскәүдә яшәүче уллары Фларис фатиры диварын да шул нәсел агачы бизәп тора икән. Агач ябалдашларында йөзләгән исем! Алар, тармакланып китеп, җәелә, үсә бара: яңа исемнәр өстәлә. Салиховлар нәселенең бик кадерле гаилә ядкаре ул. XVI гасырларда яшәгән ерак бабаларының бабалары, аларның бабалары... Ермак, Бәкер, Әкер, Кораеш, Туеш, Биккол дип, түбәннән – иң юан кәүсәдән укып китәм дә, йөзләгән исемнәр белән чуарланган вак язулар күз алдында бии башлый.

12 буын теркәлгән бу агачны моннан ун еллар элек өлкән туганнары Тимербаева Сәлимә апа башлап җибәрә, Миңнехаҗи абый белән Нурия апаның улы Ренат Салихов исә ул эшне дәвам итә.

«Гаилә тарихында гасырлар кайтавазы – без тарихта эзлебез» дигән республика бәйгесенең тугыз район катнашында Теләчедә узган зона турында Салиховларның нәсел агачы II урынга лаек дип табыла.

Бассейннан кайтып кергән 9 яшьлек Зилә шәҗәрә янына килеп: «Монда минем исем дә бар!» – ди. Үрелеп, «Зилә» исеменә күрсәтә. Кечкенәләр – Солтан, Тимурлар теркәлмәгән әле. Тиздән аларның да, киләчәктә аваз салачак тагын бик күп балаларның да исеме урын алыр анда.
«Без – Салиховлар нәселеннән!» – дип, горурланып үсәрләр.



Видеоны карар өчен смартфонның камерасын QR-кодка якынайтыгыз.
Видео: Анна Арахамия.

# ГОМЕР ЗАЯГА УЗМАГАН


Фото: Анна Арахамия

Гөлнур
САФИУЛЛИНА

– Үткәндә үкенечләрем юк…
Узган юлына карап шулай әйтә алуы – бәхет. Матур яшәлгән. Кешеләргә кирәк булып. Ил, милләт гамьнәрен хаклап. Күңеленә туплаган хәзинәне янәшәдәгеләр белән бүлешеп… Әңгәмәдәшем – Ульяновск өлкәсе мөслимә хатын-кызлар оешмасы рәисе, мөгаллимә, «Дин дәресләре» мәктәбе җитәкчесе Асия МӨЛЕКОВА. Сембер каласының Ак әбисе! Гомер дигән китап бик калын – кайбер битләренә генә күз салабыз…

## «Ульяновск өлкәсенең атказанган сәүдә хезмәткәре»

### исеме дә юкка гына бирелмәгән.

***

«Син туган көнне сугыш чыгу турында хәбәр килде, кызым», – дип сөйли иде әни. Ил хәсрәт дәрьясына чумган сәгатьләр бит инде ул... Минем өчен шатланучы булдымы икән, белмим. Авыл советына теркәтергә дә берничә көннән соң гына барганнар – туган көнем паспортыма 28 июнь дип язылган. Әти сугыштан яраланып, 1943 елның көзендә кайта. Мин бик кечкенә бит әле, әмма шул көнне хәтерлим. Томан эчендәге кебек булса да! Таяксыз йөри алмый дип тормыйлар, кайтуга әтине бригадир итеп куялар. Иң авыр вакытлар... Кырыс законнар... Әти кайбер нәрсәләрне күрергә тиеш булса да, күрмәмешкә салышкан икән. Мин бу хакта аның җеназасы өстендә ишеттем. Бөтен авыл җыелып килгән иде. «Галәви абый безне шул чакта ачлыктан коткарды», – дип сөйләделәр. Изгелек бер дә онытылмый шул. Мин бабаема да моны гел әйтәм...

***

Кукмара районы Мәчкәрә авылы кызы мин. Җидееллык мәктәп үзебездә бар иде. Тик алга таба да шундый укыйсым килә! Әтинең әнисе урын өстендә ята иде – олы бала булгач, аны карауны миңа йөкләделәр. Август ахырында әбиебез вафат булды. Иртәгә 1 сентябрь дигән көнне әти кырдан кемдер аша: «Безнең кыз укыйсым килә дигән иде, теләсә, Кукмарага барсын», – дип әйтеп җибәрде. Бер телем ипи алдым да егерме чакрымдагы район үзәген эзләп киттем. Җәяү инде, әлбәттә. Барып таптым, директорга кердем. Ә ул: «Соңга калдыгыз, Зур Сәрдек мәктәбенә барыгыз», – ди. Анда исә интернат та юк, кибетләрендә ипи дә сатмыйлар. Тугызынчы классларны иртәгә колхозга бәрәңге алышырга җибәрәләр икән. «Мин дә алар белән барыйм әле. Бәлки, кемдер укуын ташлап кире кайтып китәр – урын бушар», – дим Хәйруллин абыйга. Тормышта әрсезлек тә кирәк кайчакта... Бистәдә үскән шәһәр кызлары кебек кенә түгел бит авыл баласы – алар берне чүпләгәндә, өчәр чиләк бәрәңге чүплим. Капчык та күтәреп ташыйм. Тырышлыгымны күрделәр, мине мәктәптә калдырырга сорап, укытучылар директор абый янына үзләре керде.

***

Интернатта яшәп укыйбыз. Әтиләре сугышта үлгәннәргә сыек кына бәрәңге боламыгы, юка гына бер телем ипи бирәләр. Миңа анысы да юк – әтием исән... Беркөнне укудан кайтсам, тумбочкам өстендә бер телем ипи тора. «Фәүзия, кайдан килде икән бу ипи?» – дим аптырап бүлмәдәш кызга. «Мин куйдым, инде өченче көн берни ашаганың юк бит», – ди. Аннан шушы риваятьне сөйләде. Бер бабай янындагы кешеләрдән: «Әйтегез әле, нәрсәнең тавышы бик еракка ишетелә?» – дип сораган. Берәү – «самолет тавышы», икенчесе «паровозныкы» дигән, өченчесе тагын нәрсәнедер атаган. «Юк шул, – дигән бабай, – ипи тавышы еракка ишетелә». Фәүзиягә 14 яшь бу вакытта, әтисе сугыштан кайтмаган, үзенең дә ярдәм көтәр җире юк. «Без үсәрбез, төрле якларга китәрбез, шушы ипи телеме искә төшкән саен, мине дә хәтерләрсең», – диде ул. Шулай булды да! Мин аны беркайчан онытмадым. Киров өлкәсенә кияүгә чыгып, шунда гомер итте ул. Узган ел гына вафат булды... Ипинең бөртеген дә ташлаганым юк минем!

***

Классташым Флера белән колхоз рәисен алдап-йолдап дигәндәй, паспорт алуыбызны сөйләп тормыйм – анысы үзе бер тарих. Бүгенгеләр аңламас та, әмма безнең өчен ул, чыннан да, бөтен гомергә җитәрлек вакыйга булды. Паспортсыз авыл башыннан да чыга алмыйсың, ә безнең шәһәргә китәсе, укыйсы, һөнәр аласы килә. Тегүче булырга теләгән идем – конкурстан узмадым. Документларымны кочаклап, Ленин урамыннан төшеп барам. Кинәт күземә бер бинадагы элмә такта чалынды. «Казан кооперация техникумы» диелгән. «Кооперация» сүзенең ни икәнен белмим, әмма миңа укырга гына булсын. Ишеген ачып кердем. «Товароведлар бүлегендә генә урын калды», – диләр. Аның да кем икәнен белмим, әмма шунда ук ризалаштым – алсыннар гына.

Лекция буласы аудитория янына иң беренче булып килеп бастым. Иң беренче кереп утырдым. Бераздан башкалар керә башлады. Аннан ишектә Ул күренде... Бер күрүдән гашыйк булу диләр бит әле – бу шул очрак иде бугай. Ул керә, ә мин аны күзләрем белән озатып барам. Һәм Мөстәкыйм... янәшәмдәге урынга ук килеп утыра. Аксый, аягы зәгыйфьрәк. Тумыштан шундый ул. Әнисе 56 яшендә генә таба аны, әтисенә инде бу вакыт 64 яшь була. Әти-әнисенә бер бөртек! Русчасы әйбәт иде аның: инде биш ел читтә, шахталарда эшләп кайткан. Нинди сүзне белмәсәм дә, аңардан сорыйм... Икенче елга практика узарга үзе теләп безнең Кукмарага кайтты. Бу да безнең араны шактый якынайтты.

Мине эшкә юллама белән – Буага, Мөстәкыймне Чүпрәлегә җибәрделәр. Бераздан барысын ташлап, Буа шикәр заводына килеп, тракторист булып эшкә урнашты ул. Миңа якынрак булырга теләве иде бугай. Туган ягында, белгән кешеләр арасында ревизор булып эшләве дә җиңел булмагандыр... Буаның Мулланур Вахитов исемендәге кичке мәктәбендә укып йөрим. Теләгем – югары уку йортына керү. Беркөнне карыйм, күршемдәге Шура исемле кыз урынында Мөстәкыйм утыра! «Ә син нишлисең монда?!» – дим. «Укырга килдем», – ди күзен дә йоммыйча. Шул елны кышын өйләнештек без. Икебез дә фатирда торабыз: барып язылыштык та, миңа кайтып чәй эчкәч, тара-

PRESSA



Кеше белән елмаеп сөйләшү дә – дога. Ешрак елмаерга тырышыгыз.

лыштык... Шикәр заводы барактан бер бүлмә биргәнче аерым яшәп тордык. Әйе, мин аңа «бабаем», дим. Яшьтән үк шулай дип йөртәм. «Кызым, кияүнең исеме Коръәндә, «Фатиха» сүрәсендә язылган, аны тәһарәтсез әйтергә ярамый», – диде әни миңа без өйләнешкәч. Күңелгә кереп калды инде бу... «Бабай дип дәшсәм, ризамы?» – дип сорадым үзеннән. Нигә бабай, үзем дә белмим... Ул каршы килмәде. Яшь арабыз алай зур түгел безнең – биш кенә яшь.

***

Буа райпотребсоюзына инструктор итеп җибәргәннәр иде мине. Кайтсам: «Алмыйбыз, ул хатын-кыз эшли ала торган эш түгел», – диләр. «Ике атна вакыт бирегез миңа, булдыра алмасам, китәрмен», – дидем. Иң ерак авылга йомырка җыю планын тутырышырга җибәрделәр. Барсам, кибетченең йомырка өчен халыкка бирергә ни сабыны, ни җебе юк... Алай да, аны ияртеп урам буйлап чыгып киттем. Бусаганы атлап керәм дә: «Апа җаным, бишне генә», – дим... Тутырдык без ул йомырка планын. Ике атнадан «китәм» дип авыз ачкан идем: «Син безнең үзебезгә кирәк», – диделәр... Җәмәгать эшенә чумдым. Үземнән ун яшькә өлкәнрәк кибетчеләрне укытырга куйдылар. Үзем дә читтән торып кабат укырга кердем. Бу юлы – Мәскәү совет сәүдәсе институтына. Мин «экономист» дипломы алып чыккач, без Ульяновск шәһәренә күченеп киттек. Икенче балабызны көтәбез, кайнанам да безнең белән – баракның бер бүлмәсендә генә көн итүе авыр иде. Фатир дип кузгалдык. Буаның үзәк урамында урнаштырылган Мактау тактасында рәсемем тагын ике ел эленеп торды әле...



***

Сиксәненче еллар ахыры. Ульяновск өлкәсе җирле сәнәгать идарәсендә өлкән икътисадчы булып эшләгән чагым, кул астымда – 25 предприятие. 1987 елның 26 мартында М. Горбачевның кооперативлар оештыру турындагы карары дөнья күрде. 3 апрельдә исә инде безнең кафе үзенең ишекләрен ачты. Өлкәдә генә түгел, Россиядәге иң беренче кооперативларның берсе иде ул. Өлкә, хөкүмәт җитәкчеләре юкка гына миңа тукталмады: бар яктан да аларга туры килдем – икътисадчы белемем бар, тәҗрибәм дә җитәрлек. Тәвәккәлләсәм дә, курыкмадым дип әйтә алмыйм. Бигрәк тә беренче вакытта. Ник тотынганыма үкенеп елаган чакларым да аз булмады. Халык бит безгә башта төрлечә карады. Эшмәкәрләргә хөрмәт шактый соңрак килде әле ул. Әмма үкенсәм дә, мин кире чигенә торган кеше түгел... Бабаем һәрвакыт төп таянычым булды, кибетләрдә берни юк: ит, сөт, бәрәңгене ул машина белән авыллар буйлап йөреп ташыды. Ул арада өлкәдә татарлар берләшә башлады – милли хәрәкәт кузгалды. Алар өчен безнең кафе төп йорт – очрашу, күрешү урыны булды. Татар яшьләре өчен танышу кичәләре үткәрүне гадәткә керттек – яңа татар гаиләләре оешты.

Тернәкләнеп киттек бит без шулай. Иң беренче хезмәт хакын гел онытмыйм. 370 сум! Ул чакта югары белемле инженерның да хезмәт хакы 120 сумнан артмый иде. Өйгә кайттым да: «Бабай, моның кадәр акча белән нишлибез?» – дим. Шәһәрдән 70 чакрымдагы Чардаклы балалар йортын шефлыкка алдык. Телевизор да бүләк иттек, келәмнәр дә, бәйрәмнәрнең берсендә дә котламый калдырмадык. Егерме өч ел буе! Берсендә шәһәр урамы буйлап барганда яшь кенә кеше килеп кочып алды. «Танымыйм бит», – дим уңайсызланып. «Мин Чардаклы балалар йортында үстем, сез безгә икенче әни кебек булдыгыз», – ди. Икенче юлы стадион янында маршрут автобусы көтәм, яныма бер яшь хатын килеп басты. «Балалар йортыннан мин... Сезне гел искә төшерәбез, күрәсе килгән иде», – ди.

***

Кафены ачканда исемен үзем сайлый алмадым. «Русь» дип куштырдылар. Бик каршы төшеп карадым, булмады. Дөрес, бу исем соңрак миңа ярдәм дә итте – башка кафеларны япканда безгә кагылмадылар... Аннан әкрен генә «Ашханә»гә әйләндек. Кафе ишегендәге бу язу татарларны магнит кебек үзенә тарта иде. Өчәр касса эшләгән чаклар булды. Берәр сәгать чират торып керәләр. Менюда бездә элек тә «Русь» салатыннан кала, барысы да татар милли ризыклары иде. Тарихи Ватаныннан читтә яшәгән кешегә аларның никадәр кадерле, тансык икәнен әйтмәсәм дә аңлашыла... Берсендә яхшы гына киенгән бер ир-ат ишек шакып бүлмәмә керде. «Сезме директор?» – ди. «Тагын тикшерү килгән икән», – дип уйлыйм. «Ашханә» дигән исемегез өчен рәхмәт! Сез мине яшьлегемә кайтардыгыз. Казанда укыдым, ашханәгә йөри идек», – ди. Бу исемне алдыртырга тырышып йөрүчеләр байтак булды. Тикшерү арты тикшерү килде.

Сәбәп эзлиләр. Җәмәгать туклану оешмасында бәйләнердәй әйберләр табу авыр түгел ул. Әмма бездә дисциплина бик көчле иде: гаеп таба алмадылар. «Ни өчен кафеның исеме ошамый – язма рәвештә язып калдырыгыз. Мин сезне аннары судка бирәм – ул ничек хәл итсә, шулай булыр», – дидем соңгысында. Җиңәчәгемне белеп әйттем – юлын табып, исемне рәсмиләштерергә өлгергән идем инде.

***

Өлкәннәр көне алды иде. Идарәгә чакырып: «Сезнең кафега 20 карт-карчыкны билгеләдек. Алар өчен табын корыгыз, бүләкләр әзерләгез. Өстәлдә һәркайсына 200 грамм исәбеннән аракы да булсын», – диделәр. Ярый, сыйладык. Әмма икенче елны баш тарттым. «Моннан соң безнең кафеда исерткеч эчемлекләр булмаячак!» – дидем. Һәм булмады да. 20 елга якын хәләл кафе булып саналдык. Бу өлкәгә кагылышы булганнар моның нинди җитди адым икәнен аңлый: җәмәгать туклану оешмаларында табышның төп өлеше исерткеч эчемлекләрдән керүе берәүгә дә сер түгел.

Ул чакта намазлы идем инде, әмма калдырган чаклар да күп була иде әле. Иртәнге сәгать җидедән кичке унбергә кадәр эшлибез. Өлгермим... Туганнан туган абыем Заһретдин бер сөйләшкәндә: «Сеңлем, ятим балаларга ярдәм итәсең, Рамазан, Корбан гаетләрен үткәрәсең. Ни өчен эшлисең боларны? Аллаһ ризалыгы өчен булмаса, сиңа алардан бер савап юк бит», – диде. Уйланып калдым... Хөрмәт иткән, бик акыллы туганым иде ул минем. ТУ-154 самолетында очты, пилот иде, аннан дингә килде, Арчада имам-хатыйб булып торды.

Исерткеч эчемлекләрдән баш тарткан елны Өлкәннәр көненә кафега үзебезнең милләттәшләрне җыйдым. Гармунын күтәреп бабаем да килде. Профессор, Сембер татар милли-мәдәни мохтариятенең беренче рәисе Азат Курчаков соңгарак калган иде. «Сезнең гөрләшкәннәр универмаг яныннан ук ишетелә!» – дип килеп кергән иде ул ишектән.

***

Танышларым Коръән ашына чакырдылар шулай. Мәҗлестә кунаклар күп түгел: Флера абыстай үзе дә, аның алты-җиде шәкерте. Чиратлашып Коръән укыйлар: китапны берсеннән икенчесенә күчерә баралар. Миңа да суздылар... Ә мин... ләм-мим, бер хәрефен дә белмим. Ахырдан аларга: «Совет уку йортларында 25 ел белем алдым, әмма арагызда иң наданы мин булдым. Бер ел эчендә өйрәнергә сүз бирәм», – дидем. Ерак булса да, Вырыпаевка мәчетенә киттем – Флера абыстай шунда укыта иде. Өлгерә алмыйм: соңарып барам, иртәрәк китәм. Бик тырышсам да, башкалардан калышам кебек иде. Үземә генә шулай тоелган икән. Өч ел укып, таныклык алганда мине сыйныфның иң яхшы укучысы дип атадылар. Кызганыч, бу шатлыгымны мулла булган өчен генә Себергә озатылган бабам һәм мине дин юлына кертеп җибәргән Заһретдин абыем күрмәде...

***

Хаҗны барып күрү хыялым күптән бар иде, әлбәттә. Насыйп булды бит! Анда күргәннәрем, алган тәэсирләрем мине бик нык үзгәртте. Башта үзем өчен тәваф кылдым, аннан Мөстәкыйм өчен – ул авырткан аяклары белән анда бара алмады. Кара ташның янына ук барып җитәргә, кулым белән аңа кагылырмын дип өметләнә дә алмадым. Ә мин ул ташка хәтта башымны куеп тордым... Мин аннан икенче кеше булып кайттым.

Кайтуга «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә укырга кердем. «Сез мине алырга тиеш, бездә хатын-кыз мөгаллимәләр юк дәрәҗәсендә, укытасым килә», – дидем имтихан вакытында... Ишеттеләр! Группабызның старостасы булдым. Уку еллары сизелмичә дә узды. Дипломны «бишле»гә якладым.

Мәдрәсәне тәмамлаган елны ук укыта башладым. Беренче төркемне өлкә «Дуслык йорты»нда җыйдым, бүгенге көндә безнең «Дин дәресләре» мәктәбе Үзәк җәмигъ мәчетендә эшли. 349 шәкерт белем алып чыкты инде. Минемчә, бу инде аз түгел... Аларның күбесе үз авылларында дин дәресләре укыта, мәчетләрдә имамнар булып эшли. Барыбыз да Аллаһ ризалыгы өчен эшлибез.

***

Казанның меңьеллыгын бәйрәм итәргә чакырылган кунаклар арасында мин дә бар идем. Бөтендөнья татар конгрессында да булдык. Татар хатын-кызларының «Ак калфак» иҗтимагый оешмасы турында да ишеттек. Бик күп төбәкләрнең үз «Ак калфагы» бар икән... Кире кайтканда, юлда үзебезнең делегатларга шул хакта сүз кузгаттым: «Башкалар сөйләгәндә тыңлап кына утырдык, кыен булды», – дим. «Сез тотынсагыз, аны оештырып чыгасыз инде», – диделәр... Тугыз ел өлкәбезнең «Ак калфак» оешмасын җитәкләдем. Оештырган чараларны санап чыга алмам... Өч ел элек «Ак калфак»ны Кәримә Алиуллина кулына тапшырдым. Үзем шулай хәл иттем. Өлкәнрәк хатын-кызлар белән эшләсәм, дөресрәк булыр дип уйладым. Бүген мин җитәкләгән «Мөселман хатын-кызлар оешмасы»нда һәркайсыбызның эше бүленгән. Кемдер ЗАГСларга бара, аерылышырга гариза биргән милләттәшләребез белән очрашып сөйләшә – гомер иткән өлкән кеше буларак аларга киңәшләрен бирә; икенчеләребез яшьләр белән эшли – мәктәпләргә йөри, туган телебезне саклау сагында тора, өченчеләребез дини мәҗлесләрдә вәгазьләр темасын кайгырта...

Үткәнемә борылып карыйм да, «Гомер заяга узмаган», – дим. Телебезне, динебезне, милләтебезне хөрмәт итә торган ике ул үстердек. Без салган эздән китмәсәләр дә, кирәк чакта таяныч булдылар. Дүрт оныгыбыз, бер оныкчыгыбыз бар – дөньяның иң зур байлыгы шулар! Кырык яшемдә авырып киткәч, табиблар якыннарыма: «Көннәре санаулы», – дигәннәр иде. Илдусны армиядән минем белән хушлашырга чакыртып кайтардылар хәтта. Ул көннәрдән соң инде тагын кырык ел вакыт узды. Бер гомер! Бабаем белән никахыбызга тиздән 60 ел була. Болар бәхет түгелмени?!

# «ТАЛЧЫБЫК БЕЗ МИЛЛӘТ АГАЧЫНДА»



Лилия
ГӘРӘЕВА




1991 елда Яшел Үзән шәһәрендә беренче татар гимназиясе ачыла. Милли җәмәгатьчелек, укытучылар, татарча белем бирүче мәктәп ачылуын теләгән әти-әниләр, йорттан йортка йөреп, 67 бала туплый ул елны. Өч катлы бинаның беренче катына үзләре ремонт ясап, яңа уку елын башлап җибәрәләр. Гимназиянең даны бер ел эчендә тирә-юньгә тарала. Икенче елны инде укучылар икенче катны да били. Өченче елны өченче каттагы класс бүлмәләрен дә рәткә кертергә туры килә. Ачылган елыннан алып – 30 ел эчендә гимназия тарихы балалар саны кимегәнен хәтерләми, киресенчә, алар елдан-ел арта гына бара. Әле 2019/2020 уку елында 463 бала булса, быел биредә 495 укучы белем ала.



Май ае мәктәпләр өчен урак өсте кебек. Контроль эшләр, имтиханнар, чирек ахыры… Кылны кырыкка ярырдай шундый чакта да гимназия директоры Гүзәлия ханым Нуриева безне ачык йөз белән каршы алды. Бик яраткан, җаныңны биреп эшләгән эш турында гына кичектергесез эшләреңне дә читкә куеп, әнә шулай сөйләп, күрсәтеп була бит ул. Гүзәлия ханымга ияреп, рәхәт, самими дөньяга – Балачак иленә узабыз. Керәкерешкә үк халкыбыз каһарманнарының портретлары каршы ала. Кол Галиләр, Мөхәммәдьярлар сынап күзәтә сыман: нинди алар бүгенге татар укучылары? Милләтебезне дәвам итәрләрме? Әлеге галерея – Гүзәлия Наилевна идеясе. 2018 елда татар телендә белем бирүче «Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районының 5 нче гимназиясе» директоры итеп билгеләнгәч, подвалдан табып алып менә ул бу сурәтләрне. «Татар баласы үз геройларын белеп, күреп үсәргә тиеш!» Бу сүзләрне бер генә ишетмәдек без Гүзәлия ханым тарафыннан. Икенче каттагы диварларга чорыбызның күренекле шәхесләре портретларын элəргә теләве дә шушы максаттан. Ләкин анысы бераз соңрак, гимназия бинасына капиталь төзекләндерү узганнан соң булыр инде. Түземсезлек белән көтәләр ул көнне. Сметалар төзелгән, менә-менә башланырга тиеш. Тартмасыннан да чыгарылмаган килеш торучы зур смарт-экраннар да, технология бүлмәсенә яңа алынган җиһазлар, станоклар, 3D принтер да көтә ул ремонтны… Укучылар көтә, укытучылар, әти-әниләр…

Без гимназия белән танышып йөргән арада, тәнәфескә чакырып, кыңгырау чыңлый. Тирә-як балалар тавышына күмелә. «Исәнмесез!» «Апа, хәерле көн!» – яныбыздан һәрберсе әнә шулай туган телебездә сәлам биреп, исәнләшеп уза.

– Безнең балаларыбыз тәртиплеләр, акыллылар, иң-иң матурлар! Әдәпсез балалар юк бездә. – Директор урынбасары Сәлахова Зөлфирә Үрнәк кызыннан укучылар турында башкача сүз ишетербез дип көтмәдек тә. Гимназиянең ачылышыннан бирле дип әйтерлек татар теле һәм әдәбиятыннан белем биргән, балаларга татар теленең бар матурлыгын, тәмен, аһәңен тоярга өйрәткән укытучы ул. Гөлнара Садыйкова, Тәнзилә Нәҗипова, Зөлфия Хисамова, Марат Халитов, Резеда Баһавиевалар да хезмәт юлларын әлеге гимназиягә багышлаган тәҗрибәле укытучылар. «Безнең бриллиантларыбыз!» Педагогларның һәркайсы турында җитәкче әнә шулай ди.

Тагын бер күңелле хәл – кайчандыр биредә укып чыккан укучылар хәзер үзләре гимназиянең яшь педагоглары. Татар теле һәм әдәбияты, тормыш иминлеге фәннәреннән белем бирүче Радик Гатауллин аспирантура тәмамлап, кандидатлык диссертация яклаганнан соң укытучы булып эшкә кайта. Башлангыч сыйныф укытучысы Эльвира Амелина да 1 нче сыйныфтан бирле шушы гимназиядә укыган. Элеккеге укучылар бүген инде бирегә үз балаларын җитәкләп китерә.

Гимназиядә уку-укыту татар телендә алып барыла. Ләкин бу җиңел генә бирелми. Ике телне камил кулланган педагогларга кытлык та, рус балалар бакчаларыннан килүче сабыйларның татар телен начар белүләре дә кыенлыклар тудыра.

– Элегрәк безгә татар бакчаларыннан татарча яхшы белгән, татар телендә фикерләгән балалар килә иде. Электрон чиратлар кертелгәч, татар балалар бакчалары аз калды. 3 яшькә кадәр гаиләдә чиста итеп татарча сөйләшергә өйрәнгән бала да, рус мохитенә килеп кергәч, русча фикерләүгә күчә, – дип аңлата Гүзәлия Наилевна. – Андый балаларны ничек итеп беренче көннән үк саф татар телендә укытуга күчәргә? Бу мөмкинме?! Башта ике телне бергә кулланып, әкренләп-әкренләп кенә фәннәрне татарча укытуга керешәбез. Милли җәмәгатьчелек тарафыннан безне тәнкыйтьләүчеләр дә бар. Укыту процессын эчтән күреп белмәүчеләр гамәле бу.

Гимназиядә бары тик татар балалары гына белем аламы, дисәк…

– Рус балалары да, катнаш гаиләдә туганнар да укый бездә, – ди Гүзәлия ханым. Гаҗәпсенгәнебезне күреп, аңлатырга ашыга, – Катнаш гаиләләрдә әниләре татар булса, ул баласының татарча белеп, өйрәнеп үсүен тели.

– Ә руслар? Алар ни өчен балаларын татар мәктәбенә бирә?

– Иң элек педагоглар һәм мондагы тәртип җәлеп итә, – ди директор. – Без зур мәктәп түгел, коллективыбыз көчле. Балалар арасында полициядә исәптә торучылар юк… Белемне аны алып була, репетиторларга йөрергә мөмкин, түләүле дәресләргә… Ә менә тәрбияне гаилә һәм мәктәп кенә бирә ала. Әти-әниләр хәзер моны аңлады.

Аның сүзләрен башка педагоглар да күтәреп ала:

Фото: Анна Арахамия









**Гүзәлия Нуриева:** «Гимназиябез «Традицияләр мәктәбе – киләчәк мәктәбе: милли һәм поликультур белем бирүче мәктәп» моделе буенча эшли. Без башка мәктәпләрдән бер адым алда барырга бурычлы. «Балабыз татарча бик яхшы белми, кабул итәрсез микән?» – дип килгән әти-әниләр бар. «Кабул итәбез, телне дә өйрәтербез, ләкин сез безгә комачауламагыз гына», – дибез. Әгәр әти-әниләр шуңа риза икән, без берәүне дә кире бормыйбыз. Әкренләп бала телне өйрәнәчәк. Иң мөһиме: русча да, татарча да камил белгән фән укытучыларын табу. Ике телне белүче педагоглар гына түгел, гомумән, педагоглар кими бара.
Шуңа күрә үзебезнең белгечләрне үстерүне төп юнәлешебез итеп карыйбыз да инде».



**Зөлфирә Сәлахова:** «Предмет авыр-җиңел, яратам-яратмыйм була алмый. Укытучыны ярата икән, бала предметны да ярата. Үзебез дә шулай идек бит. Балаларга мәгълүмат күп, аны эшкәртеп өлгермиләр. Белеме булып та, белемен бирә алмаган укытучылар була. Бездә андыйлар юк. Гаделлек – укытучы өчен иң мөһим сыйфат. Бер минусыбыз бар, укучыларыбыз артык тыйнак, әдәплеләр. Бераз чаялык та кирәк. Социаль уеннар аша анысына да өйрәтергә тырышабыз».



**9 нчы сыйныф укучысы Газизә Әкрамова, Бөтенроссия яшь язучылар һәм шагыйрьләрнең «Илһам» конкурсы лауреаты:** «1 нче класстан шушы гимназиядә укыйм. 11 гә калырга теләгем бар. Укытучылар һәм класс җитәкчем Зөлфирә Үрнәковна ошый миңа. Икенче әнием кебек ул. Аңа бөтен серне ышанып сөйләргә була. Ул беркайчан ачуланмый, кирәк чакта киңәшләрен бирә. Һәр мәктәп үз укучысы өчен яхшыдыр инде ул. Монда миңа татар мохите булу рәхәт. Укытучылар белән татарча сөйләшеп булуы да рәхәт. Иң яраткан фәнем татар теле һәм әдәбияты. Татар журналисты булырга хыялланам, шигырьләр язам (язмабызның баш исеме итеп сайланган сүзләр дә аның шигыреннән. – *Авт.*). Биергә яратам. Мулла Иле авылында «Яшьлек» бию ансамбле бар. Без шул авылга кайтып йөрибез, мин ансамбльдә биим, гитарада уйнарга өйрәнәм».



**Марат Халитов:** «Мәктәп кенә балаларны тәрбияли алмый. Тәрбиянең төп өч ноктасы – гаилә, мәктәп һәм урам. Бала урамда начар якка кереп китмәсен өчен, аның шөгыле булырга тиеш. Советлар чорында спорт секцияләре бар иде. Хәзер алар кабаттан ачылып килә, ләкин элемтәләр югалгач, бу әле авыррак бара. Элек һәр спорт секциясе берәр предприятиегә беркетелгән булды. Төп чыгымнарны оешмалар күтәрде. Ә хәзер бу чыгымнар – әти-әни өстендә. Бала, мавыгып, йөреп китә, ләкин берәр ярышка барасы булса, кыенлыклар башлана. Спорт формалары, инвентарьлар кыйммәт, моңа юл чыгымнарын да өстәсәк... Мәсәлән, чаңгы ярышында катнашу өчен бер пар чаңгы комплекты егерме меңләп. Ә ул ике пар кирәк. Спорт мәктәбендә булган чаңгылар белән генә бала яхшы нәтиҗәләр күрсәтә алмый шул».

– Бездә бит өйдәге кебек җылы атмосфера. Биш йөз бөртек балабызның барысын да исемләп беләбез, барысы да күз алларыбызда үскән балалар.

Мохит, тәрбия бик мөһим, билгеле. Ләкин мәктәп өчен барыбер дә белем бирүнең нәтиҗәлелеге, материаль-техник база, укучыларга өстәмә белем алу мөмкинлеге төп күрсәткеч булып тора бит. Балаларын кайсы мәктәпкә бирүне хәл иткәндә әти-әниләр бердәм дәүләт имтиханы нәтиҗәләренә карап та фикер йөртүчән. Татарча укып, рус телендә имтиханнар тапшыру авыр булыр дип уйлый алар.

– Авыр түгел! Һәрхәлдә, безнең балаларга авыр түгел, – ди Зөлфирә

ханым. – Алар ике телне дә камил белә, ике телдә дә фикерли. Аннары унынчы-унберенче сыйныфларда бездә дә фәннәр рус телендә укытыла. Моңа кадәр инде төп терминнарны русча да, татарча да өйрәнеп килгән укучылар өчен бу күчеш кыенлык тудырмый. Моны мин сезгә ышандырып әйтә алам.

Өч ел рәттән бердәм дәүләт имтиханы нәтиҗәләре буенча гимназиядә уртача балл – 80. Бу бик югары күрсәткеч. 96–98 балл җыючы укучылар күп.

Бу хакта рус теле һәм әдәбияты укытучысы, югары категорияле педагог Резеда Шамилевна Баһавиева белән сөйләшәбез. Рус теленнән хәтта 100 балл җыйган укучылары бар аның. Сере нидә икән?

– Татарлар гомер-гомергә белемгә тартылган. Укырга ярату безнең канда, геннарда. Татар мәктәбендә ул бик сизелә, – дип, гади генә аңлатты да бирде Резеда ханым. – Балалар тырышлар, итагатьлеләр. Татарларның традицион тәрбиясе белән дә бәйледер бу. Башка мәктәпләргә дә еш барырга туры килә, карыйбыз, чагыштырабыз... Әле менә өч ел рәттән укучыларның Бөтенроссия күләмендә узган «Человек в истории. Россия – XX век» фәнни-тикшеренү конкурсында катнашып, җиңү яуладык. Бер укучыбыз үз гаиләләренең ядкаре булган XVIII гасырга караган документларны өйрәнгән. Язучы Гүзәл Яхина да аның эшен югары бәяләп, китабын бүләк итте хәтта. Ә мине, укучыларны шушы конкурска әзерләгән педагог буларак, Евросоюз Германиягә кунакка чакырды. Андагы мәктәпләр, укыту системасы белән танышып кайттым.

Без инде мәктәп-гимназияләрнең түләүле өстәмә белем бирүләренә күнектек. Ә 5 нче гимназиядә бу дәресләр түләүсез (монысы да директорның тынгысызлыгы, тырышлыгы нәтиҗәсе). Кайсы фәннән белемен ныгытырга теләвенә карап, укучылар тарих, җәмгыять белеме, рус теле, математика, икътисадны сайлый ала.

Дүртенче сыйныфларда хореография дәресе иде. Заманча татар җырларына татар бию композициясен өйрәнүләре. Ул да өстәмә белем бирү кысаларында түләүсез үткәрелә. Хореограф Ләйсән Исмәгыйлева – гимназиядә 2002 елдан.

– Башлангычларда хореография дәресләре атнага бер тапкыр кирәк, – ди педагог. – Бик кирәкле дәрес дип саныйм мин аны. Физик тәрбия белән беррәттән, балалар эстетик тәрбия дә ала. Матур итеп йөрергә, музыканы тоярга өйрәнәләр. Замана баласына хәрәкәт җитми. Менә мондый дәресләр ул кытлыкны бераз булса да тулыландыра. Югары сыйныфлар белән исә бәйрәмнәргә, конкурсларга әзерләнәбез. Чыгарылыш класслар белән әле вальс биергә өйрәнәбез.

Татарлар – тарихлы халык, дибез. Кайсы гына мәктәпкә яки балалар бакчасына барсак та, күбесендә нинди дә булса музей булмый калмый. Яшел Үзән шәһәренең 5 нче гимназиясендә музейлар берәү генә түгел, икәү! «Сезнең әле андый музей күргәнегез юк!» – дигән иде Гүзәлия Наилевна. Дөрестән дә, Бөек Ватан сугышы чорында Советлар Союзы Герое исеменә лаек булган барлык татар каһарманнары турында мәгълүмат тупланган мондый музей дөньяда берәү генәдер. Бер стенд исә татар генералларына, генерал-майор дәрәҗәсендәге милләттәшләребезгә багышланган. Музейның инициаторы – Хөсәенов Александр Галинурович. Аңа кадәр бу эшне әтисе Галинур ага башлап җибәргән була. «Военкоматларга хатлар язып, авыл советлары аша бөртекләп тупладык без бу мәгълүматларны. Ул чакта әле интернет юк иде», – ди Гүзәлия ханым. Сүз уңаеннан, Гүзәлия Наилевна үзе тарих фәненнән укыта. Әлеге гимназиягә 1996 елда тарих укытучысы булып килә ул. 2001 елда инициативалы яшь белгечне район администрациясенә эшкә чакыралар. 2017 елда Яшел Үзән муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең урынбасары итеп билгеләнә. Ә 2018 елдан исә кабат яраткан стихиясендә – укучылары арасында. «Укучылар арырга да, авырырга да җай калдырмый. Алардан килгән ярату эшләргә дә, яшәргә дә көч бирә. Энергия ресурсларыбыз – балалар», – дигән сүзләреннән үк аның үз эшенә ничек бирелгәнен аңларга була.

Ике музей, дидек. Берсе – уен кораллары музее.

Унынчыларның иң яраткан фәне – тарих. Тугызларның да, унберләр, алтыларның да! «Балалар яшь укытучыларны ярата», – дигән иде Гүзәлия Наилевна. Тарихны үз итүләренең сере Диләра апалары Коротккованың әле беренче елын эшләгән яшь педагог булуында гына түгел, билгеле.

– Тарих кызыклы фән бит, – ди ул. – Ә балалар бик кызыксынучан, эзләнергә яраталар. Без алар белән төрле темаларга эссе язабыз. Әйтик: «Бөек Ватан сугышына багышлап төшерелгән совет фильмнары» яисә Бөек Ватан сугышында җимерелгән шәһәрләрнең элеккеге фотографияләре белән хәзергеләрен чагыштырып, архитектура объектлары турында... Моны язу өчен аларга эзләнергә, күп укырга кирәк. Үзләре өчен никадәр ачыш ясыйлар!

Кайтырга кузгалабыз. Кайсыдыр сыйныфның физкультура дәресенә чыгып барышы. Укытучы абыйларын сырып алганнар.

– Тагын бер бриллиантыбыз – Марат Дамирович Халитов, – дип таныштыра безне озата чыккан Гүзәлия Наилевна. – 29 ел шушы мәктәптә ул. Татарстан Республикасы укытучыларының аттестацион комиссиясе әгъзасы, Яшел Үзән шәһәре һәм районы буенча Бердәм дәүләт имтиханнарын кабул итү пункты җитәкчесе, «Ел укытучысы-2020» Бөтенроссия конкурсның зона этабы җиңүчесе. Узган ел физик тәрбия буенча Россия олимпиадасында ул җитәкләгән Татарстан командасы беренче урынны алды.

Быел август аенда 5 нче гимназия үзенең 30 еллык юбилеен үткәрергә әзерләнә. Кунакларны әле буяу исләре дә җилләп өлгермәгән, капиталь төзекләндерүдән соң өр-яңа булып балкыган мәктәптә каршы алырга хыяллана алар. Ә хыялның тагын да зуррагы – бүген милләт агачының талчыбыклары булган шушы укучыларның татар милләте өчен зур, ныклы агач булып үсеп җиткәннәрен күрү.

Галимә, шагыйрә, Саҗидә Сөләйманова исемендәге премия лауреаты Рәзинә Мөхияр иҗаты укучыларга «Нәрсә булды миңа?», «Асылыма кайтам», «Күңел тәрәзәләрем» китаплары аша яхшы таныш. Шигырьләре хатын-кызларга хас ихласлыгы, җылылыгы белән күңелләрне яулый. Тирән фәлсәфә дә, сагыш-моң да, ярату да, өмет тә түгелә алардан. Шигъри юлларыннан ук тел, милләт сагында торучы, халык язмышы өчен борчылучы, «кирәк чакта имән мин», дип кистереп әйтә белгән Рәзинәне таныйбыз. Игътибарыгызга шагыйрәнең яңа шигырьләрен тәкъдим итәбез.


Рәзинә МӨХИЯР

# УЙЛАР ОЧА ГАЛӘМ ТИРӘЛИ

### *Җан авазым моңы*

Төшләремдә күптән очканым юк,
Дөнья йөге тарта төшемдә дә.
Җылынасым килә, күккә очып,
Бураннарда йөреп өшимен дә.

Җылылыкны эзли җаным көн-төн,
Җылытырлык дәва – им-том җитми.
Җан авазым моңы кайтавазы
Үз-үземнән ары ерак китми.

Төшләремдә элек оча идем,
Канатларны җилләр сындырдымы?!
Бураннары, җиле, давыллары
Аллаһыдан миңа сынаудырмы?..
...Төшләремдә күптән очканым юк...

### *Имән мин*

*Баш бирмәгән горурлыгым*
*Үземә юлдаш әле.*
Әнгам Атнабай

Идерергә тырышмагыз,
Горур башым имәм мин.
Кирәк чакта – каен кызы,
Кирәк чакта имән мин.

Сытарга да тырышмагыз,
Мин тиз генә сытылмам.
Сатлыкҗаннар җан асрый дип,
Горур җаным саталмам.

Аяк чалып маташмагыз,
Күктән очып үтәрмен.
Язмыш язган үз йомгагым,
Бары үзем сүтәрмен.

### *Төшләремдә язам*

Шигырь язам, язам төшләремдә,
Төшләремдә мин бит шагыйрә.
Таңнар ата, илһам өркеп кача,
Өркеп кача язган шигырь дә,
Ярты җаным кала шигырьдә.

Дөнья мәшәкате, фанилыкның
Вак-төяге йота вакытны.
Килгән фикер, шигъри уй-хисләрем
Кире китә, алар вакытлы,
Тотып алып булмый якутны.

Шигырь язам бары төшләремдә,
Таң атуга төшләр югала.
Төшләремдә язган матур юллар
Офыкларга таба юл ала,
Энҗе бөртегедәй уала.

### *Мин генәме, әллә син генәме?*

Мин генәме, әллә син генәме
Кыерсыту, рәнҗеш алганнар?
Пәйгамбәрләр күрке Ибраһимны
Янган утка бәйләп салганнар.

Мин генәме, әллә без генәме
Үз дәүләтен күптән югалткан?
Баскынчылар күпме ир-егетне
Кылыч-сөңге белән тураткан.

Мин генәме, әллә ул гынамы
Җир байлыгын күрми төшендә?
Хәерчеләр кулын сузып тора
Байлык тулы дәүләт эчендә.

Мин генәме, әллә сез генәме
Бу Рәсәйдә телсез калганнар?
Телен, динен саклыйм дигәннәре
Тел, дин өчен башын салганнар.

Илсез, телсез, динсез без кемнәр?!

### *Дөнья матур*

Дөнья матур... ал күзлектән,
Ал күзлектән карасаң.
Каралыкны акка манып,
Караларын тарасаң.

Дөнья матур... өметләнеп,
Гел яхшыга юрасаң.
Бозландырып йөрәгеңне,
Телем-телем турасаң.

Дөнья матур... битарафлык
Күзлегеннән карасаң.
Этенә дә, бетенә дә
Ярый белеп ярасаң.
Дөнья матур...

## *Төнге тынлык*

Төнге тынлык. Бөтен дөнья йоклый.
Йоклый гамьсез, борчусыз тынып.
Йокламыйча шигъри сандугачым
Сайрый тагын җаныма кунып.

Төнге тынлык. Күзгә йокы керми,
Уйлар оча Галәм тирәли.
Уй корабы оча Җиһан буйлап,
Тукталышы әле күренми.

## *Заман кырыс*

Заман кырыс. Иләкләре тимер,
Тимер иләк нидер гел или.
Горур җаннар заман иләгенә
Каршы тора, башын һич ими.

Заман кырыс. Акча алдан чаба,
Бәндәләре – аның артыннан.
Бар нәрсәне акча белән үлчәп,
Шаша кебек кеше акылдан.

Заман кырыс. Кода-кодагыйлык
Ялагайлык, ришвәт дөньясы.
Кыргыйлыклар бәйрәм иткән илдә
Гөнаһлармы аның йоласы?
Авыз, күзне ничек йомасы?!

## *Сагышланма, йөрәк*

Табигатьтә тезелешеп оча
Ел фасылы – вакыт кошлары.
Кешенең дә гомер фасыллары:
Язы, җәе, көзе, кышлары...
Гомер үтә диеп өзгәләнмә,
Сагышланма, йөрәк, сызлама.

Табигатьтә бар да исәпләнгән,
Һәр фасылның – якты яклары.
Күңелләрдә һаман сакланырлар
Ул көннәрнең якут чаклары.
Гомер үтә диеп өзгәләнмә,
Сагышланма, йөрәк, сызлама.

## *Татар авыллары*

Татар авыллары –
Милләт сакчылары,
Телнең ачкычлары,
Әхлак баскычлары.

Заман давыллары,
Чорның кыраулары,
Илнең кануннары
Йота авылларны.

Кая дарулары,
Саклау чаралары,
Имләү яраларын
Татар авылларын?!

## *Күз кыравы*

«Сөбханалла!» – дип карачы,
Күз тидерәсең инде.
Күзләрең дә, сүзләрең дә
Биздермәсеннәр иде.

Сокланып караганны да
Күтәрәлмим нигәдер,
Шиңеп калган чәчәк булам,
Күз кыравы тиядер.

Аллаһ биргән матурлыкка
«Машалла!» – дип карачы,
Ялгыш тиеп куймасын дим
Күзләреңнең карасы.

## *Калфаклары*

Калфаккаең йөзләреңә
Бик килешә, аппагым.
Матурлыгың, күркәмлегең
Кемнәр өчен сакладың?!

Татар кызлары калфаклы,
Калфаклары чигүле.
Яучылары кайчан килер,
Кемгә атлар җигүле?!

Калфакларның төрлесе бар:
Агы, күге, яшеле.
Җиткән кызлар калфак кия,
Күзләре бигрәк серле.

Калфаклары, калфаклары...
Гасырларны иңләгән.
Калфаклы кызларны халкым
Хан кызына тиңләгән.

## *Кайчагында*

Кешеләрне аңлау өчен
Кайвакытта гомер китә.
Кайчагында... тотырып бер
Карап алу – шул да җитә.

Кешеләрне аңлау өчен
Күпме тоз ашалып бетә.
Кайчагында... читтән генә
Күреп калу – шул да җитә.

Кешеләрне аңлау өчен
Көннәр үтә, еллар китә.
Кайчагында... сирәк кенә
Керфек сирпү – шул да җитә.

## *Кеше гомере ничә чордан тора?*

Кеше гомере ничә чордан тора?
Чордан чорга күпме барасы?
Һәрбер чорның елы, көне күпме,
Мизгелләрнең күпме арасы?

Мизгелләре коштай очып үтә,
Очышлары мәңгелеккә дип.
Тик берсе дә аның кабатланмый,
Очышлары чиксезлеккә бит.

Кадерләрен генә белеп булмый,
Җанга тезеп булмый мизгелне.
Үткән гомер никтер сагындыра,
Тотып калып булмый тезгенне.

Һәр мизгелнең,
һәр сулышның кадрен
Аңлау бәхете килә бик соңлап.
Аңлаганда үкенеч-югалтулар
Кайтавазы яңгырый чыңлап.

## *Минем күңел*

...Минем күңел нидән ясалгандыр?!
Артык нечкә, артык нәзберек.
Һич тә күтәрәлми авыр сүзләр,
Төшеп китә җиргә өзелеп.

Минем күңел нидән ясалгандыр?!
Артык тоя, артык нык сизгер.
Җылы сүздән үрелә күкләргә,
Канат үстерүләр бик тиздер.

Минем күңел нидән ясалгандыр?!
Әле җирдә, әле һавада.
Матур сүзләр генә әйтче миңа,
Күзләремә төбәп кара да.

## *Көтәм*

Көтәм...
Сызылып алсу таң атуын,
Кояшымның назлы балкуын,
Нурларының тигез януын,
Гөлләремнең өскә калкуын,
Берөзлексез чәчәк атуын,
Чәчәк күреп йөзләр балкуын,
Җанда өметләрнең калкуын,
Сөюемнең тагын кайтуын,
Һәр кич саен кояш батуын,
Иртәгәсен таңның атуын
Көтәм.





Укучыларыбыз Кәрим Кара хикәяләрен һәрчак көтеп ала. Чөнки аларда – гыйбрәтле язмышлар, көтелмәгән вакыйгалар, гаиләдәге сөенечләр һәм көенечләр белән тулы чын тормыш. Һәм ул хатын-кызлар күңеленә бик якын булган темаларны кузгата. «Фатиха» – авторның тагын бер өр-яңа хикәясе.



Кәрим КАРА

# ФАТИХА

(Хикәя)

Вәлиулла өенә кайтканда ярты төн узган иде инде. Чатан Садри аны тыкрык башына кадәр үз машинасында китереп куйды. Калган кырык-илле адымны алпан-тилпән ничек тә үтте. Кызыл кирпечтән салынган зур өенең аш бүлмәсендә ут яна иде әле. Сәкинәсе йокламагандыр болай булгач. Йоклап кына карасын!

Капка-ишекләрне бәреп-сугып өйгә үтте ул, ишек яңагына сөялеп:

– Сәкинә-ә! – дип кычкырды. Аш бүлмәсе ягыннан, ашыгып, хатыны килеп чыкты, куркынган карашларын чак басып торган Вәлиуллага төбәде.

– Нигә как следовает каршы алмыйсың иреңне? Әллә борын сызгыртып йоклап ятасыңмы, ир кайгысы юкмы синдә? Азрак талкыганмындыр шул мин сиңа бу хакта. Тагын өстисе булган... сеңдерерлек итеп... – Вәлиулла чукмардай йодрыгын уңга-сулга селеккәләде.

– Нинди йокы булсын, әтисе. Һәр адымыңны ишетеп тордым. Ашны җылытырга куеп йөрүем, – дип, гаепле тавыш белән сөйләнде хатыны, килеп Вәлиулланың аяк киемен салдырырга талпынды.

Барысы тәртиптә булуына күңеле булып, Вәлиулла урындыкка җәелде.

Бу вакытта уйлары хатыны тирәсендә уралды. Йокламадым дигән була, кайдан беләсең хатын-кызның хәйләсен? Аның дөбердәп керүенә йоклап яткан кеше дә сикереп торыр иде. Ну ирне ир итәргә кирәген хатынының канына сеңдерә алды шикелле. Ул чүпрәкбашларны уч төбендә йомарлап тотарга кирәк. Бераз ирек бирсәң, тәртип бетте диген. Җылы якларда әнә дөрес чиклиләр хатын-кызны. Баштанаяк бөркәнгән булсын, чит ир-атка күтәрелеп карамасын, ирен хуҗа итеп танысын, дөньясын җигелеп көтсен. Бер хуҗа булырга тиеш өйдә.

Бүлмә аша хатынының зәгыйфь кенә тавышы ишетелеп калды:

– Капкалап аласыңмы, өстәл әзер...

Вәлиулла өстәл артына чыгып утырды. Токмачлы ашны бер-ике капты да, чыраен чытып, читкә этеп җибәрде. Тәлинкә чак өстәл читенә эләгеп калды, шулпа ашъяулык өстенә чайпалып түгелде.

– Шыр тоз иткәнсең! Картайганчы аш пешерә белмәдең. Кая, берәр чынаяк чәеңне китер дә, торма каршымда катып...

Хатыны шәүлә төсле тавыш-тынсыз чыгып югалгач, Вәлиулла комсызланып кайнар чәй чөмерде. Алдына куелган аш тозлы түгел иде анысы, артык җәелеп китмәсен өчен генә хатынын шелтәләде. Кайтырга чыкканчы ул мул табын артында утырды, калҗа-калҗа симез сарык ите кимерде, каз итеннән пешерелгән бәлешне берүзе диярлек ашап бетерде.

Чатан Садри шулай кунак итте аны, алдында йөгергәләп торды. Чөнки Вәлиулла абыйсы кирәк иде аңа. Аннан башка күпләр бер адым да атлый алмый бу авылда. Чатанның өстәле артында эчемлекне дә күп чөмерде ул. Менә хәзер чәйгә тансыклаган инде.

Ә хатыны ничауа гына Садриның. Вәлиулланың һәр сүзенә елмаеп-көлеп кенә торды. Садри нәрсәгәдер икенче бүлмәгә чыкканда, тәмам сырпаланып, Вәлиулланың иңбашларына да кагылып

куйды әле мут хатын. Аның белән киләчәктә якыннанрак танышырга кирәк булыр.

Тамак кипкәне басылгач, веранда баскычына чыгып утырды, тәмләп тәмәке суырды. Ә менә үз хатыны белән күптән назланмый инде ул. Назлана да, назлый да белмәде шул хатыны. Ул яктан уңмады Вәлиулла. Хәер, тормышында хатын-кызлары җитәрлек булды анысы.

Язмыш аргамагының йөгәнен кулларында чытырдатып тотып яшәде ул. Гомер буе склад мөдире булып эшләде. Таныш-белеш күп булды, абруй зур иде. Башың эшләсә, бик тә төшемле урын ул. Теләгәнен ашады, теләгәнчә эчте – тоташ бәйрәм иде гомере. Кемгәдер баш имәде, аңа бил бөгеп килделәр. Әле дә махы бирми. Өе урап чыккысыз, абзар тулы терлек, гаражында машинасы җырлап утыра, саклык кенәгәсендә шактый акчасы саклана. Әле теттереп яшәр, 55 яшь ирнең кырган орчык кебек чагы...

Кәефе шәп, күңеле җырлый иде Вәлиулланың. Хәзер кереп йомшак түшәккә сузылачак та иртәнгә кадәр изрәп йоклаячак. Утларны да сүндереп тормыйча бүлмәсенә үтте. Хатын ни өчен? Сүндерер, бикләр, саклар тәртипне.

Урыны җәелгән иде, Сәкинәсенең генә тавышы-тыны ишетелми. Мыштым гына үз бүлмәсенә посскандыр. Аның шулай шәүлә төсле тавыш-тынсыз йөрүенә ачуы да килә иренең. Әйтерсең бер өрәк белән яши...

Вәлиулла керә-керешкә өстендәге костюмын почмакка салып атты да, барып урынына ишелмәкче булды. Тик ике адым гына атлап өлгерде: үзе дә сизмәстән, тубыкланып төште. Каршында ниндидер иләмсез зур яфраклар пәйда булды. Гөл икән лә ул, фикус гөле, чыгарып бәрсен, иртәгә үк хатынына әйтергә кирәк!

Вәлиулла кулларына таянып калкынырга теләде, ни гаҗәп, аякларын бөтенләй тоймады. Үҗәтләнеп, көчле бармаклары белән ботын борып чеметеп алды – черки тешләгән кебек тә авырту сизелмәде. Бар тәнен моңарчы тоелмаган ят халәт биләп алды. Йөрәге, әнә туктыйм, менә туктыйм дигәндәй, әкрен генә тибәргә тотынды, авызы ябылып бетмәстән, яшь балаларныкы төсле төкерege агып төште. Каршыдагы тәрәзә караңгылыгында ниндидер очып йөргән ак япмалар күзенә чалынып калды. «Үләм!» дигән ят уй миен көйдереп алды. – Үлемем шушы икән...» Эчкечелектән барысы!.. Соңгы араларда чаманы узган иде шул. Көн дә сәбәбе табыла, иртәдән кичкә кадәр чөмерә дә чөмерә. Ул йөрәк ничек чыдасын? Туктарга, ял бирергә кирәк организмга. Иртәгә иртүк мунча яктырырга. Юк, иртәгәне өмет итәсе түгел шикелле инде...

– Сәки-и-нә, – дип дәшәргә көч тапты ул үзендә. Көтеп кенә торгандай, хатыны каршысына килеп басты.

– Булыш торырга, – дип, хатынына кулын сузды ул. Юка гына хатынының көче җитәрлек идемени соң аның биш потлык гәүдәсенә?!

– Маташма, – диде ул шактый матавыклангач, еш-еш сулап, – фатиханды бир миңа җан тәндә чакта. Мин үләм, Сәкинә...

– Врач чакырыйммы? – дип, бөгелеп төште Сәкинәсе. Кая барып бәрелергә, нәрсә эшләргә белмәде ул. Вәлиулла кемдер каршында шул хәлдә ятармы? Әлегә кадәр мескенләнгәне булмады, моннан соң да булмас...

– Ки-рәк-ми, – диде ул өзеп-өзеп. – Соң инде. Риза-бәхиллегеңне әйт. Миңа бит җавап бирәсе...

– Хәзер йөрәк даруы алып киләм, – дип, хатыны йөгерә-атлый чыгып китте. Бу вакытта Вәлиулла аның өчен иң кирәкле сүзләрне хатынының әйтергә теләмәгәнен аермачык аңлады. Нишләп бәхил булырга тиеш ди ул иреннән? Вәлиулла бит аны эт урынына да күрмәде. Йодрыгын уйнатып кына торды хатыны өстендә. Сәкинәсенең йөзеннән күгәрек китмәде, ничә тапкыр кабыргасы сынды, тешләре коелды, аякка басалмас булып урын өстендә кан косып ятты. Исерек баштан барысына да өстән генә карады Вәлиулла. Ничек җан саклый әле ул изелгән, җәберләнгән, аяк астына салып тапталган мескен зат?

Очраклы рәвештә соңгы мизгелләрендә бу гөл каршына килеп тубыкландымы ул? Гөл каршында түгел, әнә аның кырында басып торган акшарлагандай ак йөзле, зур күзле, ябык кызы Рәмилә каршында тубыкланды ич ул. Мескен бала, ютәленә төелеп, елап-елап, көн дә мәктәпкә барырга ашыга иде. Шул вакыт телсез, карусыз хатыны:

– Балага киез итек алырга иде, кул сыярлык тишек аяк киемендә, – дип мәрхәмәт сораган иде.

Ул чакта кәефләнеп алган Вәлиулла, кызарынып-бүртенеп, Сәкинәсенә акырып кына куйды. Кызган баштан хатынының сүзләре кызык кына булып тоелды.

– Үзең алып бир йон эрләгән акчаларыңа, – дип, ишекне бәреп чыгып киткән иде. Ә баланы өч көннән шәһәр больницасына алып киттеләр. Дөресрәге, Сәкинә кемгәдер гозерләнеп алып китте, Вәлиулланың һәрвакыттагыча вакыты юк иде. Ниндидер озакка сузылган кунакка тарып, күрше авылларга чыгып китеп, күңел ачып йөргән чагы иде. Мамык кебек җиңел генә калган олы кызын ләхеткә салганы уяулы-төшле генә хәтеренә язылды. Бераз айный башлагач, үтереп башы авыртканда хатынына:

– Рәмилә кайда килеп сарып йөри, күзгә чалынмады, – дип һушын алган иде. Сәкинәсе күз яшьләренә төелеп, үксеп елап чыгып киткән иде ул чакта. Шул бала аннан риза-бәхил булсынмы? «Әти!» – дип, бер килеп сыену бәхетеннән мәхрүм булган сабый хәзер синең гөнаһларыңа разый булсынмы? И Вәлиулла, Вәлиулла...

– Менә бу даруны эчеп кара, йөрәгеңә хәл кертер, – дип, ниндидер төймә сузды Сәкинәсе, су йоттырды. Агу йоттырса да таман гына буласы иде дә соң. Кара, иреннәрен ничек кыскан. Бу иреннәр ачылып, аңа мәрхәмәт сүзләрен әйтәселәре юк!

– Мендәрне ташла баш очыма, шунда гына башымны терим. Әллә хәл кереп китәр, – диде ул күзләрен йомып.

Хатыны утны сүндереп чыгып китте. Алгы бүлмәдән төшкән сүрән яктылык кына саркылды Вәлиулла яткан урынга. Аның ишеткәне бар иде, хәзер бит дин турында белүчеләр – адым саен, сөйләгән иде кайсыдыр... Тегендә, имеш, бар гөнаһларның гафу ителүенә өмет итәргә була. Аллаһ рәхимле үз бәндәсенә, зәгыйфь зат икәнебезне белә безнең, күп очракта аралый уттан. Әмма дә ләкин бәндәнең бәндәгә кылган начарлыгына Аллаһ Тәгалә ташлама ясамый. Син башта зар елаткан адәмнең бәхиллеген ал, шул чакта гына миһербан булыр синә.





Баскан урынында җир уеп йөргән шәпле Вәлиулла да үлемнән курка иде. Халык арасында аның кушаматы «алпавыт» булды. Берәрсе яраттымы икән аны? Юктыр. Әмма барысын куркытып, барысын бер җепкә бәйләп тотты. Үлем алдында шәпләнеп булмый икән. Монда синең әтәчләнүләреңнең поты бер тиен.

Бер якын кешесе юк бит хәлен белешерлек. Хатыны ышанмады да шикелле чиренә. Тагын берәр мәкер уйлыйдыр дип фаразлагандыр. Тонсын иде, котылырмын дип уйлап куйгандыр. Әллә Тәңрегә ялвара торгандыр бар күңелен салып, ал шул ләгънәтнең кара җанын, дип. Нәсел дәвамчысы, улы Наил кайтса ни була? Соңгы тапкыр күреп калыр иде Вәлиулла. Ни дисәң дә, әти кеше бит ул. Дөресен генә әйткәндә, әтилеге чамалы булды.

Улы тугач нык шатланган иде ул. Хәтерендә, кендек әбисенә шау чәчәктән күлмәклек бүләк итте. Авылда юк иде андый затлы товар. Күп өметләр баглады улына. Әти кешеләр шундый буладыр инде. Тик аларның улы гына башкаларныкыннан акыллырак, зирәгрәк, остарак, гайрәтлерәк дип ышаналар. Тоташ бәйрәмнән торган тормышында өзек-төтек кенә улын кулында сикерткәннәре, шаяртып түшәмгә очырганнары хәтердә калган. Менә Наиле мәктәп чорына кергәч, ныклап тотынды ул улын тәрбияләргә. Ни гаҗәп, шул бала, кемгә охшаптыр, бөтенләй башсыз булып чыкты. Гади генә мисаллар да аңына барып җитәлми иде шул имгәкнең. Карап торышка төгәл кебек бар яктан.

Вәлиулла, берәр чәркә салып, дәресләр әзерләтеп маташты улына. Сүз генә үтмәгәч, кулына солдат каешын бөкләп алып утыра торган булды. Аш бүлмәсендә хатыны Сәкинә дерелдәп утыргандыр аларның шөгыльләнүеннән. Әти кешенең тыныч кына сөйләшүе ике-өч минутка гына җитә иде. Шуннан каеш белән белем кертергә тотынды баласына. Акыллы булсын, янәсе. Бер кызып киткәннән соң, тотнагын югалткан улының тубыкларын калтыратып, идәндәге күлдәвек өстендә басып торуын шәйләгәч, башка тәрбия белән булашмады. Өметен өзде ул килделекиттеле баладан.

Моннан соң улы белән гел кычкырып, әмер биреп, атыюлы белән сүгеп, җилкәсенә тамызып кына сөйләшә торган булды. Чак кына әтисенә тарткан булса да, Вәлиулла аны бер дигән итеп тәрбияләр иде. Чакырган чакларда киндердәй агарып, катып кала иде Наиле. Куркак адәмгә бу җирдә урын бармыни? Укудан да тәки булдыра алмады. Сигездән соң әнисенең туган авылына чыгып китте. Әле дә шунда ферма тиресендә казына. Кабергә аяк баскан 90 яшьлек әбисендә яшәп ята. Хаклы булган Вәлиулла, рәтле-башлы кеше чыкмады малайдан. Әле дә айт дигәнгә тайт дип, теләсә кемгә йомышчы булып йөри, диләр. Гаилә кормаган һаман. Вәлиулла озаграк өйдә булмаса, Сәкинәсе, яшерен генә барып, улының хәлләрен белеп кайта шикелле. Ә малайның чыгып киткәненнән бирле берәр тапкыр кайтып, авыз ачып «әти» дип әйткәне юк. Үстер-үстер дә баланы, ашат, киендер дә, әнә шул була сиңа рәхмәт...

Шул мизгелдә Вәлиулланың үтереп су эчәсе килә башлады. Бер йотым су өчен әллә ниләр бирердәй булды. Юктан гына тумаган икән теге әйтем: үлгән чагында бер кашык су эчерүче булсын. Ерак юлга чыгар алдыннан түзеп булмаслык дәрәҗәдә тамак кибә икән.

Ярым саташып, су күзаллады ул. Менә ул, биш-алты яшьләрдәге малай, иптәшләре белән колхозның яшелчә бакчасыннан кайтып килә. Күк йөзендә рәхимсез кояш кыздыра. Алар корсаклары күпкәнче яшел борчак ашадылар, кишер кимерделәр, ә хәзер су таптыра кипкән тамаклары. Арып-талып, Бакый чишмәсенә килеп җитә алар, челтерәп аккан чишмә суы тирәли сузылып яталар да туя алмыйча су эчәләр. Эчкән саен эчәсе килә бу тешләрне камаштырган тәмле суны...

Дерт итеп һушына килеп киткән Вәлиулла, кипшенгән иреннәрен ялап, Сәкинәсен чакырырга авызын ачты. Әмма кире уйлады. Үпкәсе зур иде аның хатынына. Чирек гасыр бер түбә астында яшәгән җәмәгатең тормыш белән хушлаша, ә син шуңа бер йотым су эчерергә карыш инде. Килсен иде янына, сорашсын иде хәлеңне, берәр җылы сүз әйтсен иде. Яхшымы-начармы, Вәлиулла ире була бит шул күрше бүлмәдә түшләр күреп йоклап яткан хатынның. Гел генә начар булып тормагандыр бит ул, иркәләгәндер дә, кочкандыр да. Менә бу күкрәп торган дөнья кем куллары белән төзелгән?

Яхшылык өмет итәсе түгел бу хатыннан, никахлашкан ирен дошманнары исемлегенә язган. Бәлки, төпчек кызы Фәния рәхим-шәфкатьлерәк булыр иде? Менә ул, ичмасам, укуда алдырды. Ни гаҗәп, кыз балалар яхшырак укый, үткеррәк була. Ләкин ул баласына да үрнәк әти була алмады Вәлиулла. Фәниясе үскән еллар аның район үзәгендә яшәгән плановик Хәлимә белән мәхәббәт уйнаган чорга туры килде. Тол хатын Хәлимә ничек тә Вәлиулланың гаиләсен тузгытып, ирне үзенеке итәргә көрәш башлады. Көн аралаш диярлек районга чапты Вәлиулла, яңа мәхәббәтендә мунчалар кереп, пилмәннәр ашап, атналар буе хәмер чөмереп ятты. Үзен бөтенләй икенче тормышта яшәгәндәй хис итә башлаган иде ул. Шуңа да сирәк күрешүләрдә Сәкинәсен дә, балаларын да җен урынына күрде.

Тәмам күченергә җыенып беткән иде инде, нигәдер кире уйлады, күңеле кайтты Хәлимәдән. Чамалады акылы белән: бер барып капса, ычкына алмаячак җәтмәдән. Хәлимә – юаш Сәкинә түгел, читкә бер адым атларга рөхсәт итмәячәк. Дуларга уйласаң, ике уйлап тормый, бозым ясаячак, агу эчерәчәк, җаныңны җәһәннәмгә олактырачак! Бу дөньяда иргә сусаган ялгыз хатыннар беткәнме? Хәлимәдән болайрак әллә күпмене табарга була.

Шулай икеле-микеле йөргән елларда Фәния гел «дүртле», «бишле» билгеләренә мәктәпне тәмамлады.

– Укырга керергә ниятләгән идем, әти, – дип ярдәм сорады ул. – Миңа укыган елларда акчалата ярдәм ит әле, зинһар. Һәр тоткан тиенеңне язып барырсың. Соңыннан барысын эшләп түләрмен, – дип ялынды.

– Әндри казнасы бармы әллә монда? Әлеге яшеңә кадәр караганга рәхмәт әйт. Эшләп укы, акыллы кешеләр шулай итә, – дип кырт кисте.

Ул кызы шәплерәк иде, чыбык та әзрәк элəкте анысына, Вәлиулла да олыгая төште. Ачы телле иде, шуңа йөзенә бәреп әйтте:


Рәсем: Наталья Васильева

– Сиңа көнем калмасын. Башка әти дигән сүзне ишетмәссең миннән, бусагаңны атлап кермәм. Укырмын да, кеше дә булырмын. Сиңа күрергә булсын кылганнарыңның җәзасын. Әни генә жәл, – дип, бер кул сумкасы тотып чыгып китте өйдән. Анысының да күзгә күренгәне юк. Сәкинәдән кайчак сораштыра да Вәлиулла, гел укый ди. Тәки сүзендә торган икән. Юк, ул кызы да кипкән тамагын җебетмәс иде аның...

Әле менә үз гаиләсендә булып үткән вакыйгалар яңарды, ә уйлап китсәң, күпме кешене ул кан яшьләре белән елатты, җәберләде, мәсхәрәләде, камыр урынына изде. Ул яшәдеме бу тормышны? Бетмәс-төкәнмәс бәйрәм булдымы шундый яшәү?..

Бөтенләй түземлеге төкәнеп, Вәлиулла Сәкинәсен дәшәргә булды. Авызын ачып, аңлаешлы авазлар чыгарырга азапланып карады, хәленнән килмәде. Ниндидер боз салкынлыгы аяк бармаклары, кул бармаклары буйлап үрмәләгәнен тойды ул. «Җан чыгу дигәннәре шул була икән», дигән коточкыч уй үтте башыннан. Бәлки, ризыгы тәмам азагына җиткәндер, башкача бер йотым су да язылмагандыр фанилыкта.

Җан ачуы белән фикус гөле утырган кечкенә урындыкны этеп җибәрә алды ул. Зур савыттагы гөл, бүлмә яңгыратып, идәнгә тәгәрәде, тирә-якка туфрак чәчелде. Берничә бөртек балчык ирнең күз кабакларына, иреннәренә ягылды. Менә шулай җиргә тартыла башлады бугай инде.

Күрше бүлмәдән, очып, Сәкинәсе килеп чыкты, утны кабызды. Өс киемен дә салмаган хатыны, күзләре кара янып чыккан. Йокламагандыр, ахрысы, утыргандыр үткән гомерендә иренең кәмитләрен исенә төшереп.

– Су... су... – дип авызын кыймылдатты Вәлиулла, ялынычлы карашын кешегә дә чутламый яшәгән хатынының сырлар капларга өлгергән йөзенә юнәлтте. Аңлады, рәхмәт төшкере, йөгертеп чынаяк алып чыкты. Диңгез эчеп бетерердәй булып сусаган иде Вәлиулла, ике йотудан артык китә алмады. Теләк тә киртәләнә икән соңгы адым алдыннан.

– Ярар, гафу итә алмыйсыңдыр... – диде ир, суына башлаган учына Сәкинәсенең кулын кысып.

Хәле бетте аның, еш-еш тын алып ял итте.

– Нигә ташлап китмәдең син бу тормышны? Нигә түздең?

Сәкинәсе, елмая төшеп, тынып калды.

– Жәлләдем мин сине...

Менә сиңа мә! Аны бу җирдә күралмадылар, курыктылар, бәддога укыдылар, аңа яраклаштылар, куштанландылар, көнләштеләр, каргадылар, бәлки, битарафлар да табылгандыр. Әмма жәлләгән кеше?

– Син бит шайтан фигылендә яшәдең. Ни дисәң дә, син минем хәләл ирем, балаларымның атасы. Бөтенләй юкка чыга идең янында мин булмасам.

Үләр алдыннан гына адәм баласы кайбер кыйммәтләрне аңлый башлый. Әмма соң була шул, соң була...

Теге тәрәзә артындагы ак япмалар бүлмә эченә үттеләр, түшәмгә күтәрелеп, Вәлиулла өстендә зыр-зыр әйләнергә тотындылар. Кинәт караңгылык чорнады ирне, тәне-гәүдәсе берни сизми-тоймый башлады. Бары ерактан, бик ерактан таныш тавыш ишетелеп калгандай булды:

– Риза-бәхилмен синнән, Вәлиулла. Фатихамны бирәм. Соңгы яхшылыгым шул булсын. Тыныч йокла...





# Роза Халитова: «МУЗЫКА БЕЛӘН ЯШӘҮ ҖИҢЕЛРӘК!»





Алсу ШАКИРОВА

**– «Концерт» дүрт сәгать бара, түзәрсең микән, сеңлем?**
**Роза Фатыйховна җавабымны да көтмичә, беренче дискны куеп та җибәрә. Әңгәмәбезне шулай башларга теләде ул. Үзенең 60 яшьлек һәм иҗатының 40 еллык юбилеена багышланган концерт дисклары егерме ел элек яздырылган. Роза ХАЛИТОВАның укучысы, тавыш режиссёры Камил Фәйзрахманов бу дискларны остазына истәлек өчен яздырганда, киләчәктә аларның мөгаллимә өчен нинди кыйммәткә ия булачагын күз алдына да китермәгәндер.**

# Роза Халитова – башка милләттән кергән уен коралы домрага татар моңын ирештерүче.

– Юбилейга әзерләнеп йөргәндә, Татар дәүләт филармониясе директоры ачулана үземне: «Роза Фатыйховна, көне килеп җитә бит инде, афиша да, билетлар да юк. Сатуга кайчан бирергә уйлыйсыз?» – ди. Ә аларның кирәге дә булмады! Сатарлык бер билет та калмады, сүзе чыкканчы ук алып бетерделәр!

...Менә мин тыңларга тиешле «концерт» башлана. Уйнаткыч колонкалары аша Ринат Еникиевнең «Һәр кич саен» дип аталган әсәре яңгырый... Домра һәм фортепианога күчерелеш – Роза Халитованың иҗат җимеше! Концертның ялгыз домра тавышыннан башланып китүе дә символик әһәмияткә ия. Өч кыллы инструмент, безгә юбилей иясенең тарихын сөйләгәндәй, күңел кылларына үрелә: «Тыңлагыз, янәсе, бу шәхеснең тәрҗемәи хәлен күңел күперләре аша үткәрегез...» – дия кебек. Бу урында гүя үзеңне дә танылган музыкант, мөгаллимә, дирижер, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, мандолина һәм домрада уйнаучы Роза Фатыйховнаның гомер юллары буйлап атлап баргандай хис итәсең. Роза Халитованың яраткан композиторы Ринат Еникиев иҗат иткән көйгә ияреп, балачак елларына, туган ягына «юл тотабыз».

Аның балачагы очсыз-кырыйсыз урманнары, таулары белән дан тоткан Уралда үтә. Чыгышлары белән Чаллы ягыннан булып та, әти-әнисе шушы якларга килеп урнаша, гаиләдә җиде бала аваз сала. Роза – иң төпчекләре. Әниләре колхозда хезмәт куя, әтиләре мәктәптә латин теле дәресләре бирә. Авырлыклар арты куанычлар алышынып торса да, шау-гөр килеп яшәгән җирдән гаиләгә хәсрәт килә – әти кеше хатыны, балаларын ташлап, икенче гаилә кора. Әниләре берсеннән-берсе кечкенә балалар белән кала. Төпчек кызы әтисен хәтерләрлек яшьтә дә түгел, сабыйга 2 генә яшь була. Әнисе белән бергә олы апасы да гаилә тәртәсенә җигелә.


– Апа, мескенкәем, туя торган булгандыр бездән. «Нигә бу кадәр бала таптың, әни?» – дип әйткәннәре хәтеремдә, – дип искә ала Роза ханым ул ачы елларны. Кызга 7 яшь вакытта алар Миасс бистәсенә (соңрак ул шәһәр булып үсә) күченәләр. Сугыш елларында Уралга күпсанлы сәнәгать предприятиеләре эвакуацияләнә. Шул исәптән, Миасска да Мәскәүдән Лихачёв исемендәге заводны җибәрәләр. Завод каршында мәдәният йорты, концерт мәйданчыклары, парклар төзелә, кайнап торган тормыш башлана.

Розаның апасы Римма мандолинада уйнарга өйрәнә. Җырларга да бик оста була ул. Саный китсәң, гаҗәеп күренеш: гаиләдәге һәрбер бала – үзе бер талант! Кайсы музыка белән шөгыльләнә – гармунда, мандолинада, гитарада уйный, кайсы рәсем ясый. Өйләрендә сатып алынган бер генә йорт җиһазы да юк – барысы да абыйларының кул хезмәте, осталык һәм тырышлык нәтиҗәсе. «Без яшәгән баракның верандасында әсирлеккә төшкән венгрлар гаиләсе яши иде. Гаилә башлыгы мандолинада, уллары гитарада бик матур көйләр башкаралар. Ял көннәрендә барак халкының яртысы төрле уен коралларында уйнап, бергә күңел ача торган идек. Мин менә шул атмосфераны, музыка яңгырашын сеңдереп үстем. «Син зур үстең инде, Роза», – дип, апа мине клубтагы түгәрәккә дә яздырды».

Берничә елдан Роза «УралЗИС» заводы каршындагы халык уен кораллары оркестрында уйный башлый. Менә шул вакытта домрага чын-чынлап күңеле төшә кызның. Завод хезмәткәрләренә ияреп, атнасына өч көн оркестрга йөри. Юрий Александрович Пастухов җитәкчелегендә концертлар, бәйгеләр, җыр бәйрәмнәре оештырып, үзе дә катнашып, зур тәҗрибә туплый ул. Ирекле тыңлаучы булып, янәшәдәге музыка мәктәбен дә тәмамлый.

...Аудиоязмада концерт дәвам итә. Ринат Еникиевнең «Синең эзләр» әсәрен Татарстанның халык артисты Наҗия Теркулова башкара. Еникиевны тыңлаганда, Роза ханым беравык тынлыкка ияреп, уйлары белән әллә кайларга китеп югалгандай була... Хисләр дулкынында вакытны янәдән артка борабыз.

Магнитогорск шәһәре. Роза Халитованың Михаил Глинка исемендәге музыка училищесының



Роза Халитова язучы Гомәр Бәширов белән рәссам Бакый Урманчеда кунакта.

# Иң аянычлы югалтуы ул аның – бик зур өметләр баглаган, үз эшен курыкмыйча тапшырып калдырырга теләгән укучысы...



Роза һәм Иттаки Халитовлар, Казан, 1976 ел.

халык уен кораллары сыйныфында уку елы башланыр чак. Ләкин кызыксынучан, тынгы белмәс студент үзен уку белән генә чикләми. Төгәл бер елдан Магнитогорск шәһәре мәктәбендә уен кораллары оркестрын җитәкли башлаячак ул. Менә кайчан кирәк була «УралЗИС» оркестрында туплаган оештыру тәҗрибәсе! Остазларына гомере буе рәхмәтле Роза. Әле дә сүз саен аларны искә ала. Әмма кыз үзе дә бик тырыш, сүз тыңлаучан була. Остазы нәрсә әйтсә, берсүзсез шуны эшли торганнардан, ягъни. Әнә шулай, Леонид Аркадьевич Аншелес киңәше белән, өч ел укыганнан соң, диплом да алмыйча, Мәскәүнең Гнесиннар исемендәге музыка-педагогика институтына юл тота. Соңыннан бик үкенә әле бу киңәше өчен Леонид Аркадьевич. «Эх, юләр булганмын, тагын бер ел укыта ала идем бит әле сине, нигә ашыктым икән?» – ди ул җан ачысы белән. Ләкин Уралда чыныгып үскән кыз авырлыкларга бирешәме соң?! Музыка училищесы дипломы булмаса да, кулында музыка мәктәбе аттестаты бар, музыка тәгълиматын су урынына эчә, домрада шактый күп авторның әсәрен яттан башкара ала!

«Мәскәүгә самолетта очтым. Җемелдәп торган утларга күмелгән шәһәрне күреп шаккаттым. Имтиханнар тапшырганнан соң безне тулай торак төзелешенә калдырдылар. Күзен инде шунда яши дә башладык». Домра сыйныфы буенча укытучы һәм халык уен кораллары оркестры дирижёры белгечлеген яратып үзләштерә булачак сәнгатькәр. Бер эшне генә алып барырга күнекмәгән бит инде ул. Белемнәрен шунда ук гамәлгә күчереп бара – Метрострой сараенда балалар оркестры белән җитәкчелек итә. Дирижер белгечлеген үзләштерү җиңелләрдән бирелми, әмма осталыгын арттыру өчен бик күп дирижерларны тыңлый, дөньякүләм танылган артистлар Мстислав Ростропович, Галина Вишневская концертларын берничә тапкыр тамаша кыла студент кыз.

Роза ханымның остазы Леонид Аншелес шушы елларда Казан шәһәре консерваториясенә домра сыйныфын укытырга чакырыла. Магнитогорск шәһәрендәге өч бүлмәле фатирын Казанның Нефтяниклар бистәсендәге баракка алыштырырга туры килә аңа. Роза ханым Леонид Аркадьевичның яраткан укучысы да бит әле! Остазы аның язмышын хәл итүдә зур тырышлык куя. Күченеп килүгә, Розага да Казанда урын әзерли тора Леонид Аншелес. Казанның музыка училищесы директоры белән сөйләшеп, бик талантлы белгеч үсеп килгәнен, аны, һичшиксез, Казанга кайтарырга кирәклеген әледән-әле дәлилләп тора.

Роза Фатыйх кызыннан бер курс соңрак укыган, киләчәктә Россия һәм Татарстанның халык артисты булачак, әмма ул елларда әле танылып та өлгермәгән егет Шамил Монасыйпов та ярдәм кулы суза. Беренчедән, кызны Казанның матурлыгы белән кызыктыра, күңелендә шәһәргә карата мәхәббәт уята; икенчедән, училище директоры Ильяс Әүһәдиевкә Роза хакында бары тик яхшы бәяләмә генә биреп тора. «Казанда көтәләр сине, Роза!» – ди аңа Шамил. Розаның директор белән беренче очрашуы көтелмәгән борылыш алачак... Ләкин бу хакта соңрак...

...Роза Фатыйх кызы белән әңгәмә корып утырган бүлмәдә оркестр башкаруында Салих Сәйдәшевнең «Наемщик» музыкаль драмасыннан вальс яңгырый. Дирижеры – Роза Халитова. «Әлеге вальс домрага иң беренче күчерелмәм булгандыр», – дип искә алды Роза ханым. 1965 елда, Казанга килгәч, радиодан ишетә ул аны. Ике елдан кулына диплом алып, Казанга килергә дигән анык карар белән кайтып китә. Әзерлекне көнендә үк башлый: «Мәскәүдә татар композиторларының ноталарын эзли башладым, миңа репертуар әзерли торырга кирәк иде. Диплом эшем дә «Татар композиторлары әсәрләренең домра һәм фортепиано өчен күчерелмәләр җыентыгы» темасына багышланган иде». Роза ханым ул елларда даими рәвештә композиторлар белән очраша, Ленин исемендәге китапханәдә нота җыентыкларында туктаусыз эзләнә, атнага ике тапкыр Зур театрга йөри...

– Роза Фатыйховна, сез бит башка милләттән кергән уен коралы – домраны татар моңына өйрәткән кеше! – дим, соклануымны яшерә алмыйча.

– Әйе, шулай дияргә дә була, – дип елмая ул. Каршысында – халык уен кораллары оркестры өчен төзелгән 200 дән артык партитура, домра һәм фортепиано өчен күчерелмәдә ике ноталар җыентыгы. Роза ханымның дистә еллар буе туплаган тәҗрибәсе, хезмәте!

1967 елда укуын тәмамлап, Роза Казанга килә. Яңа шәһәрдә аны медицина институтының икенче курсында белем алучы ире каршылый. Тиздән аларның беренче балалары туачак... Берничә ел дәвамында түземсезлек белән көткән яшь белгечне авырлы килеш күреп, музыка училищесы директоры исә аны эшкә алудан баш тарта, кире Мәскәүгә китәргә куша. Шул чакта аңа «Кузгалмаска!» дигән боерык килә Мәскәүдән. Бер телефон шалтыратуы барын да хәл итә, икенче көнне үк

аны эшкә алалар. Бер ел да үтми, Роза Фатыйх кызы Казан музыка училищесының халык уен кораллары бүлеген җитәкли, җиң сызганып педагогик хезмәт белән шөгыльләнә башлый. Белем йортының музыкаль оркестры белән җитәкчелек итүе дә татар сәнгать сөючеләре өчен мәгълүм. Бу эшен ул һәр җирдә башкарып килгән иде бит: туган ягы Уралда, Мәскәүдә укыганда, хәзер инде Казанда. «Кая барсам да, гел оркестр оештырырга туры килде миңа», – дип елмая мөгаллимә.

...Алып баручы Казан музыка училищесы халык уен кораллары оркестры өчен күчерелмәдә Ринат Еникиевнең «Поэма» вальсын игълан итә. Скрипкада солоны Шамил Монасыйпов башкара. Дирижер – Роза Халитова.

– Әнинең язмышын миңа да кабатларга туры килде. Укуын тәмамлагач та, ирем ике бала белән берүземне калдырып, ташлап китте... Әле дә ярый иҗатым бар иде. Музыка белән яшәү михнәтемне җиңеләйтте. Озак еллар дәвамында Татарстанның әйдәп баручы солистлары белән эшләдем. Оркестр концертлары афишаларын иң яхшы башкаручы вокалистлар исемлеге бизи иде: РСФСРның һәм Татарстанның атказанган артисты Рәхилә Мифтахова, Татарстанның атказанган артистлары Рәйсә Нуриева һәм Зиннур Нурмөхәммәтов, Россиянең һәм Татарстанның халык артисты Илһам Шакиров һәм башкалар... Салих Сәйдәшев, Нәҗип Җиһанов, Ринат Еникиев, Фасил Әхмәтов, Мирсәет Яруллин әсәрләрен бик яхшы кабул итә иде тамашачым.

Гаҗәп, әмма кайчак хәсрәтнең хикмәте бәхеткә тоташкан була икән бит. Тәкъдире аңа пар итеп үзе кебек үк музыкантны каршына чыгарып бастыра. «Мине өч виолончелист егет ошатып йөрде. Беренче икесенә күңелем тартмады, гел качу ягын карый идем, – дип көлә хәзер Роза ханым, – өченчесенә насыйп булдым менә». Мәшһүр музыкант, скрипка һәм виолончельләр ясау һәм төзәтү остасы Иттаки Халитов белән тормыш корып җибәргәч, иҗади гаилә җыр-моңга сусаган күңелләренә илһам тапкандай була. Алардан кунаклар өзелми дә диярлек – музыкантлар, шагыйрьләр, рәссамнар! «Һәр очрашу үзе бер концерт программасына әйләнә иде. Классик әсәрләрне уйнап, аралашып, җырлап ял итә идек без. Дусларымның барысы да диярлек гүр ияләре инде хәзер... Берүзем калдым...» Роза ханымның күңелендә хатирәләр нур булып, яшьлегенең шаһитлары булган чордашларының рухларына ирешкәндәй була.

Укучылары... Монысы инде үзе аерым бер тарих! 60 яше уңаеннан оештырылган юбилей концертында Роза Фатыйх кызының иң талантлы, яраткан укучылары – мәшһүр композиторлар һәм музыкантлар чыгыш ясый. Илдәге вазгыять, пандемия белән бәйле чикләүләр аркасында мөгаллимәнең 80 яшьлек юбилеен үткәрергә мөмкинлек булмый. Шулай да 60 яшьлек юбилей кичәсенең дискка яздырылып, аудиоформатка күчерелеп калуы – Роза ханым өчен бик зур бүләк. Баксаң, Татарстан композиторлар берлегенең яртысы диярлек Роза Фатыйховна укучылары икән бит! «Термоядерлы энергияле, фанатизм белән музыкага бирелгән, ихлас кеше», – дип атый алар остазларын.

Роза Фатыйховна исә чыгыш ясаучы һәрбер укучысы турында үз хатирәләрен яңарта... Иң аянычлысы – аның горурлыгы булган танылган укучыларының күбесе инде бакыйлыкка күчкән... Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, композитор Риф Ильясов, танылган композиторлар, Г. Тукай премиясе лауреатлары Шамил Тимербулатов, Шамил Шәрифуллиннар...

Диск аша яңгыраган концерт ахырына якынлаша. Ләкин Роза Фатыйховна бәйрәм тортын көткән кебек, игътибар белән алдагы чыгышны көтә. Сәхнәгә Татарстанның халык артисты, барлык уен коралларында нотага карамыйча уйный алучы виртуоз музыкант, халыкара бәйгеләрнең күп тапкыр Гран-при иясе Рәфыйк Таҗетдин чакырыла! Яраткан укучысы белән икесе уйнаган әсәрне тыңлаганда Роза ханым тыелып тора алмый, күзеннән яшьләре тама. Ике маэстро – домра һәм балалайка залны сихри авазларга күмә... Иң аянычлы югалтуы ул аның. Бик зур өметләр баглаган, үз эшен курыкмыйча тапшырып калдырырга теләгән укучысы... Ләкин язмыш башка төрле хәл итә. Музыкант 56 яшендә вафат була...

Роза Халитова 80 яшенә кадәр хезмәттә кайный – Казан мәктәпләрендә, 1 нче, 12 нче номерлы гимназияләрдә балаларны домрада уйнау серләренә төшендерә. Шушы олпат елларына якынлашканда гына лаеклы ялга чыга. Хәзер аның тормыш юлын яңадан барлап, искә алып, хатирәләргә бирелеп йөргән матур чоры. Шундый көннәргә дә вакыт калсын икән ул! Кичләрен якын дусты, композитор Ринат Еникиевның сөекле тормыш иптәше, музыка белгече Нәркиз Мөштәри яздырып калдырган аудиоязмаларны тыңларга ярата. Бу язмаларда Нәркиз ханымның сәнгать эшлеклеләре, мәшһүр музыкантлар турында эшләгән радиотапшырулары тупланган. Роза ханым ире Иттаки Халитов турында китап чыгарырга планлаштыра, кулъязмасы күптән әзер инде. Тагын бер юанычы – бакча. 60 ел гомеренең һәр көнен иҗатка багышлаган бу гаҗәеп шәхес кай арада бакчасында кедр һәм әстерхан чикләвеге үстерергә өлгерде икән? Агачлары чәчәк атып кына утырмый, чып-чын җимеш тә бирә... Нәкъ иҗатындагыча.

Таш өстендә гөлләр үстерергә сәләтле Роза Халитова куйган хезмәтне беркемнеке белән дә чагыштырып булмый хәзер. Аның башлангычын дәвам итәргә, алга таба да үстерергә, бөртекләп җыйган тәҗрибәне югалтмаска гына кирәк. Домра өчен татар һәм рус көйләрен, танылган классикларның әсәрләрен күчергән, татар композиторлары исемен танытуда зур хезмәт куйган мөгаллимә кебек дәвамчылар кирәк татар сәнгате дөньясына.

Фотолар: Роза Халитованың шәхси архивыннан.

Кадерле «Сөембикә» редакциясе!

*Зөя сулары бик тирән,*
*Карап күзләрем тала.*
*Хатка язып сүзем бетми,*
*Бик күп сүзләрем кала!*

Сагынычлы хат башы – сез дә языгыз каршы, дип башланып китә иде элек сәлам хатларыбыз, хәтерлисезме? Хат язып, җавапны тәкате калмый көтүче кеше генә хат укуның чын тәмен беләдер.

«Азат хатын» журналы «Сөембикә» исемен алган чорда, 90 нчы еллар башында, күпсанлы гаиләбез белән ерак Төркмәнстаннан күчеп килдек без: әти-әни, ирем, үзем һәм өч бөртек берсеннән-берсе кечкенә улλарыбыз. Телләре русча ачылган балаларыма татар телен өйрәтүче син булдың, «Сөембикә»! Башка матбугатны китапханәдә укысам да, сиңа бер дә хыянәт итмим, әле дә алдырам! Журналны кулга тотып, һәр битен карап, сыйфатлы кәгазьгә төшерелгән язмаларны укып, күңелгә җан азыгы алам. Якын туганым кунакка килгән кебек була, «Сөембикә»!

Журнал белән бик күп матур мизгелләр бәйле мине. 90 нчы елларда сез уздырган бәйгегә әледән-әле күңелем белән кайтып килəм. Роза ханым Туфитуллова бәйгедә катнашу өчен 2500 хат килде, дигән иде. Җиңүчеләрне түгәрәк өстәл артына – бәйрәм табынына җыеп бүләкләделәр. Гөлчәчәк Галиева, Гөлнур Айзатуллова кебек танылган шәхесләр белән бер өстәл артында мин дә бар! Кызыксынуымны җиңә алмыйча сорау бирергә җөрьәт иттем. Миндәй гапгади авыл хатыны язган хат җиңүчеләр исемлегенә ничек кергән икән?

Роза ханым хатымны кулына алды да болай дип җавап бирде: «Кайнанаңа багышланган бу хатыңны үзең тыңлап кара әле, дустым. Син бит аны үз әниеңнән дә ныграк яраткансың кебек. Туган җиреңнән аерылганнан соң, иң якын, иң газиз кешең кайнанаң булган. Бу хатның һәр нотасында ихласлылык, дөреслек чагыла. Кайнанаңны «Алтын йозак» дип атап, олылап, хөрмәтләп язуың да сокландырды». Роза ханымның бу акыллы сүзләренә бик күңелем булып, канатланып кайттым. Очрашуда миңа бүләк ителгән нәфис фарфор чәй сервизы – безнең гаиләнең ядкаре. Олы кунаклар килгәндә генә тәмләп чәй эчәбез, кадерләп тотабыз аны.

«Сөембикә» журналы һәрвакыт ана телебезнең үрнәге булды. Чын йөрәктән язылган язмалар гына укучы йөрәгенә барып җитә. Сезнең гыйбрәтле язмаларны укыганда күздән яшьләр килә. Чын интеллигенция үрнәге сез, хөрмәтле ханымнар!

«Сөембикә»ле матур еллар кичеп, улларыбызны олы тормышка озаттык. Өчесе дә гаилә корып, балалар үстерәләр. Оныкларга исем сайлаганда да безнең белән киңәшеп, олы хөрмәт күрсәттеләр.

Әниебез исә 8 март көнне 98 яшен тутырды. Элеккечә безнең кадер-хөрмәткә тиенеп яши. Зиһене ачык, саусәламәт гомер кичерә, һәммәбезгә хәер-догада кала!

*Зәйнәп ЯРУЛЛИНА.*
*Апас районы.*

*Быел 80 яшемне тутырганда үзем кебек Татарстанда туып-үсеп, Көньяк Уралда яшәүче милләттәшләремне барлыйм. Шуларның берсе – Венера Хаматдин кызы Нуретдинова турында яраткан журналымның укучыларына да җиткерәсем килә.*

Ул – сугыш чоры баласы. 1939 елның 7 маенда Татарстанның Азнакай районы Түбән Сукаеш авылында туа. Урта мәктәпне тәмамлагач, Алабугада китапханәчеләр әзерләүче техникумда укый. Дипломлы яшь белгечне Нурлат районы Түбән Норлат авылына китапханә мөдире итеп билгелиләр. Берьюлы китапханәдә дә эшли, мәктәптә дә укыта. 1963 елны Казан дәүләт университетына укырга кереп, аны да уңышлы гына тәмамлап чыга.

Нурлат районында эшләгәндә Иглай авылы егете Нуретдин Зыятдинов белән башланган дуслыклары, еллар узып, олы мәхәббәткә әверелә. Кызның диплом алганын зур түземсезлек белән көтеп, аны Чиләбе өлкәсенә – үзе яшәгән һәм эшләгән Коншак районы Кобагыш авылына алып китә. Тәтеш авыл хуҗалыгы техникумында укыганда Зыятдин белән фикердәшләр, дуслар булдык. Мин Коншак районында агроном булып эшли башлагач, ул да әнисе белән монда күченеп, Тахталым совхозына эшкә урнашты.

Фото: Анна Арахамия




Читтән торып Казан авыл хуҗалыгы институтын тәмамлады. Югары белемле Зыятдин Минабутдин улын әле партия, әле авыл хуҗалыгы буенча бер совхоздан икенчесенә күчереп йөрттеләр. Ире белән бергә Венера да Халит, Үрәкүл, Үзбәгәрәк, Коншак авылларында яшәп, шушы авыл мәктәпләрендә балалар укытты. Педагогик стажы 40 ел аның! Әнисе дә мөгаллимә булган аның, тик явыз чир аркасында 40 яшендә үк мәңгелеккә күчкән. Фин сугышына алынган әтисе шуннан гына Бөек Ватан сугышына китеп югалган, кызы аны хәтерләми дә.

Венера укытудан тыш, җәмәгать эшләрендә дә актив катнаша. 1983 елда район китапханәсе каршында эшләүче «Туган тел» иҗади түгәрәгенә, «Акмулла» әдәби берләшмәсенә йөри – күңеле бик тә иҗатка тартыла аның. 2006 елдан Коншак районы әдәби берләшмәсен җитәкли. Үзе дә ике шигырь җыентыгы бастырып чыгара. Районда айга бер чыга торган «Чишмә» газетасының шеф-редакторы булып эшли, башлангыч сыйныфларда татар теле укыта.

2019 елны Венера ханымның юбилеен Коншак китапханәсендә зурлап уздырдык. Өлкәнең татар конгрессы рәисе Лена Колесникова, шагыйрь Ирек Сабировлар да аны котлап, эшенә югары бәя бирделәр. Әдәби эшчәнлеге өчен Венера ханым Кадыйр Даян исемендәге премия белән бүләкләнде.

Үтә дә тырыш, эшчән гаилә булды минем дусларым. Җәмәгать эше, үз эшләре белән бергә, хуҗалыкларында мал-туар да асрадылар, бакчасын да утырттылар, менә дигән өч бала тәрбияләп үстерделәр. Хәзер менә дүрт оныклары үсеп җитте, инде бер туруннары да бар.

Тормыш гел сикәлтәсез генә бармый. 18 яшьлек уллары Маратны җир куенына салу йөрәкләрендә гомерлек яра булса да, барыбер алга таба яшәргә кирәк. Алар бүген дә үз төбәкләрен яратып, тормыштан тәм табып көн итәләр. Венераның «Ак төс» шигырендә шундый юллар бар: «Нинди бәхет – изге эштән торса / Яшәү белән үлем арасы», – дип яза ул. Гомерен балаларга белем бирүгә багышлаган мөгаллимнең эшен изге дими, тагын ничек бәялисең?!

*Нурислам АЙБУЛАТОВ.*
*Чиләбе өлкәсе, Чибәркүл шәһәре.*

### *Әтием Камалов Солтанның яшь вакытта булган бер кызыклы хәлен искә алырга яратабыз.*

Кыр-Аксу авылында укытучы булып эшләгән вакытта, балалар әтидән: «Абый, җеннәр буламы?» – дип сорыйлар икән. «Юк, юк, балалар, җеннәр юк!» – дип җавап биргән әти. Малайлар әтине кызык итәргә уйлаганнар. Кич җитүгә парта астына кереп ятканнар. Яшь укытучы кичен сызгыра-сызгыра мәктәпкә килеп ут кабыза да эшкә утыра. Шул вакыт малайлар партаны шакылдата башлый. Әти тора да, тиз генә мәктәптән чыгып тая. Икенче көнне малайлар кабат сорыйлар икән әтидән: «Абый, җеннәр буламы?» «Белмим шул, балалар...» – дип җавап биргән әти бу юлы.

Кызганыч, әтине шулай сагынып искә алып кына яшәргә туры килде миңа. Әтием Камалов Солтан Буа районы Кыр-Аксу авылында 1913 елда туа. Бик акыллы, чибәр, тиктормас малай булган ул. 16 яшендә үк «Атаклы Солтан» дип йөрткәннәр аны. Туган авылында да, күрше авылда да укытучы булып эшләгән әти. Соңыннан аны район үзәгенә комсомол секретаре итеп билгеләгәннәр.

Мин тугач, әтине Горький шәһәренә танкистлар училищесына укырга җибәргәннәр. Әтинең әнигә шул елларны язган хатлары әле дә саклана. Алар барысы да шигырь белән язылган. Исән-сау булса, танылган шагыйрь булыр иде ул дип уйлыйм.

Фин сугышы башлану белән, әтине шунда җибәрәләр. Танк янып, ике тәүлек кар астында ятканнан соң гына табып алалар аны. Ул вакытта исән кала ул. Ләкин озакка түгел...

Украинаның Львов шәһәренә күчеп, комиссар булып эшли башларга туры килә әтигә. Миңа 4 яшь булганда ул безне дә үз янына күчерде. Кызганыч, рәхәт тормышыбыз озакка бармады шул. Аяз иртәләрнең берсендә күрше карчыгы: «Иптәш Камалов, сугы-ы-ыш!» – дип кычкырды. Әти йөгереп чыгып китте. Әни, мескенкәем: «Солта-а-ан, миңа нишләргә-ә-ә?» – дип, артыннан елап калды.

Биш көн буе мәхшәр кичердек. Бомба өстенә бомба аттылар. Әнинең үткенлеге аркасында гына бертуктаусыз өстән явып торган бомбалар астында исән-сау калып, туган ягыбызга кайтып егылдык. Ул көннәрнең кайсын искә төшерсәм дә, бер китап язарлык инде... 19 яшемә кадәр самолет тавышыннан котым алынып яшәдем.

Әтием шул чыгып китүеннән кайтмады. Истәлеккә фотосурәте генә калды. Гел каршымда тотам ул фотоны, көн саен сөйләшәм әти белән. Бик бала җанлы кеше булган ул, мине гел кулында күтәреп йөрткән. Кече кызының тууын да түземсезлек белән көткән булган, тик аларга күрешергә насыйп булмады. Үз гомерендә бер тапкыр да әтисен күрмичә үскән сеңлем Венера Кәлимуллина Казанның мех комбинатында чыгып килүче күптиражлы газетаның баш мөхәррире булып эшләде.

Бик кызганыч, әтинең хәтта кайда, ничек һәлак булганын да төгәл белмибез. Сугышның иң афәтле, иң куркыныч беренче көннәрендә үк вафат булган солдат балалары без. Ләкин машина да, фатир да алганыбыз булмады, акчалата ярдәм дә күрмәдек. Әтиләребез медаль-орденнар алырга да өлгермичә, ватанны саклап, дошманга беренче каршылык күрсәтеп, батырларча китеп бардылар.

*Флёра САТТАРОВА.*
*Казан шәһәре.*

***Хөрмәтле укучыларыбыз!***
***Сездән хатлар көтеп калабыз.***
***Безнең адрес: Казан,***
***Декабристлар урамы, 2.***
***e-mail: ssuum@yandex.ru***



# «БҮТӘН ӘНИЕМ ЮК...»

– Әнием Картлар йортында минем...
Ул шушы җөмләне әйткән мизгелдә тыныч кына барган әңгәмәбез кинәт икегә бүленде. Бер мәлгә мин хәтта югалып та калдым бугай. Дөресрәге, ялгыш ишеттем дип уйладым. Без бер минут элек кенә аның тормышта ирешкән уңышлары, яулаган дәрәҗәләре турында сөйләшә идек бит. Исеме республикада шактый билгеле аның. Республикада гына да түгел... Ул тагын кабатлады:
– Әйе, әнием Картлар йортында...
Бик азга гына күзләребез очрашты: алардагы әрнүнең зурлыгын, тирәнлеген күреп тетрәнеп киттем. Әңгәмәдәшем сүзен дәвам итте.

– Кечкенә чакта әнидән җылы күрмәдек без...

Гөлназның әтисе белән әнисе күрше авылларда гына үсәләр. Очрашып танышалар, кавышалар. Өйләнешкәч: «Дөнья күрергә, акча эшләргә», – дип, туганнары янына шахтага эшкә чыгып китәләр. Гөлназның да, сеңлесенең дә туу турындагы таныклыкларына Воркута шәһәре дип язылган. Кызларның берсенә – 3,5, икенчесенә 1,5 яшь булганда, әниләре аларны әтиләре кулына калдырып, кире туган якка кайтып китә. Нигә аерылышканнар, арада ни булган – сәбәбен, әлбәттә, балалар белми. Ул көннәрне Гөлназ томан кебек кенә хәтерли: әтисе эштә чакта өйдә сеңлесе белән икәү генә торганнарын, баракта яшәгәннәрен, сөлге белән үзенең идән юуын, әтисенең аларга кичен өч литрлы бидон белән аш алып кайтуын... Өчәү ашханәгә барып ашаган сөтле ашның тәме хәтердә тагын... Ир-атка берүзенә ике кечкенә сабыйны тәрбияләү авыр булгандыр инде: әтиләре балалары белән кире туган авылына әйләнеп кайта. Кызлар рәхәткә чыга – әбиләре белән яши башлый. Аннан әтиләре кабат өйләнә.

Гөлназ укырга керәсе елны әниләре аларны алырга килә.

– «Сагындым сезне, ниһаять, янымда буласыз!» – дип, әнинең сөенгәне исемдә түгел. Ул безне хәтта кочакламады да... Әйтерсең лә үз газизләрен түгел, күрше кызларын алып китә... Соңыннан гына белдек – үзе теләп килмәгән ул. Әнисе, туганнары: «Балаларны ташлап калдыру буламы?! Ил-көндә күрмәгән хәл... Кешеләрдән оят – барып алган бул!» – дип, көн-төн тукып теңкәсенә тиюләреннән туеп кына килгән... Бөтен урам озатырга җыелды, өйдәгеләр, бигрәк тә әби елый. Ә безнең китәсебез килми. Кая барганыбызны да, нигә барырга тиешлегебезне дә аңламыйбыз...

Шулай итеп алар шәһәрдә яши башлый.

Беренче мәлләрдә иң үзәккә үткәне, әлбәттә, сагыну була. Гөлназ үзе дә, сеңлесе дә гел күз яшьләре аша көлеп искә төшерә торган бер очрак бар. Бик теләсәләр дә, шәһәрдән качып кайтырга тәвәккәлли алмый ике кыз туган. Беренчедән, юлны белмиләр, икенчедән, билетка акча кирәк булачагын чамалыйлар. Ә авыл... авыл бит башка! Әниләре каникулга авылга кайтарып куйганның беренче көнендә үк әтиләре янына бару турында хыяллана башлыйлар. Аның авылы каядыр шушында гына булырга тиеш бит – өйдәге сөйләшүләрдән шуны чамалыйлар... Беркөнне әниләренең абыйсы эшкә чыгып китеп барганда, Гөлназ тәвәккәлли: «Ә безнең әтинең авылы кайсы якта?» – дип сорый. Ашыккан ир, аны-моны уйламыйча гына, кулын селти: «Шунда...» Башта ындыр артына чыгып басып карап торалар. «Ничек кенә барырга икән?» – дип уйлашалар. Аннан, урамдагы балалардан аерылалар да, җитәкләшеп шул якка карап китәләр... Бик озак баралар, урманга ук җитәләр. Ярый әле артларыннан эзләп чыгалар, ярый әле тирә-күршедәге бала-чага күреп калган була. «Сез соң кая бармакчы идегез?» – ди әбиләре аптырап. «Әти янына», – диләр икесе беравыздан. «Балакайларым, әтиегез ул якта яшәми бит...» Ике кызның көне-төне: «Әтине сагындык!» – дип елауларыннан тәмам арып, беркөнне сөт ташучы машинасына утыртып, ниһаять, аларны әтиләре янына җибәрәләр. Тагын качарлар дип куркалар бугай. Әмма башта: «Әнигә бу хакта әйтмибез!» – дип сүз бирдертәләр әле... Авыл башына җиткәч, шофер кызлардан: «Әтиегезнең кайда торганын беләсезме?» – дип сорый. Аннан: «Йортын эзләп йөрергә вакытым юк, үзегез табарсыз», – дип төшереп калдыра.

## Гаиләдә бөтен бала да начар була алмый бит инде, ә без әни өчен өчебез дә начар идек.

– Таптык бит өйләрен! Барып кердек. Әти өйдә иде. Шаккаттылар инде... Анда шундый рәхәт булды. Илсөяр апаны да яраттык. Ул да безне... Алгарак китеп булса да әйтим, Илсөяр апа кызын да, улын да: «Шәһәрдә сезнең ике апагыз бар. Безнең белән берәр нәрсә булса, аларны эзләп табыгыз, аралашыгыз», – дип үстергән. Олы кызлары: «Шәһәргә укырга килгәч, трамвай-троллейбусларда гел сезне эзләдем», – дип сөйләде. Ул безне үзе эзләп тапты! Әнигә белгертмичә генә очраштык. Хәзер дә аралашабыз, кунакка йөрешәбез. Илсөяр апага «әни» дип бик әйтәсем килә. Әйткәлим дә, әмма балаларыннан яхшы түгел... Әти белән алар ул чакта безне киендерделәр. Күлмәк-майкалар, аяк киемнәре алдылар. Әмма борчылулары йөзләренә чыккан, сөйләшкәннәре колакка керә: «Ахыры хәерле булып бетмәс моның», – диләр... «Әниегездән сорамыйча килергә ярамый», – дип, кире әбиләргә илтеп куйдылар. Без бу серне әнидән озак яшердек, аннан түзмәдек, әйттек. Әләкте инде... Әтинең кучтәнәчләр җибәрүен белә идек, әмма әни аларны бервакытта да безгә бирмәде. Әбинең безгә дип бәйләгән оекбашларын да... Аякларыбыз туңып йөрсә дә...

Ана белән бала, әни белән кыз арасы бөтенләй башкача булырга тиешлеген Гөлназ үсә төшкәч, үзенең классташлары, дус кызларына карап кына аңлый башлый. Ә ул чакта... Ул чакта барысы да шулай булырга тиеш кебек тоела.

Әниләре ел саен җәйгә ялга китеп бара: йә берәр санаторийга, йә Кырымга, диңгезгә. «Мин авырыйм, миңа ял кирәк», – ди ул. Өйдә өч кечкенә бала берүзләре яшәп кала. Әйе, алар инде бу вакыт өчәү булалар – әниләре тагын бер кыз таба. Айлар буе балалар ничек тора, нәрсә ашый, нишли – ананы бу кызыксындырмый.

– Газ юк, керосин плиткасы гына. Хәер, икенче-өченче класс баласы нәрсә пешерсен инде?! Пешерергә әйбере дә юк бит әле аның... Без бик аз ашый идек. Шешәләр җыеп тапшырабыз да, ипи

# Әле дә шаккатам: без ничек беребез дә юлдан язмаган, эчүгә сабышмаган, тәмәкегә үрелмәгән…

сатып алабыз. Бакчада алма күп була иде – ипи белән шул алманы ашыйбыз. Кайчак күршеләр ашата, әмма беркайчан да кешедән үзебез сорап нидер алмадык, ояла идек… Берсендә безне туган көнгә чакырдылар. Өстәл тулы ризык! Без күрмәгән ят ризыклар: винегрет, котлет… Шунда кунакка килгән кызларның: «Мин моны ашамыйм, яратмыйм», – дип әйткәннәрен ишетеп сеңлем белән шаккаттык. Без дә ризыкка үрелмәдек – ничек ашыйсың, бүләксез кергән идек бит… Әби – әнинең әнисе дә бу вакыт шәһәргә күчеп килгән иде инде, кайчак ашарга аңа барып кайтабыз. Еш барып булмый, ерак – юлга акчабыз юк, җәяү барабыз. Барган саен әби: «Нигә әниегез өстегезне юмый, салып бәрегез әле», – дия иде. Ул безнең күлмәкләрне юып киптергәндә, әбинең озын күлмәкләрен киеп торабыз, «Без – артистлар», – дип көлешәбез… Керләребезне әни беркайчан юмады. Үзенекен дә марлядан биш кат маска ясап киеп кенә юа иде, «Порошокның зыяны бик күп аның», – дия иде… Алмашка киемебез юк иде инде. Апрель ае, минем аякта резин итек. Ә урамда әле кар, боз… Итегем тишек, җитмәсә. Ташу акканда мәктәптән өйгә кайтып барам. Су кермәсен дип аяк очына гына басарга тырышам. Бер апа арттан карап кайта икән: «Нужаланма, бәбкәм, су барыбер керде бит инде», – ди… Җәй көне дә шул итектән йөри идем мин. Тагын бер очрак бик истә. Шуны гына сөйлим дә. Анысы инде яшүсмер чагым. Әбигә ашарга йөргәнне әйткән идем бит. Берсендә бардым шулай. Мин килгәч, күрше апа керде. «И-и, балам, әниең күрмимени, күкрәкләрең үскән бит, нигә лифчик алмый?» – диде. Кызардым, агардым…

Әниләренең ашавы да балалардан аерым була. Аның алдында – йөзем, курага, каймак, эремчек… «Боларга кагылмагыз, мин авырыйм, миңа шулай ашарга кирәк», – ди. Кагылмыйлар, сорамыйлар – шулай тиеш дип беләләр. Шәһәр читендәге совхозга бәрәңге, кыяр урларга җибәрә – баралар. Аннан шуларны сатарга куша – берсүзсез урам читендәге әбиләр янына чыгып басалар. Класссташлар гына күрмәсен… Әниләренә ялга барырга акча шулай җыела. Әтиләреннән килгән алимент акчасына да шул сәбәпле кагылмыйлар.

Мәктәпкә киткәнче утын кисеп өйгә кертеп калдыру, колонкадан су ташу – барысы да кызлар өстендә була. Боларның гына бер авырлыгы да юк. Ә менә иртәнге сәгать дүрттә торып, әниләре өчен эшкә бару… Кайсы көнне үзе йоклап кала, ә кызларны идән юарга җибәрә. Студентлар килгәнче ике катлы училище бинасын юып чыгарырга кирәк. Берсендә озаграк җыештыралар – студентлар лекциягә килә башлый, алар артыннан ишектә директор да күренә. «Бу ни хәл?» – ди ул аптырап. Кызлар, өйрәтеп куйганча: «Әни авырый, шуңа без килдек», – диләр. Директор: «Барыбер ярамый. Сез бит әле сабый балалар гына», – ди. Мәктәпкә киткәнче кыр кадәр училищены җыештырулар шуның белән тәгәлләнә.

Озын тәнәфестә бөтен кеше мәктәп ашханәсенә йөгергәндә, алар икесе дә классларында утырып кала торган була. Ашыйсылары килә, билгеле, тик төшке ашка дип 5 тиен сорасалар, әниләре һәрвакыт: «Минем акчам юк», – дип җавап бирә… Гөлназ бер очракны гел онытмый. Берсендә алар класслары белән паркка барырга җыеналар. Укытучылары һәркемгә 33 әр тиен акча алып килергә куша. Дусларыннан аерылып калырга теләмәгән Гөлназ әнисеннән ул акчаны ялынып-ялынып сорый. Ниһаять, әнисе бирә акчаны! Йөгерә генә кыз! «Инде кайтып китәләрдер, таралалардыр», – дип бик ашыга. Ә барып җиткәч, йөгергәндә кесәсеннән ул тиеннәрнең төшеп калган булуы ачыклана…

Мәктәптә чыгарылыш кичәсе якынлаша. Бөтен кызлар яңа күлмәк тектерә, кибетләрдән туфли эзли. Гөлназга әнисе үзенең иске күлмәген бирә – кыз аны үзе кыскартып кия.

– Әйе, классташларымнан күреп, әни белән безнең мөнәсәбәтләр дөрес түгеллеген аңлый идем. «Әни, нигә соң син шулай безне яратмыйсың? Без бит синең кызларың… Картаерсың, без дә сиңа кирәк булырбыз», – дип әйттем хәтта берсендә. «Берегез дә кирәкмисез… Хөкүмәт карар әле, Картлар йортына барырмын», – дип җавап бирде. Ул гомер буе шул сүзне кабатлады: «Картлар йортына китәм…» «Без – синең кызларың», – дигәнне ишетергә дә теләмәде. «Сез – дошман орлыгы!» – дия иде. Әтинекеләр, янәсе…

Әнинең безнең беребезне дә кочаклаганын хәтерләмим. Булмаганны… Мин үзем дә моңа күптән түгел өйрәндем әле. Күреп үсмәгәч соң… Аның холкы шундый – ул балалар яратмый. Нишләтәсең, безгә шундый әни насыйп булган… Ярый әле әтиемә охшаганмын дип сөенәм. Кешеләрне яратам! Сеңлемнең холкы авыррак менә – ул әнигә тарткан. Кечкенә сеңлем исә инде күптән: «Минем әнием юк. Ул минем өчен үлде…» – диде. Алар аралашмыйлар… «Укырга кирәргә, белем алырга кирәк», – дигән сүзләрне без ишетмәдек. «Кайчан янымнан китәрсез, кайчан сездән котылырмын?!» – дип кенә кабатлады әни…

Өйдән алар бик иртә китәләр – уналты яшьтә үк. Акыл да кермәгән килеш кияүгә чыгалар. Гөлназның тормышы барып чыкмый. Аерылыша һәм… бала белән урамда кала. И-и, ул көннәр! Өч бүлмәле фатирларының бусагасыннан да уздырмый әнисе. Пропискасы шунда булса да. «Кызыңны атасында калдырып кайтсаң гына кертәм. Аннан: «Озакламый яңадан кияүгә чыгып китәм, дип сүз бирсәң генә», – ди. Баласыннан ничек баш тарта алсын инде Гөлназ?!

– Баламны күтәреп, классташ кызларның берсеннән икенчесенә йөрдем... Алар кич укудан кайткач киләм, ашыйм, йоклыйм. Иртән алар институтларга укырга барырга кузгалганда, мин дә бала белән чыгып китәм. Шәһәр буйлап йөрим. Чүпрәк сумкам бар иде – анда баланың колготкалары. Эскәмияләрдә утырам... Үземнең ашыйсы килгәнне хәтерләмим, ашау кайгысы түгел иде миндә. Ә бала елый, ашарга сорый... Эшкә урнаша алмыйм: кызым әле кечкенә, аны балалар бакчасына алмыйлар... «Башка болай яши алмыйм», – дип, тимер юлга барган чагым да булды. Поездга каршы атлаганым... Үземне түгел, баламны җәлләдем ул чакта. «Кызым гаепле түгел ләбаса», – дигән уй гына коткарды мине...

Берсендә кунарга җир тапмадым. Тагын әнигә килдем. Кертте! «Бер генә кичкә! Тавышыгыз чыкмаса гына!» – диде. Без кызым белән кечкенә бүлмәдә утырабыз, ә алар кухняда ашыйлар. Өчәү – яңа ире, үзе, кечкенә сеңлебез. «Тәмле булган!» – дип сөйләшәләр. Кашык тәлинкәгә бәрелгән тавышлар ишетелеп тора. Ә мин көне буе авызга бер бөртек ризык капмаган...

Урамнар буйлап балам белән йөргәндә гел Аллаһы Тәгаләгә ялвара идем. Һәм ул мине ишетте! Юлыма яхшы кешеләр чыгарды. Аякка басу өчен теләсә нинди эшкә тотындым.

«Баланың баласы балдан татлы», диләр. Тик, кызганыч, бу ярату да Гөлназның әнисен урап уза. Ул оныкларының барлыгын да белми, белергә теләми дә. Уртанчы кызының беренче баласын 11 яшькә җиткәч кенә күргән. Ә аларның бер-берсеннән аралары нибары өч тукталыш...

Сүз Картлар йортына җитте. Иң авыр урынга.

– «Әниегез кабат кияүгә чыктымы?» – дисез. Чыкмаган кая! Унга кадәр санадым да, аннары ташладым... Ул гел хатыны үлгән, балалары еракта булган ир-атларны сайларга тырышты. Кайтып комачаулап йөрмәсеннәр, дип... Һәм һәрвакыт шул ир хисабына яшәде. Үз акчасын гел җыеп барды. Өч бүлмәле фатирыбызны ирләренең берсе һәм кечкенә сеңлем белән бүлешкән иде. «Авылда яшисем килә», – дип, ул акчага йорт алды. Аннары аны да сатты. Беркайда да өч-дүрт айдан озак яши алмый әни. Нигә шулайдыр... Әти ягыннан туганнар: «Әбиегезнең рәнҗеше төшкәндер. Сезне алып киткәндә: «Гомер буе җаныңа тынычлык тапма», – дип калды. Бер дә бирәсе килмәгән иде сезне, гел сагынып яшәде», – диләр... Ирдән иргә йөри торгач, әнинең шәһәрдә бер бүлмә алырлык акчасы җыелган. Күршеләр белән торганчы, аерым фатир үзең өчен җайлырак булыр, дип, сеңлем, аның кызы ипотекага бер бүлмәле фатир алып бирделәр әнигә. Өр-яңа җиһазлар, суыткыч, телевизор... Тынычлап тор гына бит. Көннәрдән бер көнне миңа республикадагы Картлар йортының берсеннән шалтыраттылар. «Әниегез бездә», – диләр. Егылып китә яздым... «Торыр җирем юк, куып чыгардылар. Беркая да китмим сездән, үлсәм шушында үләм», – дип килеп кергән. «Фатирының ачкычы кесәсендә булырга тиеш», – дим. Сеңелләр белән дә элемтәгә керделәр. Алар бөтенләй үпкәләгән: «Үзе ничек барган, шулай кайтсын», – дигәннәр... Сүзне уйлап әйтергә кирәк диләр бит, ә безнең әни гомер буе: «Берегезгә дә ялынырга җыенмыйм, Картлар йортында яшәячәкмен», – дия иде... Нәкъ дүрт айдан шалтыратты: «Кире үз өемә илтеп куегыз, миңа монда начар», – ди. Инде күптән беләм: үзенә яхшы булганда беркайчан телефонын алмый ул. Җавап бирми! Ирем белән шунда ук юлга чыгып киттек. Өенә алып кайттык, бер атнага җитәрлек ризык алып калдырдык... «Фатирың матур, яңа, чиста, җылы, рәхәтләнеп яшә генә, әни. Айга бер тапкыр без дә килеп йөрербез», – дим. Өч айдан шалтыратты. Картлар йортында булганда алтмыш җиде яшьлек бер абзый белән танышкан икән. Ирләре бик еш шулай үзеннән яшьрәк була аның. Әни үзен караганнарын, көйләптәрбияләп торганнарын ярата... «Яшәргә аның янына авылга кайтам, озатыгыз», – ди. «Әни, сиңа бит инде сиксән, тынычланырга вакыт», – диеп булмый: ирем белән илтеп куйдык. Бик ошаттык – яңа ирен дә, ул торган авылны да. Кунакка кайтып йөрүләр генә насыйп булмады – ике айдан әни тагын Картлар йортында иде... Әйтәм бит, бер урында гына тора алмый ул. Үзебезгә дә алып килеп караган булды – ике айдан артыкка түзмәде... Телефонына акча салып торам. Шундый тиз бетә акчасы, аптырап: «Әни, син аны кая куясың соң?» – дип сорадым. Сеңелләр күрше республикада яши – көн дә аларга шалтырата икән. Миннән зарланырга... Башка әниләр балаларына: «Дус булыгыз, үзара тату яшәгез!» – дип киңәш бирә, ә безнеке нигәдер гел араларыбызны бозарга тырышты. Менә шулай беребезне икенчебезгә сөйләп... Үзем дә әни буларак, тагын бер нәрсәгә шаккатам – ул безнең шатлыкларга куана белми. Бәлки, ышанмассыз да, әмма яхшы хәбәреңне ишетсә, хәтта тынычсызлана башлый. Ә борчуың булса – кинәнә... Моны аңлаганнан бирле тормышымда нинди генә күңелсез хәл булса да, әнигә белгертмәскә тырышам. Тик сөйләгәннәремне, зинһар, зарлану дип кабул итмәсәгез иде. Күбрәк күңелемне бушату бу. Рәнҗемим мин аңа – холкы шундый булганга ул гаепле түгелдер. Кайчан гына ярдәм сораса да, мин аңа шундук булышырга тырышам. Бөтен эшемне ташлап. Әни бит ул... Ә минем бүтән әнием юк...

...Кайдан башыма кергәндер, белмим, әмма Картлар йорты директоры нәкъ бу минутларда башка бер журналистка интервью биргәндер кебек тоелды миңа. Үзләрендә тәрбияләнүчеләр хакында сөйләгәндер: «Менә тагын бер ана. Аның өч кызы бар, өчесе дә исән-сау...» – дигәндер. Каршында утырган журналист кызның күзенә мөлдерәп яшь тулгандыр. Минеке кебек...

Гөлнур САФИУЛЛИНА

**РЕДАКЦИЯДӘН:** язмадагы исемнәр барысы да үзгәртелде.

PRESSA



# ЮЛЫМДА – СИНЕҢ ЭЗЛӘРЕҢ...



Фото: җырчының шәхси архивыннан

Алсу ШАКИРОВА

Мәйдан гөрли... Сабантуйның абсолют батырын билгеләмичә өйгә кайту юк бүген! Татарстан беренчелеге, Муса Җәлил турниры җиңүчесе, бик күп Сабантуйлар батыры – Вил Усманов көрәшә бит мәйданда! Озак тартышты егетләр, икесе дә нык арыдылар, билләренә сөлге дә күптән бәйләнгән... Ләкин өстенлекне берсе дә ала алмый. Ах, эләкте бит! Вил көндәшенең алымын үз файдасына кулланып, аны аркасына әйләндереп салды. «Чиста! Чиста-а-а!» – дип, утырган урыннарыннан сикереп торды җан атучы тамашачылар. Хөкемдар уң кулын өскә күтәреп, уч төбен ачып күрсәтә. Чиста җиңү! Сабантуйның абсолют батыры – Вил Усманов!

Халык алкышлый, сызгыра. Бер белмәгән апалар, картлар килеп кулын кыса, котлыйлар, егетләр, күтәреп, күккә чөяләр. Батырны олылау, тәбрикләү гадәте шундый. Алай гына да җибәрмиләр әле. Вилне җырлатмыйча Сабантуй тәмамланмый. Һәрвакыт шулай. Хәлдән тайганчы көрәшкән батыр, сәхнәгә менеп, микрофонны кулына ала. «Әйдәгез, бергәләп!» – дип башлап та җибәрә. Әйтеп торасы бармы соң! Бөтен мәйдан кушылып җырлый:

*Юлымда синең эзләрең,*
*Суымда – синең шәүлә.*
*Гел сине эзли күзләрем,*
*Син ярен йолдыз мәллә?*

Кечкенәдән сәнгатькә гашыйк булып үсә Вил. Башкача мөмкин дә булмагандыр. Әтисе ягыннан кайсы абыйсын гына алсаң да, һәммәсе диярлек баянда, гармунда уйныйлар. Гармун серләренә Вилне кулыннан тотып өйрәтүче булмый авылда. Әтисе Нургали абыйның Сабантуйда кө-

## *Син яшерен йолдыз мәллә?*

*Көтмәдең, ялгыз калдырып,*
*Вәгъдәләр биреп киттең.*
*Яшәве йөрәк яндырып,*
*Шуңа да бигрәк читен.*

*Кушымта:*
*Юлымда синең эзләрең,*
*Суымда – синең шәүлә.*
*Гел сине эзли күзләрем,*
*Син яшерен йолдыз мәллә?*

*Гөлләрем чәчәк аттылар,*
*Синең гөл – кызыл яран.*
*Бер йолдыз булып атылам –*
*Яныңа үзем барам.*

*Көтмәдең, ялгыз калдырып,*
*Вәгъдәләр биреп киттең.*
*Яшәве йөрәк яндырып,*
*Шуңа да бигрәк читен.*

рәшеп алган гармунында үзе уйнарга өйрәнә. Менә шулай гомере буе гармун белән сөлге – сәнгать белән көрәшне тигез алып бара ул. Бу шөгыльләренең бер-берсенә ничек каршы килгәннәрен музыка училищесында гына аңлый. Ләкин көрәш ул гади спорт кына түгел. Юкка гына «көрәш чире» дип йөртмиләр инде аны ата-бабалар. Тимер күтәреп беләк, күкрәк мускулларын нygытканда тавыш көченә зыян килүен остазлары соңрак аңлата Вилгә.

Тик әлегә 1988 ел, Вилгә нибары 20 яшь. Баулының спорт комплексында татар-башкорт көрәше буенча – тренер, мәдәният йортында баянчы булып эшләп йөргән еллары. «Ватаным Татарстан» газетасында чыккан шигырьләрне аеруча яратып укый егет. Ошаганнарын көйгә салып, җырлар иҗат итә башлый. Малайларга көрәш серләрен өйрәтеп, мәдәният йортына эшкә килеп, кайвакыт төннәр буе гармунда уйнап, моңланып чыга.

Зәки Нуриның «Яныңа үзем барам» шигыре Вилгә аеруча ошый. Аның өчен гади шигырь генә түгел бу сүзләр. «Син яшерен йолдыз мәллә» дигән юлларын бераз үзгәртеп, йолдыз сүзен баш хәрефтән язып куйсаң, бу сүзләр егетнең гыйшкы төшкән Йолдыз исемле кызга атап язылган диярсең! Мәхәббәткә мәдхия итеп әнә шундый җыр иҗат итә дәртле йөрәк. Исемен дә шигырьдәгечә калдырмый – «Син яшерен йолдыз мәллә?» дип, үзләре – ике гашыйк аңларлык итеп куя. Мәдәният йортында сәбәп чыкмый калмый, ел дәвамында әллә ничә концерт оештырырга туры килә. Яшь җырчы, үзешчән композитор башкарган бу җырны тамашачы яратып кабул итә.

Вил Усмановның җыры әнә шулай үзешчән сәнгать үрнәге генә булып та калыр иде бәлки. 23 яшендә музыка училищесына укырга керү теләге белән егет Казанга китә. Музыка мәктәбе белеме булмаса да, бәхетен сынап карамакчы була. Иҗат итә, көйләр яза бит, бәлки... Имтихан вакытында Вилне тыңлап карыйлар: чынлап та, матур уйный, ошаталар. Ләкин, ни кызганыч, көйләре шәп килеп чыкса да, ноталарны укый белми Вил. Авылда эштән бушаган вакытта, төннәр буе уйнап өйрәнү генә җитми икән укырга керер өчен. Әле анысы өчен дә эләгә иде әтисеннән: «Утырма гармун тотып, чыгып эш эшлә!» – дип, ничә ачулангандыр улын... Ләкин Россиянең һәм Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, мөгаллимә Резеда Газиз кызы Сабитовская теләктәшлеге белән егетне музыка теориясе бүлегенә укырга алырга булалар.

Дәресләрнең күбесе фортепианода уйнауга корылган. Яшь кенә үсмер егет-кызлар дәресләрне су урынына эчә. Ә Вил уйный белми, тәҗрибәсе юк. Беренче дәрестә укытучы янына фортепиано артына барып утыра Вил. «Йә, нәрсә уйныйбыз?» – дип сорый укытучы. «Белмим», – дип җавап кайтара егет. «Ничек инде белмисең, кая, бармакларыңны күрсәт әле!» – дип гаҗәпләнә укытучы. Вил клавишалар өстенә сөлге тотып ныгыган юан бармаклы кулларын куюга, укытучы: «И Ходаем!» – дип, йөзен каплый...

Бер елда музыка мәктәбенең дүрт сыйныфлык белемен үзләштерергә туры килә Вилгә. Ләкин моның өстенә училище программасы да бар бит әле. Анысы көннән-көн кыенлаша. «Ел ярым интеккәннән соң, училищеда укудан азат итүләрен сорап, Сабитовская исеменә гариза яздым. Ләкин укытучы аңа кул куймады. Мине вокал бүлегенә күчереп, укуны тәмамларга мөмкинлек бирде», – дип, рәхмәт сүзләре белән искә ала композитор.

Тамашачы күңеленә хуш килгән җыр өчен шәһәрдә яңа офыклар ачыла. Ә Йолдыз белән Вилнең юллары икесе ике якка аерылып, аралар өзелә. Мәхәббәт хисләре яшьлекнең якты истәлеге булып кала... Җырны исә яшәтергә кирәк!

Казанга килгәч, Вил Вадим Усмановның тавыш яздыру студиясенә җырга аранжировка эшләтергә бара. Җаен китереп, Вадим Усманов бу җырны Зәйнәб Фәрхетдиновага күрсәтә. Җырчының танылып килгән еллары. «Син яшерен йолдыз мәллә?» җыры Зәйнәбнең күңеленә хуш килә. Әнә шулай Вилнең йөрәк җырын Зәйнәб Фәрхетдинова зур сәхнәгә алып чыга. Җыр шундук халык күңеленә үтеп керә. Соңрак Вил Усманов Россия буйлап гастрольләрдә үзе йөргәндә «Син яшерен йолдыз мәллә?» җырының никадәр халыкчан булуын күреп, үзе дә гаҗәпләнә. Кая гына башкарса да, бөтен зал кушылып җырлап утыра! Композитор өчен – иң зур куаныч. Халык кабул иткән, димәк. Бу җырыннан башка концертлары гына түгел, бер генә Сабан туе да узмый Вилнең. Көрәшчегә дип килсә, җырлаталар, җырларга дип килсә, көрәштерә торган булалар аны.

– «Син яшерен йолдыз мәллә?» җырын хәзер Линара һәм Марат Галимовлар башкара. Яшь башкаручылар җырга яңа аранжировка ясап, яңа сулыш өрделәр... Аны тыңлап, яшьләр мең рәхмәт әйтеп язалар хәзер: «Вил абый, шундый матур җыр иҗат иткәнсең», – диләр. Әйе, 33 ел элек инде, дим...

PRESSA



# «БЕЗДӘ «ТЕЛӘКЛӘР ГРАДУСНИГЫ» БАР»



**Ир-ат һәм хатын-кыз. Бер үк галәмгә без бит очраклы гына эләкмәгән... Шулай булгач, нигә соң бер-беребезне күп вакыт аңламыйбыз? Гамәлләребезне, теге яки бу адымыбызны, әйткән сүзләребезне... Үзара тартылуны «җиңеп», арага каршылыклар керә дә куя...**
**Ә ир-атлар үзләре бу хакта ни уйлый икән? Сүзне аларга бирик әле.**

Данил СӘФӘРОВ, журналист, «Матбугат.ру» сайты җитәкчесе; гаилә стажы – 11 ел; өч бала әтисе: Сабир, Нәргизә, Самат.

**1 Иң элек хатын-кызның нәрсәсенә игътибар итәсез: киеменә, буй-сынына, күзләренә, чәченә...**

– Чит хатынныңмы, әллә үземнең хатынныңмы? *(Көлә.)* Хатын-кыз тыштан тулаем матур булса, үз-үзен караган булса, бик күркәм инде. Карале, моның чәче матур, борыны нинди җыйнак дип анализламыйм, образны тулаем кабул итәм. Башкалар да шулай, күрәсең. Шуңа да бит кайвакыт хатын-кыз нәрсәсендер үзгәртә, әйтик, чәчен кистерә, ә ире моны аңламый да кала.

**2 Хатын-кызның кайсы сыйфатларын гафу итәргә була?**

– Көндәлек вак-төяк кимчелекләрен. Ә, бәлки, ул кимчелек тә түгелдер, син генә аны кимчелек дип кабул итәсеңдер...

**3 Ә нәрсә өчен сез бик якын хатын-кызны да гафу итмәс идегез?**

– Һәр гафу итү-итмәү ситуациядән чыгып хәл ителә. Менә син хәзер әйтерсең «фәләнне гафу итмәм» дип, әмма син ул ситуациядә булмаган, шуңа күрә нәрсәне гафу итәчәгеңне яки итмәячәгеңне алдан берничек тә белә алмыйсың.

**4 Хатын-кызлар икегә бүленә: ир-атны илһамландыручы алиһәләр һәм өйдә аның өчен комфорт тудыручы хуҗабикәләр. Сезгә аның кайсы якынрак?**

– Сәер бүленеш... Өйдәге хатын ирне илһамландыра алмыймыни? «Алиһә» һәм «хуҗабикә» сүзләрен капма-каршы кую да аңлашылмый. Монда, беренче чиратта, ирне түгел, хатын-кызны уйларга кирәктер. Аңа ничек рәхәтрәк? Кемгәдер хуҗабикә тормышы белән яшәү комфортлырактыр. Ә кемдер чабышкы ат сыман ыргылып тора – аны өйдә берничек утырта алмаячаксың. Холыклар төрле бит.

**5 Ир кеше өчен аның хатыны дус та була аламы?**

– Була аламы түгел, шулай булырга тиеш тә. Дус та, сердәш тә.

**6 Хатыныгызга ничек тәкъдим ясаганыгызны хәтерлисезме әле?**

– Бәлки, онытыр идем дә, әмма Әдилә һәрвакыт искә төшереп тора бит. Кабан күле буенда булган иде бу хәл. Ә танышкан көнне беренче кар яуганы хәтердә. Мамык сыман карны машина өстеннән щетка белән бергәләп сыпырып төшергән идек. Романтика! Ә минә саннарга хәтер начаррак. Никах, туй даталарын искә төшерә башласаң, югалып каласың.

**7 Ир кеше хатын итеп әнисенә охшаган кызны сайлый, диләр, шулаймы?**

– Бу гайре табигый нәрсә түгел. Ир кеше балачактан үз гаиләсендә ниндидер модель күреп үсә. Анда исә һәр кешенең үз роле. Шул рәвешле аңа бу нәрсәләр сеңә.

**8 Хатыннары ирләреннән күбрәк мал тапкан гаиләләр бар. Ир кеше бу очракта үзен ничек тотарга тиеш?**

– Гаилә өчен куркыныч дип саныйм әлеге күренешне. Хәтта русчалап, риск дияр идем. «Безгә – барыбер, иң мөһиме – бер-беребезне яратабыз», – дип, күпме генә әйтсәләр дә, гаилә өчен бу – сынау. Чөнки әлеге ситуация ир белән хатын мөнәсәбәтләренең табигатенә туры килеп бетми. Бу мәсьәләдә төпченә башласак, борынгы заманнарга барып

чыгарбыз. Күз алдыгызга китерегез: ир мәгарәдә, учак янында җылынып ята, ә хатыны аңа тунарга мамонт сөйрәп алып кайта...

**9 Гашыйк булуын хатын-кыз башлап үзе белдерүгә ничек карыйсыз?**

– Бер караганда, монысы да табигатькә бигүк туры килми сыман. Белмим... Кешеләрнең мөнәсәбәтләренә карaптыр инде. Хатын-кыз ярата икән, ул аны барыбер ничектер әйтә, белгертә – эчендә калдырмый. Аның каравы, һич алдаусыз(дыр). Батырлык өчен «бишле» аңа! Ә минә ир кеше моны ничек кабул итә – анысы бөтенләй икенче мәсьәлә.

**10 Хатын-кызларны ир-атларда иң беренче чиратта нәрсә җәлеп итә дип санайсыз?**

– Тотрыклылык. Тагын – акыл. Ир-атның ниндидер бер үзәк кылы, «умыртка баганасы» булырга тиештер.

**11 Хатын-кызларның үзегезнең кайсы яклырыгызга игътибар итүне көтәсез?**

– Ир-ат өчен күп кирәкми: өйдә тынычлык булса, игәп тору булмаса, шул җитә. Ә инде хатын-кыз ир-атны үсендереп торса, «мамонтка ауга барганда» көч бирсә, бу бик акыллы хатын булыр.

**12 Ир-атны артык чибәр һәм көчле хатын-кызлар куркыта, диләр. Бу, чынлап та, шулаймы?**

– Бу сүзләрдә хаклык бардыр. Барысы да әлеге дә баягы табигатькә барып тоташа. Бу сорауга җавап – күбрәк хезмәт хакы алучы хатын темасында.

**13 Ир-ат белән хатын-кыз икесе ике Галәмнән икәне билгеле инде. Кайчакларда аларның бер-берсен аңламаулары шуннан килеп чыга да. Хатын-кызның нигә нәкъ менә шулай эшләгәнен үзегез аңламаган берәр очракны искә төшерегез әле.**

– Әгәр сез бәхәсләшәсез яки матур гына фикер алышасыз икән, иң мөһиме – фикер эзлеклелеген, мантыйкны югалтмаска. Кайвакыт хатыным белән бәхәсләшкәндә шаярып әйтеп куям: «Синең белән сөйләшеп, колеямны югалттым, кире үз колеяма күтәреп алып куй әле», – дим.

**14 Хаклы икәнегезне яхшы беләсез, әмма хатыныгызның үз туксаны – туксан, хаклык аның ягында дип саный. Мондый очракта нишлисез? Үзегезнең хаклы булуыгызны исбатларга тырышып карыйсызмы әллә инде юл куясызмы?**

– Әгәр сүз ак һәм кара турында барса, моны исбатлау авыр түгел. Һәм хатыным бу исбатлауны, гадәттә, кабул итә. Ә инде ниндидер хисси әйберләр турында сөйләшсәк... Берәүгә берәү ошый, баганага терәү ошый, диләрме әле? Шуның кебек, монда хаклык юк. Элегрәк мин шундый «теләкләр градуснигы» уйлап чыгарган идем. Әйтик, хатынымның киного барасы килә, ә минем – паркка. Нишләргә? Кем юл куярга тиеш? Үз теләгеңне «теләкләр градуснигы» белән үлчәп кара. Әйтик, минем паркка бару теләгем 5 балл гына, ә Әдиләнең киного бару теләге 10 балл кебек хис ителә. Димәк, җыенабыз да киного китәбез. Әлбәттә, икебезнең дә теләкләребез 10 балл булырга да мөмкин. Әмма андый очраклар сирәк. Монда иң мөһиме – алдаламау, ихлас булу. Әгәр һәр хисеңне 10 балл итеп күрсәтсәң, бу градусник эшләми, бик тиз ватыла.

**15 Шундый очракны күзаллыйк әле: сез, ачыгып, арып-талып эштән кайтып керәсез, ә өйдә ашарга пешмәгән. Хатыныгыз, мин арыдым, дип, диванда кырын ятып тора. Сез нишлисез инде? Кафега чыгып китәсез яки пиццага заказ бирәсез? Тиз генә үзегез берәр нәрсә пешерәсез?**

– Өченче вариантны шундук сызып атабыз – аш-су пешерергә хирыс түгелмен. Бергәләп кафега чыгып китәбез, бернинди проблема юк!

**16 Сер түгел, берәр җиргә җыена башласак, без, хатын-кызлар, соңга калучан. Бу сезнең ачуны китерәме? Китерә икән, бу хәл белән ничек көрәшәсез?**

– Соңга калу – хатын-кыз яки ир-ат сыйфаты түгел дип саныйм. Әмма тегеләре дә, болары да ачуны китерә. Минем үземнең дә кешенең ачуын китергән чагым бар. Сирәк кенә.

**17 Хатын-кызлар еш кына... бүләк сайлауда ялгыша: ир-атка ошамастай бүләк бирә. Сез алган бүләкләрнең иң ошаганы һәм ошамаганы?**

– Минә бармагымда көмеш йөзек, аны хатыным бүләк итте. Мин үзем файдалы бүләкләр яратам. Сувенир, бизәк ише чүп-чарны яратмыйм. Гомумән, кайбер бәйрәмнәрдә бер-беребезне бүләксез калдырсак та, бернинди үпкә юк. Бөтен нәрсә бар, бөтен нәрсә җитеш, Аллаһка шөкер. Әмма календарь буенча фәлән көн килеп җитә дә, син бүләк бирергә ТИЕШ. Ярый да берәр идеяң булса: ул очракта бик теләп эзлим ул бүләкне, табам, сатып алам, аннан инде тизрәк тапшырасым килә...

Әйтәм бит, бар нәрсә дә бар, шуңа күрә бүләк эзләү еш кына проблемага әверелә. Ә календарь таләп итә!



**Әлеге чир йогышлы эчәк авырулары арасында иң киң таралганы санала. Статистика күрсәткечләре буенча, авыручыларның 60–70 проценты – балалар. Республика балалар клиник хастаханәсе педиатры, югары категорияле табиб Зөлфия ШАРХЫМУЛЛИНА белән балаларның дизентерия йоктыру очраклары турында сөйләшербез.**

# ДИЗЕНТЕРИЯ

Дизентерия – ашказаны-эчәклек системасы зарарлану һәм инфекцион агулану синдромнары белән узучы йогышлы чир. Аның белән күбесенчә 2 яшьтән алып 7 яшькә кадәрге балалар авырый. 2 яшьтән дә кечерәк сабыйларда исә сирәк күзәтелә, ләкин аларга да йогу куркынычы зур булып санала.

Дизентериянең төп сәбәбе – организмга килеп эләккән шигелла бактериясе. Аның инкубация чоры балаларда берничә сәгатьтән алып бер атна тирәсе була. Күп очракта ике-өч тәүлекне тәшкил итә.

Тиешенчә юылмаган яшелчә, җиләк-җимеш, дөрес эшкәртелмәгән сөт һәм ит ризыклары, пычрак су белән авыз аша кереп, әлеге бактерия эчәклектә бик тиз үрчи һәм үзенең агулы матдәләрен бүлеп чыгара башлый.

Дизентерия ризык аша гына түгел, кешедән кешегә дә йога. 3 яшьтән кечерәк балалар гадәттә аны аралашу-көнкүреш шартларында йоктыра. Бактерия юылмаган куллар, уенчыклар, ишек тоткалары, савыт-саба, сантехника, хәтта кием-салым аша да күчә.

Ризык һәм су аша йогучы төре аеруча хәтәр, чөнки берьюлы бик күп кешеләр авырып, ул эпидемия рәвешен алырга мөмкин. Дөрес эшкәртелмәгән, тиешле температурада сакланмаган ит һәм сөт ризыклары, термик эшкәртү узмаган азык-төлек белән аеруча сак булырга кирәк.

Чирнең таралуында күпмедер дәрәҗәдә чебеннәрнең дә өлеше бар. Нигездә, мондый очраклар авыл җирлегендә күзәтелә.

Балаларда дизентерияне ачыклау берникадәр кыенлыклар тудыра. Бу аларда инкубация чорының кыскалыгы, ә чирнең үтә дә кискен формада башлануы белән бәйле. Сәламәтләнгәннән соң, балада берникадәр вакытка шигелла бактериясенә карата иммунитет барлыкка килеп ала.



**Табиб киңәш итә**

■ баланы амбулатор дәвалау чир җиңел формада булганда һәм өйдә бакчага яки яслегә йөрүче башка балалар, азык-төлек промышленностенда яки балалар учреждениеләрендә эшләүче өлкәннәр булмаган очракта гына мөмкин.

■ Яше дә тулмаган бала исә стационар шартларда дәваланырга тиеш.



■ Авыру балага суны аз-азлап, 10 минут саен эчереп торырга кирәк. Табиб белән киңәшеп, дөге яки алма пешкән су, ромашка төнәтмәсе бирергә була.

■ Бала эче авыртудан интексә, спазмалитик бирергә мөмкин, ә эчәклек эшчәнлеген җайга салу өчен, пробиотиклар эчерү мөһим.

■ Баланың хәле бик авыр булганда антибиотиклар да билгеләнә. Ләкин аларны фәкать табиб кына хәл итәргә тиеш.

**Билгеләре:**

- бик тиз күтәрелгән югары температура;
- хәлсезлек;
- агулану билгеләре барлыкка килү;
- күңел болгану, костыру;
- эч китү (көнгә 10–25 тапкыр булырга мөмкин);
- эч авырту;
- баланы көзән җыеру;
- тахикардия;
- тән тиресенең зәңгәрләнүе;
- кан басымы төшү.

**Ничек сакланырга?**

■ Балага биреләсе азык-төлек җентекләп эшкәртелергә, аларны әзерләү технологиясе төгәл сакланырга тиеш. Шулай ук ризыкларның саклану срокларын да барлап тору мөһим.

■ Чирнең таралуына юл куймас өчен, авыру баланы башкалардан аерырга, ә бүлмәләрне исә дезинфекцияләргә кирәк.

■ Кискен дизентерия белән хастаханәгә кергән бала чирнең билгеләре бетеп, өч көн узгач кына өенә кайтарып җибәрелә.



Фото: www.pixabay.com

ДРКБның матбугат хезмәте җитәкчесе Зөһрә Гыйбадуллина ярдәме белән әзерләнде.



**Яшүсмер чакта без, кызлар, биткә сипкел чыга дип кайгырабыз. Гаилә корып, әни булырга әзерләнгән чорда күбебезнең битен туткыл «бизи». Олыгая төшкәч исә биттә, тәндә төрле таплар күренә башлый. Республика клиник тире-венерология диспансеры табибы, беренче категорияле табиб-дерматолог һәм косметолог Гөлнар ЯФЯСОВА белән сүзебез тиредәге таплар хакында булыр.**

# ТӘНДӘГЕ ТАПЛАР

Җир шарында яшәүче халыкның 60–70 процентында күпмедер күләмдә гиперпигментация күзәтелә. «Пигментация» термины латинча «пигмент» – буяу дигән сүздән алынган.

Кеше организмындагы төп пигментлар булып меланин, гемоглобин, кератоноидлар санала. Гиперпигментациягә, ягъни тәндә таплар барлыкка килүгә, нигездә, меланин сәбәпче. Аның чамадан артыклыгы тәндә көрән таплар барлыкка китерә. Кояш тәэсирендә меланин матдәсен җитештерүче меланоцит күзәнәкләре зурая. Бу механизм организмны артык ультрафиолет нурлардан саклау өчен хезмәт итә.

Гиперпигментациянең төрләре күп: сипкел, хлоазма, лентиго, өлкән яшьтәгеләргә чыгучы таплар, невуслар... Бөтен таплар да сәламәтлек өчен куркыныч тудырмый. Аларның күпчелеге кешегә бары тик косметик уңайсызлык кына китерә. Әмма кечкенә генә бер миң, торабара азып, яман шеш кебек катлаулы чиргә китерергә мөмкин. Гади кеше үз тәнендәге тапларның төрен ачыклый алмый. Тәндә моңарчы булмаган таплар күренә башлау белән табиб-дерматологка мөрәҗәгать итәргә кирәк.

Хлоазма – күп очракта бит тиресенә чыга. Хатын-кызларда йөклелек вакытында барлыкка килгән бу тапларны «йөклелек битлеге» дип тә атыйлар. Гадәттә, тап шактый зур, төгәл формасыз, көрән төстә була, тимгелләр берберсенә тоташып китә. Хлоазма бары тик эстетик яктан гына борчый, сәламәтлек өчен бернинди дә куркыныч янамый. Бала тапканнан соң алар юкка чыга яисә кими.

Лентиго – биттә, кул аркасында, җилкәләрдә барлыкка килүче көрән таплар. Алар түгәрәк формада була һәм тән тиресеннән калкып тормый. Сипкелдән аермалы буларак, бу таплар көзге-кышкы чорда да кимеми һәм тоныкланмый. Мондый таплар артык күп икән, кардиолог һәм ревматологка күренү мөһим, чөнки кайбер очракларда бу генодерматоз – йөрәк-кан тамырлары системасы зарарлану билгесе булырга мөмкин. Сирәк очракларда лентигоның яман шеш авыруына китерү ихтималы да билгеле.

Картлык белән бәйле таплар 45 яшьтән соң барлыкка килә. Кул аркасында, биттә, муенда күзәтелә. Косметик дефект буларак кына бәяләнә, дәвалауны таләп итми.

**Табиб киңәше**

- Гиперпигментация күп очракта ультрафиолет нурлар аркасында барлыкка килә. Кояш нурлары тирене картайта да. Язгы һәм җәйге айларда биткә ультрашәмәхә нурланыштан саклаучы кремнар сөртү гиперпигментацияне киметә, тиренең иртә картаюын булдырмый.
- Гиперпигментацияне киметү өчен, хәзерге медицинада һәм косметологиядә күптөрле ысуллар кулланыла. Пилинг, лазерлы шлифовка, аппарат терапиясе, мезотерапия һәм башкалар таплардан арынырга булыша.
- Кояшның активлыгы югары булган сәгатьләрдә – көндезге уникедән кичке дүрткә кадәр кояшта кызынудан тыелырга кирәк. Аеруча тән тиресендә төрле таплар булган кешеләр өчен актуаль бу.
- Тирене тәрбияләүче косметика сайлаганда аның составына карагыз. Гиперпигментация күзәтелгәндә составында гидрохинон, арбутин, койе кислотасы булган кремнарны яки башка төр косметик чараларны кулланмау хәерлерәк.

**Төп сәбәпләре:**

- кояш астында күп булу;
- нәселдәнлек;
- гормональ системадагы тайпылышлар;
- ашкайнату, бавыр системасы авырулары;
- гинекологик проблемалар;
- паразитлар белән зарарлану;
- кайбер төр дарулар эчү;
- йөклелектән саклаучы препаратлар куллану.

**Бу – мөһим**

- Тәндә теләсә нинди тап барлыкка килү – дерматологка күренер өчен җитди сәбәп;
- Моңарчы булган тап зурайса, төсен үзгәртсә, кычытса яки әрнесә, кичекмәстән табибка күренергә кирәк.



# ИЮНЬ АЕ – АШЛЫ АЙ

**«Ашлаган җир аш бирә», ди безнең халык. Яз көне утырткан яшелчәләребезне хәзер инде ашлар, туфракны файдалы микроэлементлар белән баетыр чор җитте. Моның өчен кибеткә барып, аларны махсус сатып алырга да кирәк түгел. Бакчабызда мул уңыш үстерергә ярдәм итүче ул файдалы ашламаларны күбебез көн саен чүплеккә ташлап бара. Нәрсәләр ул һәм аларны ничек дөрес итеп кулланасы? «Бакчачы» сәхифәсендә шул хакта сөйләшик.**

**Утын көле** – бакчачыларның иң яраткан ашламасы. Анда үсемлекләргә бик тә кирәкле булган 30 төрле микроэлемент бар. Аны коры килеш тә, төнәтмә ясап кулланырга да мөмкин. Көл төнәтмәсен ясау өчен 1 литр көлгә 9 литр кайнар су алына. Капкачын каплап, ике көн торганнан соң, калийга бай ашлама әзер. Үсемлекләрне корткычлардан саклау өчен көлне коры килеш куллану яхшырак. Бакча җиләге соры черек авыруына бирешмәсен өчен дә коры көл булыша. Помидор, борыч, баклажан, кәбестә үсентеләрен утыртасы чокырларга да бер уч көл салып калдырсагыз, аларның тамыр системасы тизрәк ныгыр.

**Йомырка кабыгы** 92–95 процент кальций карбонатыннан, калий һәм фосфордан тора. Бу микроэлементларның барысы да үсемлекләр өчен мөһим. Иң элек йомырка кабыгын киптереп, эчке элпәсен алырга һәм уклау яки кофетарткыч белән ваkларга кирәк. Ваграк булган саен, үсемлекләр андагы файдалы матдәләрне тизрәк үзләштерә. Коры килеш тә, төнәтмәсен дә кулланырга мөмкин. Сыек хәлдә куллану отышлырак. Ул 1 литр кайнар суга 100 г вакланган йомырка кабыгы салып ясала. Капкач белән томалап, бер атна тирәсе җылы урында төнәтелә. Үсемлекләргә сибәр алдыннан 1 литр төнәтмәне 3 литр су белән сыекларга онытмагыз. Бераз исе бар, ләкин анысына гына түзәргә була.


Фото: www.pixabay.com

**Искерә башлаган ипидән** дә үсемлекләр өчен файдалы ашлама әзерләргә мөмкин. Беренчедән, ул аларга үсеш стимуляторы булып тора. Ипидәге чүпрә исә туфрактагы башка файдалы микроэлементларны активлаштырып җибәрә. Ипине ашлама сыйфатында куллану өчен, савытның өчтән ике өлешенә искергән ипи салып, савыт тулганчы җылы су агызабыз. Ипи өскә калкып чыкмасын өчен, авыррак әйбер белән бастырып торырга була. Бер атнадан файдалы ашлама әзер. Кулланыр алдыннан бер өлеш ашлама өч өлеш су белән сыеклана. Ул үсемлекләргә үсеш чорында да, чәчәк аткан һәм җимеш өлгерткән вакытта да файдалы. Ләкин ипидәге чүпрә туфракны калий һәм кальцийга ярлыландыра. Шуңа күрә ипине ашлама урынына кулланусагыз, өстәмә рәвештә калий да кертегез.

**Бәрәңге пешкән суны** бакчада бик сирәк кеше генә кулланадыр. Ә бит ул калийга бай менә дигән әзер ашлама. Бигрәк тә бәрәңгенең кабыгын әрчеми пешерсәгез. Сез аны бүлмә гөлләренә, яшелчәләргә сибә аласыз. Бәрәңгенең кабыгын да әрәм итмичә, аны аерым гына да пешерергә була. Ләкин тоз салып пешерелгән бәрәңге суы ашлама буларак кулланырга яраксыз.

**Кофе түбе** ашлама түгел түгелен, тик ул туфракны көпшәкләндерә, шул рәвешле тамырларга кислород керүенә булышлык итә. Яфраклы чәй исә туфракның структурасын яхшырту белән бергә, аны калий, марганец, цинкка да баета. 2 чәй кашыгы эчелгән чәй яфракларын 500 мл җылы суда 2 көн буе төнәтеп, һәр үсемлек төбенә 1 аш кашыгы күләмендә салып чыгалар.

**Пычкы чүбе** турында төрле фикерләр бар. Каршы фикердәгеләр, пычкы чүбе туфракның әчелеген арттыра һәм андагы азотны үзенә тарта, дисә, яклаучылары туфракны көпшәкләндерү сыйфатын мисалга китерә. Без бакчада куллана торган органик ашламаларның төп составы – азот. Ул күп булса да яхшы түгел. Туфрактагы артык азотны нейтральләштерү өчен нәкъ менә пычкы чүбе кулланыла.


*Кадерле укучыларыбыз! «Сөембикә» журналы сайтында яңа фотоконкурс игълан итәбез. Бакчагызның иң матур, ямьле, күзләрне иркәләүче почмакларын фотога төшереп безгә юллагыз.*
*Адрес: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт. «Сөембикә» журналы редакциясе.*
*Электрон адресыбыз: ssuum@yandex.ru яисә suumbike@tatmedia.com*
*Конкурсның нигезләмәсе – сайтта: www.syuyumbike.ru*
*Нәтиҗәләр сентябрьдә ясалачак. Җиңүчеләрне бүләк көтә!*

# ЯҢАКЛАР МАТУРЛЫГЫ

**Йөз контурын бозып, яңак төшү, халыкча әйтсәк «бульдог яңагы» барлыкка килү теләсә кайсы яшьтә булырга мөмкин. Әмма ул, гадәттә, 35 яшьтән узган хатын-кызларда еш очрый. Киң таралган сәбәбе – артык авырлык. Яңаклардагы «Биш» төеннәре аска төшү дә әлеге эстетик проблеманы китереп чыгара. Моннан иң нәтиҗәле профилактика – массаж. «Әмма ул биткә генә ясау белән чикләнми. Массаж комплекслы булырга һәм эч мускулларыннан ук ясала башларга тиеш», – дип аңлатты массажист Ләйсән САБИТОВА. Иң элек бит мускулларын «җылытыгыз». Моның өчен арканы төз тотып, берничә тапкыр басарга һәм утырырга кирәк. Соңыннан сузып һәм ачык итеп «а», «о», «э» авазларын әйтегез. Моны биттә җылы тойганчыга кадәр эшләгез, аннары күнегүләргә күчәбез.**

1 Диафрагманы тонуска китерәбез. Сулыш чыгарган вакытта дүрт бармак белән аскы кабыргалар астына «кереп», массажлыйбыз.

2 Бармаклар белән җиңелчә генә күкрәкне кагабыз, аннары күкрәк читлегендә массаж тубы тәгәрәтәбез.

3 Сул кулны уң яктагы трапециясыман мускулларга куябыз да, 10–15 тапкыр җилкәне әйләндерәбез. Сул җилкәне дә шулай ук итеп әйләндерәбез.

4 Умрау сөяге өстендәге лимфа төеннәренә бармаклар белән җиңелчә генә баскалыйбыз. Болай эшләү лимфа системасын уятып җибәрәчәк.

5 Муенны өскә таба сузабыз. Моның өчен колакны өскә «тартабыз».

6 Муенны арттан учлап тотабыз да, «әйе», «юк» дигән шикелле, чиратлаштырып, башны селкетәбез. Күнегүне кулларны алмаштырып та эшлибез.

7 Ике кулны күкрәккә куеп, иякне өскә күтәрәбез. Бер үк вакытта тел очын борын очына тидерергә тырышабыз. Тел очын шул рәвешле ян-якка да сузабыз.

8 Ике бармак белән колакларның алдын һәм артын, аннан соң кулның сырты белән ияк астын ышкыйбыз.

9 Аскы казна тиресен йомшак кына чеметкәлибез.

10 Баш һәм имән бармаклар белән иякне тотып, кулларны әкренләп колакка таба шудырабыз. Колак турыннан муенга таба сыпырып, күнегүләрне тәмамлыйбыз.

Һәр күнегүне 10–15 тапкыр эшләргә онытмагыз.




Күнегүләрне, QR-код аша кереп, видеодан да карый аласыз.
Фото һәм видео: Анна Арахамия.



# Бакча йортын яңартабыз

**Җәй көне һәркемнең күңеле табигатькә тартыла. Шәһәр читендә урнашкан бакчасы, җыйнак кына йорты – дачасы булганнарныкы аеруча. Берәүләр бакчада ял көннәрен уздыра, икенчеләр шунда җәй буена яшәргә үк күченеп китә. Саный китсәң, бакча йортында бик күп еллар уздырабыз икән без. Шуңа күрә әлеге йортның матур, уңайлы, зәвыклы булуы, күзгә ямь биреп торуы да мөһим. «Эшләр өчен генә түгел, ял итәр өчен дә уңайлы шартлар булдырырга кирәк», – ди интерьер дизайнеры, архитектор Әлфия КӘРИМУЛЛИНА. Бу язмада Әлфиянең проектына нигезләнеп, бакча йортын матурларга өйрәнербез. Дизайнер тәкъдим иткән киңәшләр дистә еллар элек салынган дачага да яңа сулыш өрергә ярдәм итәр.**



Фото: Анна Арахамия

Алсу ШАКИРОВА әзерләде.
Әлфия КӘРИМУЛЛИНА фотолары.



■ Бакча йортын үзгәртергә теләсәгез, иң беренче чиратта буяуларга, төсләргә әһәмият бирегез. Аксыл, фирүзә төсләрне куллану бик отышлы килеп чыга. Алар мәйданны киңәйтә, бүлмәгә сафлык өсти. Бер бүлмә эчендәге диварларны төрле төсләргә буяудан курыкмаска киңәш итәбез. Иң мөһиме – ишекләрне дивар төсенә буягыз. Бүлмә тагын да иркенәеп китәчәк. Гомумән, бүлмәдә берничә төстәге буяу кулланып, кимчелекләрне яшерергә була. Бу проектта да тәрәзә рамнарын төрле төскә буягач, аларның икесе ике биеклектә булуы да артык күзгә ташланмый.

■ Бакча йортындагы түшәмгә игътибар итегез әле. Түшәмне сүтәргә уйласагыз, гадәттә аның өстендә 20–30 сантиметр биеклектәге бушлыкка тап булырга мөмкин. Без эшләгән дачаның түшәме астында да 30 сантиметр биеклек ачылды. Матчаларны ачык калдырып, агач белән тышлаганнан соң, бүлмәнең мәйданы артты. Бу бик отышлы адым булды. Түшәмне гадәттәгечә ак төскә түгел, башкача да буярга була. Бүлмәдә кулланган төп төсләрнең берсе белән тәңгәл килсә, бигрәк тә яхшы булачак.

Интерьер булдыру – һәрвакыт иҗади процесс. Без күреп ияләшкән гадәти агач бакча йортына заманча караш ташлыйк әле. Бакча йорты кебек корылмалар белән эш иткәндә, аларны яңадан үзгәртеп төзү мөмкин түгел, булган база белән эшләргә туры килә. Интерьерның иске элементларын кулланып, шуларга бераз детальләр өстәп, яңа төсләр, яктылык кертеп кенә дә дачага яңа төсмер бирергә була. Мондый гади генә алымнарны куллану хуҗалар өчен дә бик уңайлы: чыгымнары кесәгә сугарлык булмый. Әлеге дачаны яңартканда кулланган материалларны төзелеш нокталарында да, популяр кибетләрдә дә табарга мөмкин. Дизайнерлар теле белән әйткәндә, бәясенә караганда, нәтиҗәсе күпкә баерак, зәвыклырак күренәчәк.



■ Бакча йорты өчен табак-савыт киштәләрен ачык итеп ясау бик килешә. Киштәләрне агачтан ясап, теләгән төскә буярга мөмкин. Шәһәр фатирында яисә йортыгызда урын таба алмый яткан матур сервизларны шушында урнаштырып куегыз. Алар үзләре декор элементы булып торачак. Уңайлык өчен чынаякларга рәсемдәгечә аерым элмәкләр куярга да була.





■ Бакча йорты өчен ачык проводка куллану – иң отышлы вариант. Беренчедән, үрелгән чыбыклар интерьерны бизәп тора; икенчедән, гамәли яктан да уңайлырак кебек. Дачага ут керткәндә онытылып калган ялганышларны ремонтка зыян китермичә өстәп куярга була.

■ Бакча йорты зур булмаган очракта да, анда юыну бүлмәсе өчен урын табарга мөмкин. Моның өчен бүлмәнең бер башын бер метр киңлектә вагонка белән бүлеп алу да җитә. Игътибар итсәгез, бер диварда такталар вертикаль, икенчесендә горизонталь рәвештә беркетелгән. Бу шулай ук бүлмәнең иркен булып күренүенә йогынты ясый.

8-987-228-29-99
@aelita_rooms
AELITA ROOMS
/ авторские шторы / люстры /
/ дизайн-проект / карнизы /
/ производство мебели /
Мы переехали. Ждем вас по адресу:
г. Казань, ул. Родины, 24 Б
РЕКЛАМА

# Гөмбәле скумбрия



**Динә – балыкчы кызы. Әтисе Ильяс белән бабасы Рәмзигә ияреп, Ык буена балыкка төшкәннәре – балачагының иң күңелле хатирәләре. Өстәвенә, ире дә балык тотарга һәвәс. Г. Камал театры артисты Илнур Закировны күпләр оста балыкчы буларак та белә. «Сөембикә» журналының «Аш-су» рубрикасында ул укучыларыбызны карп балыгы пешерү серләренә өйрәткән иде. Бүген без менә тагын бу кунакчыл гаиләдә кунакта. Сәхифәбезнең хуҗабикәсе – Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры оркестры музыканты, скрипкачы, Муса Җәлил премиясе лауреаты Динә ЗАКИРОВА. Традициягә тугры калып, ул да безне балык пешерергә өйрәтә. Ләкин гади генә рецепт белән түгел, бәйрәм табынына куярлык булачак ул. Музыка, сәнгать дөньясында кайнаган Динәне аш-су бүлмәсендә күрү, бәлки, гаҗәбрәк тәдер. Яңа рецептларны сынап карау аның бер хоббие икән. Куллары нидер эшли, ә күңелендә – музыка! Таба чыжлаган тавыштан да матур көй ишетә ул. Үзе дә музыка укытучысы булган әнисе Диләрә ханымнан күчкән талант бу. Аш-суга осталыгы исә – Рузалия әбекәеннән. Кыюлыгы, уңганлыгы да – аннан. Әйдәгез әле без дә, тәвәккәлләп, Динә өйрәткән рецепт белән Сабантуй кунакларын скумбрия пешереп сыйлыйк.**

**Кирәк**

*(1 кешелек порция өчен)*

- 1 скумбрия балыгы (эче-башы алынмаганы кирәк);
- эре булмаган 1 баш суган;
- 3-4 шампиньон гөмбәсе;
- ярты кишер;
- 1 бал кашыгы лимон суты;
- тоз-борыч, балык тәмләткече;
- 50 г чамасы сыр;
- 2 аш кашыгы кибет каймагы;
- берәр тотам укроп белән петрушка;
- 1 тырнак сарымсак;
- үсемлек мае.























## *Эш барышы*

■ Балыкны юып, сырт сөяге буйлап ярабыз. Шушы кисем аша сак кына умыртка сөяген алабыз, балыкның эчен чистартабыз. Эскәк яки кул белән кылчыкларын чүплибез. Башы белән койрыгына кагылмыйбыз.

■ Суганны вак кына турап, үсемлек мае салынган табада кыздырабыз. Шунда ук эре угычтан уылган кишерне өстибез.

■ Гөмбәне юып, вак шакмаклап турыйбыз һәм суган белән кишер янына салып кыздырабыз. Тәменчә тоз, борыч, тәмләткечләр өстибез, вак угычтан уылган сарымсак кушабыз.

■ Балыкның эченә һәм тышына тоз ышкыйбыз, 1 бал кашыгы лимон суты бөркибез. Яратсагыз, уылган сарымсак та өстәргә була.

■ Фольгадан «көймә» ясап, балыкны шунда урнаштырабыз. Кыздырылган гөмбә белән яшелчәләрне балык эченә тутырабыз.

■ Укроп һәм петрушканы ваклап турап, кибет каймагына кушып туглыйбыз. Каймакны гөмбә өстенә түшибез.

■ Каймак өстенә эре угычтан уылган сыр сибәбез.

■ Тутырылган балыкны 180 градус кызулыктагы мичтә 30 минут пешерәбез.

Ашларыгыз тәмле булсын!



Видеоны карар өчен смартфонның камерасын QR-кодка якынайтыгыз.
Фото һәм видео: Анна Арахамия.






Фото: www.pixabay.com

# Файдалы соуслар

**Җәй ул – кояш, яшелчә, җиләк-җимешләр чоры. Шушы кыска гына вакытта организмыбыз витаминнар, микроэлементлар запасын тулыландырып калырга тиеш. Яшелчәләрнең, җиләк-җимешләрнең энергияне арттыруын, төрле авыруларны кисәтүен барыбыз да беләбез. Мондый рацион кан басымын көйли, йөрәк-кан тамырлары чирләре килеп чыгу ихтималын киметә. Яшелчәләрдәге витаминнар һәм структураланган сыеклык яшьлекне озайта, ә алардагы клетчатка холестеринны һәм шикәрне киметә, матдәләр алмашын яхшырта.**
**Гадәттә, яшелчәләрдән салатлар яки ашлар әзерлибез. Дөрес туклану сәхифәсенең даими авторы Камилә ДИМӨХӘММӘТОВА исә салатларга кушу өчен файдалы да, тәмле дә булган төрледән-төрле соус рецептлары тәкъдим итә. Тагын да файдалырак булсын өчен, аларга көнҗет, көнбагыш, кабак, җитен орлыклары да кушарга була.**

## Авокадолы соус

**Кирәк:**
- 1 киви;
- ярты авокадо;
- 1/3 чәй кашыгы лимон суты;
- 1-2 г кинза;
- 2 аш кашыгы зәйтүн мае;
- 3-4 аш кашыгы су;
- тәменчә тоз, борыч.

Авокадолы соус мексика салатларына килешә.

## Алсу соус

**Кирәк:**
- 80 мл биойогырт;
- 2 аш кашыгы кызыл чөгендер суты;
- чирек лимон;
- 20 г вак угычтан уылган «Пармезан» сыры;
- тәменчә тоз, борыч.

**Эш барышы:** йогыртка чөгендер суты, вак угычтан уылган лимон кабыгы белән лимон суты, уылган «Пармезан»ны, тәменчә тоз, борыч кушып, яхшылап туглыйбыз. Әлеге соус суыткычта бары 8 сәгать кенә саклана ала.

## Грушадан соус

**Кирәк:**
- 1 груша;
- 3-4 мелисса яфрагы;
- ярты лайм суты;
- 4 аш кашыгы су;
- 3 аш кашыгы зәйтүн мае;
- тәменчә тоз һәм борыч.

**Эш барышы:** барлык кирәкле ингредиентларны бергә кушып, блендер белән ваклатабыз. Әлеге соус хуш исле сыр кушылган салатлар өчен тәмле. Суыткычта бер тәүлек саклана.

## Кыярдан соус

**Кирәк:**
- 3 кыяр;
- 3-4 рәйхан яфрагы (базилик);
- чирек лайм суты;
- 3 аш кашыгы зәйтүн мае;
- тәменчә тоз һәм борыч.

Әлеге соусны яшелчәдән әзерләнгән барлык салатларга да кушарга була.

## Шпинаттан яшел соус

**Кирәк:**
- 20 г шпинат;
- 20 г петрушка;
- 2 аш кашыгы лимон суты;
- яшел зәһәр борыч (яраткан кешегә);
- 1 тырнак сарымсак;
- 40 мл зәйтүн мае;
- 8 данә яшел зәйтүн;
- тәменчә тоз.

Барлык ингредиентларны да блендер савытына берәм-берәм салып, издерәбез. Соус бер тәүлек саклана.

игезәкләр
хатын-кыз

Игезәкләр йолдызлыгы астында туган хатын-кызлар һәрвакыт игътибар үзәгендә. Мөлаем, ачык күңелле туташ-ханымнарга игътибар итми мөмкин түгел. Һава стихиясе аларга ирек, тәвәккәллек, ихтыяр көче салган. Үзләрен бары тик яхшы яктан гына күрсәтә белә Игезәкләр. Һәр эшкә кызыксынып тотыналар.

***Мәхәббәт.*** Чын мәхәббәтен тапканчы Игезәкләр, яшьлектә мавыгып, үзләренә тиң булмаган кешегә берничә тапкыр гашыйк булырга мөмкин. Шул тәҗрибәгә таянып, үз ярын табып, киләчәктә матур гаилә коралар. Игезәкләр сайлаган кеше шәхес буларак формалашкан булса, шаккаттыра белсә, һәрвакыт үсештә булса, мондый мөнәсәбәтләр гади мавыгу булып кына калмаячак.

***Мөнәсәбәтләр.*** Конфликтлы вазгыятьтән ерак торырга тырышалар. Ләкин үзләрен яклый да беләләр. Очкын кабызып, тирә-юньдәгеләрнең кәефен күтәрергә сәләтлеләр. Һәрвакыт гаделлеккә омтылалар, дөреслек, хаклык өчен көрәшәләр. Шаяра белү, дәртләндерү сәләтенә ия Игезәкләр янәшәдәгеләрне һәрдаим канатландырып тора.

***Гаилә.*** Игезәкләр йолдызлыгында туган хатын-кызлар гаилә җанлы. Ирләре өчен, һичшиксез, тугры юлдаш алар. Балалары өчен әни генә түгел, серләрен ачарлык якын дус та була беләләр. Шул ук вакытта Игезәкләрдә таләпчәнлек сыйфаты да бар. Шушы күркәм яклары яхшы, тәртипле балалар тәрбияләп үстерүдә ярдәм итә.

йолдызнамә
июль

***Кучкар.*** Гаиләгә карата җаваплылык хисе көчле сездә. Әлеге энергияне якыннарыгыз, туганнарыгыз белән үзара мөнәсәбәт җайлауга юнәлтегез. Тормыш мәшәкатьләреннән арынып ял итәр өчен уңайлы, җылы гаилә учагы булдырыгыз. Шул җылылык сезне ел буе сөендереп торыр.

***Үгезбозау.*** Кызыклы идеяләр, нәтиҗәле аралашулар, җитди фикерләр ае сезнең өчен. Яңа дуслар да табарсыз. Бу кадәр актив аралашу чорында тормышыгызның мөһим вакыйгалары хакында да онытмагыз. Берничәсен аерып алып, игътибарны шуларга юнәлтегез.

***Игезәкләр.*** Әйткән сүздә нык торган чагыгыз. Акчаны юк-барга сарыф итмичә саклап тотсагыз яхшы булыр. Гомумән, финанслар өлкәсен күбрәк өйрәнеп, киләчәк өчен кирәкле мәгълүмат тупласагыз, файдасын күрерсез. Ышанычлы керем эзләр өчен дә отышлы ай.

***Кысла.*** Кая гына барсагыз да, игътибар үзәгендә булырсыз. Кайсы эшкә тотынсагыз да – уңышка юлыгырсыз. Сездән бары тик тәвәккәллек таләп ителә. Үзегезне күрсәтә, тормышыгызны яхшы якка үзгәртә торган чорны кулдан ычкындырмагыз.

***Арыслан.*** Үз эчеңә кереп бикләнү, тынычлык эзләү вакыты – сезнең өчен. Организм таләпләренә колак салыгыз, үз-үзегезне ишетегез. Ләкин артык мавыгып китеп, гел ялгыз калырга ашыкмагыз. Тоемлау хисе дә артып китәр әлеге чорда.

***Сөмбелә.*** Башкалар фикеренә ияреп китеп, үзенчәлегегезне югалтмагыз. Кешеләрнең сезгә булган мөнәсәбәте, нәрсә уйлавы турында артык борчылмаска киңәш ителә. Шул ук вакытта башкаларны ишетә белсәгез, шактый файдалы фикерләр, идеяләр туплый алырсыз.

***Бизмән.*** Максат-хыялларыгызны барлар вакыт. Карьерага кагылышлы сорауларга игътибар итәргә, югарырак баскычка күтәрелергә менә дигән мөмкинлекләр ачылыр. Хыялда йөртелгән бизнес планын тормышка ашыру өчен дә уңышлы чор.

***Чаян.*** Максатларыгызны дөрес юнәлешкә борсагыз, сезне сәяхәтләр, кызыклы ачышлар көтә. Күңелегез дә яңалыкларга, үзгәрешләргә омтыла. Тормыштан матур сабак алырга, яңа юнәлештә үсәргә әзер сез. Фәнни ачышлар белән мавыгу да нәтиҗәле булыр бу чорда.

***Укчы.*** Моңа кадәр бер дә кызыксынмаган юнәлештә хәрәкәт итә башларсыз. Сезнең өчен тормышның күзгә күренмәгән, тирәнрәк яшеренгән серләре кызык булыр. Дин белән кызыксына башлавыгыз да ихтимал.

***Кәҗәмөгез.*** Әйләнә-тирәдәгеләр белән мөнәсәбәтләргә игътибарны арттырыгыз. Башкаларның үзара аралашуын да көйләргә сәләтле сез. Бу саваплы эшнең нәтиҗәсе чын-чынлап сокланырлык булыр. Бөтен җиргә дә өлгерү теләгеннән тыелып торыгыз. Сәламәтлеккә зыян килерлек булмасын.

***Сукояр.*** Игътибарыгызны көндәлек мәшәкатьләргә юнәлтегез. Вак-төяк дип караган эшләрне дә нәтиҗәлерәк башкару хакында уйланыгыз. Бу гади генә үзгәрешләр дә тормышыгызны шактый җайга салырга мөмкин. Үзегез турында түгел, башкалар хакында күбрәк уйланыгыз.

***Балыклар.*** Яраткан шөгыльләрегезгә тотынырга иң кулай вакыт. Сезнең өчен күңел ачу чоры башлана. Вакытыгызны күбрәк балалар белән уздырыгыз, ял итегез, тормышка бераз җиңелрәк карагыз. Тормышыгызда җәй халәте сизелсен!

«Хатын-кыз галәме» сәхифәсен Лилия ГӘРӘЕВА, Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА, Алсу ШАКИРОВА әзерләде.










# КОЯШ КАЙНАРЛЫГЫ БЕЛӘН

Мөлаем, нәфис, зифа гәүдәле ул, ә холкы буенча – эзләнүчән, кызыксынучан. Шундый булмаса, мөгаен, күп сәгатьләрне очкычларда үткәреп, Казан, Мәскәү һәм Гавана арасында яшәп иҗат итмәс тә иде. Татьяна Веранес яшүсмер вакытта ук рәссам юлын сайлаган. Ә бит ул бер дигән биюче яисә китапларын күпләр яратып укырлык язучы, яисә испан теленнән тәрҗемәче булып китә алыр иде. Испан телен бик яхшы белүе аны нәкъ менә Кубага китергәндер дә инде. Татьянаның иҗаты өчен мөһим булган бар нәрсә – эссе Кояш, кичкә хәтле дә суынмаучы ак ефәктәй комлыклар, җылы җилләр, зөбәрҗәт төсендәге Кариб диңгезе, кайнар биюләр, илаһи илһам – биредә. «Кубадагы тормыш бар мәгънәдә кайнар, ачык күңелле Куба халкының милли холкы, яшәү рәвеше, абсолют хөрлек һәм бәхет хисе (алар әйтерсең лә ел әйләнә һәм көннәр буе гел биеп, шат көйләр ритмында дәртләнеп җырлап яши!), үзгә табигать, һавадагы диңгез исе... «Кешеләрне хәрәкәттә сурәтләмим, персонажларымның эчке кичерешләрен тасвирлау минем өчен әһәмиятлерәк», – ди ул.

Әйе, Кубаны үз күзләрең белән беркайчан да күрмәскә дә мөмкин, әмма ул сурәтләгән образлар аша гына да бу утрауга гашыйк булып була! Гашыйк булу гынамы соң, киндерләрендәге Куба сине тәмам әсир итә! Картиналардагы тропик чәчәкләрдән хуш исләре бөркелеп тора сыман. Чуар кошлар, кызыл ябалдашлы агачлар, гуайява, манго, папайя сурәтләре... Алар шулкадәр яратып язылган! «Казанны сагынып кайтсам да, бераздан Гаванага китеп барам, чөнки иҗатым өчен кирәк булган бар күңел халәте шунда гына туа», – дип аңлата рәссам.

Ирекле рәссам Татьяна Веранес 1982 елны Казанда туган, Н. И. Фешин исемендәге Казан сынлы сәнгать училищесын тәмамлаган. 2005 елдан – җитди иҗат өлкәсендә. Белемнәрен арттыру өчен башта испан телен өйрәнгән, Кубаны яратып ясаган, бераздан бу илгә китеп тә барган.

Мәшһүр испан акварелистлары белән дуслашып, акварель язу ысулын ныгыткан. Ул Мәскәүдәге шәхси рәсем мәктәпләренең берсендә дәресләр дә алып бара. «Башкаларны рәсем ясарга өйрәтү авыр түгел, ә менә аларның иҗади фикер йөртә башлауларын күрү кыенрак», – дигән нәтиҗәгә килгән ул.


Татьянага майлы буяулар белән иҗат итү кулайрак. Чөнки майлы буяулар озак кибә, ошамаган детальләрне төзәткәләргә, иҗат процессын туктатып торып, үзең яраткан куба каһвәсен пешереп алырга да була. Ә иртәнге Гавана Татьянаны абайламаска да мөмкин, чөнки рәссам төнлә иҗат итә. Аның иң беренче тамашачылары Гавана күгендәге ерак йолдызлардыр, мөгаен...


Рәссам Татьяна Веранес Казанда, Мәскәүдә, Сальтильода, Копенгагенда үткәрелгән күргәзмәләрдә катнашкан. Күргәзмәләр саны бихисап булмаса да, иҗатын дөньяның төрле илләрендә үз итүчеләр шактый. Ул кечкенә улы Диегоны үстерергә дә, сынлы сәнгатьне яратучыларны яңа картиналары белән шатландырырга да җитешә.

«Куба, Мексика, Бразилия мәдәниятен үз күрәм. Җете төстәге картиналарымны язудан туктап торган мәлләрдә сальса биим», – ди Татьяна. Аның картиналарына карап, без дә әлеге талантлы рәссамның халәттәшләренә әйләнәбез. Гаванага кадәр юл алмасак та, киндерләрендәге Куба күңелләребезне яулый.

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА












**ТАТЬЯНА ВЕРАНЕС**







# ТАТМЕДИА ГАЗЕТА-ЖУРНАЛЛАРЫНА ЯЗЫЛГАН ӨЧЕН – СКУТЕР, ТЕЛЕВИЗОР, ЭЛЕКТРОЧАЛГЫ БЕЛӘН БЕНЗОПЫЧКЫ, СМАРТФОННАР ҺӘМ БАШКА ТЕХНИКА

**Катнашу өчен гаризалар 2021 елның 20 июленә кадәр кабул ителә**
**Бүләкләр уйнату 2021 елның 19 августында узачак**



**1 ЯЗЫЛ** — 2021 елның 20 июленә кадәр «ТАТМЕДИА» АҖнең бер газета һәм бер журналына язьл (акциядә катнашучы басмалар белән tatmedia.ru сайтында танышып була)

**2 ҖИБӘР** — «Акция» билгесен куеп, язылу квитанцияләренең копиясен безгә җибәр (телефон номерыгызны язарга онытма). Адрес: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 яки podpiska@tatmedia.ru

**3 ОТ** — Язылган өчен телевизор, электрочалгы белән бензопычкы, смартфон. Төп бүләк – скутер!




Акция турында тулырак мәгълүматны, призлар һәм аларны алу турында tatmedia.ru сайтында белеп була.
Акциянең узу вакыты: 12.05.2021–18.08.2021. Гаризалар кабул итү 20.07.2021 кадәр.
Оештыручы «ТАТМЕДИА» АҖ. Реклама 16+ Товарлар рәсемдәгеләрдән аерылырга мөмкин.